1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
2019 АВГУСТ № 8

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

СЕЛФИ ЯСАУ
хоббимы, чирме?..

ЧӘЧЛӘРЕҢӘ ҖИЛЛӘР ҮРЕЛМИ...
бала хәсрәте

ЯРАТУГА КҮКЛӘР ШАҺИТ
артистлар гаиләсе

Гөлзада РУДЕНКО:

АЛАБУГАГА КИЛЕГЕЗ! БЕЗДӘ ШИШКИН, ДУРОВА, ЦВЕТАЕВА...

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә... ...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Муса ЖӘЛИЛ

ӨЯНКЕ

Әминәгә

(шигырьдән өзек)

...Сөйгән дустым еракта;
Карыйм һаман шул якка;
Сөйгәнем-чибәремне
Артык сагынган чакта.

Шул яктан да таң белән
Язгы җил иссен иде.
Сөйгәнемнең йөрәген
Тирбәтеп үтсен иде.

Һәм өянке яфрагын
Койган кебек алдыма, –
Сөйгәнемнән җылы хат
Китерсен иде миңа.

Аңласын иде җаным
Җылы карашын аның,
Һәм дуслыгын иптәше
Никадәр сагынганын...

1939 ел, март.

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Әминә Җәлилова.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



08’2019

Фото: Анна Арахамия

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Гөлзада Руденко
Фото: Ольга Дорофеева

Верстка:
Лариса Маликова

Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 08.08.2019 ел
Заказ О-2063
Тираж 4924

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



30 АВГУСТ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КӨНЕ



Баш мөхәррир сүзе



Кадерле укучыларыбыз! Бу саннан башлап ТАССРның 100 еллыгы уңаеннан яңа проект башлап җибәрдек.
Журналыбызны әзерләгәндә күңелне тетрәндергән бер хатирәгә юлыктык. Беренче тышлык өчен Гөлзада Рәкыйп кызы Руденконы фотога Чаллы фотографы Ольга Дорофеева төшергән иде. Ә бер көнне аннан хәбәр килеп ирешә: «Минем әбием «Азат хатын» журналын бик ярата иде. Һәр яңа санын көтеп алып, кадерләп җыеп барды. Ә мин, 10-11 яшьлек кызчык, тышлыкларын сыйпап: «Шундый матур апалар... Үсеп, фотограф булгач, мин дә шулай төшерә алырмын микән?» дип уйлый идем. Рәхмәт сезгә! Миңа ышаныч белдереп, балачак хыялымны чынга ашырдыгыз. Миңа хәтта гонорар да кирәк түгел. Сезнең журналда исемем күренү үзе мәртәбә! Журнал кулыма элэгү белән әбием янына зиратка барып килермен. Әбиемнең рухы шатлансын...»
Ольганың балачак истәлекләре үзебез өчен дә табыш булды!
Кадерле укучыларыбыз, сез дә гаилә ядкарьләрен барлап карагыз әле. Бәлки, сезнең арада «Сөембикә» («Азат хатын») журналының беренче тышлыгында лаеклы урын алган ханымнарның балалары, оныклары, туганнары бардыр? Проектыбызда сез дә катнаша аласыз бит! Ул геройларның язмышы нинди булган? Тормышта нинди үрләр яулаган, бүген нинди алар?..
Беренче тышлыктагы героиняларыбызның тарихларын көтеп калабыз.

Сезне яратып,
Лариса МАЛИКОВА.

Фото: Анна Арахамия




Безнең тышлыкта

14

«Шәһәрнең кабатланмас үз рухы, үз йөзе бар. Ә ул рухны саклап калырга, йөзне карап-тәрбияләп торырга кирәк»

Алабуганы саклаучы фәрештә
Эльмира Закирова

Заман һәм без



6 «Мин иң-иңе...»
Чулпан Галиәхмәтова

10 23 яшьлек «генерал»
Лилия Гәрәева



20 Сары диңгез
Гөлнур Сафиуллина

Татар дөньясы



24 Шәхесләргә бай милләт без
Эльмира Шәрифуллина




28 Алтынчы буын балчы
Чулпан Галиәхмәтова



32 Яратуга күкләр шаһит
Раилә Хәялиева


Мәдәни тормыш



38 Айның тулган чагы
Роза Мулланурова

Яшәеш

46 Чәчләреңә җилләр үрелми...
Гөлнур Сафиуллина



50 Кытай. Хайнань
Раушания Полосина-Сөләйманова


Хатын-кыз галәме



60 Дограма



62 Лимонад яратасызмы?



«МИН ИҢ-ИҢЕ...»



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Дөнья акылдан шаша! Үзен-үзе табу юлында булган яшүсмерләр генә түгел, әби-бабайлар, әти-әниләр, хәтта премьер-министр, президентлар да селфи белән «җенләнә». Бу нәрсә? Шапырынумы, ялгызлыктан дарумы, үзеңне ярату билгесеме, әллә инде барлыгыңны бөтен дөньяга белгертәсе, шатлыклы минутларың белән уртаклашасы килү теләгеме? Ярый ла әлеге зарарсыз шөгыль тормышка комачау итмәсә... Иң кәттә селфи ясыйм дип, гомерләре белән хушлашучылар да юк түгел бит...

Алабугада яшәүче кыз селфи ясаган вакытта күпердән егылып төшә...

Дәрвишләр бистәсе–Восстание станцияләре арасындагы күпергә менеп селфи ясаган вакытта ике яшүсмер егылып төшеп имгәнә, берсе, югары вольтлы электр үткәргечтә тиеп тәнен пешерә...

Икенче курс студенты балкон рәшәткәсенә утырып, үз-үзен фотога төшергән вакытта дүртенче каттан егыла...

Раифа–Күлбаш юлында 23 яшьлек кыз руль артында социаль челтәрләрендә туры эфир алып барган вакытта бәрелеп үлә...

Бу әле аерым бер фаҗигале очраклар буенча Татарстанда теркәлгән рәсми мәгълүмат кына. Без ишетми калганы күпмедер. Статистиканы алдап булмый: селфи ясаганда бәхетсезлек очрагына тарып үлүчеләр саны буенча Россия дөньяда икенче урында. Моны Journal of Family Medicine and Primary журналында басылып чыккан тикшеренүләр нәтиҗәсе раслый. Селфи ясаган вакытта корбан булучыларның уртача яше – 23 яшь. Экспертлар фикеренчә, 20–23 яшьтә үз-үзеңне танып белү өчен экспериментлар ясарга үзаңда чикләр куелмый әле. Нәкъ шушы яшьтә танылу, абруй казану теләге дә зур. Моннан кала, Россиянең әлеге күңелсез рейтингта беренчеләр рәтендә булуы менталитет белән дә бәйледер, чөнки илнең киң күңелле халкы һәрнәрсәнең уңышлы тәмамлануына ышанып яши. Өстәвенә, шаккаттырасы килү теләге дә көчле!

Беренче селфины 1839 елда Филадельфия фотографы Роберт Корнелиус ясый. Кызлар арасында үз-үзен фотога төшерүче туташ – Анастасия Романова. (Әйе, Россия империясенең соңгы патшасының



Кәүсәр ЯХИН, профессор, медицина фәннәре докторы, КДМУның психиатрия һәм наркология кафедрасы мөдире, «Россиянең психиатрлар җәмгыяте» вице-президенты, Татарстанның атказанган табибы

Селфомания – кешелек үсешендәге техноген юнәлешнең бер төре. Аның нигезендә гади бер нәрсә: һәрберебезгә үзе булган фото кадерле! Күз алдына китереп карагыз, өстәлдә бик күп фотографияләр ята, ди. Иң беренче нишлисез? Дөрес, объективка үзегез дә кергән сурәтне эзлисез. Танышыгыз булганны карап алырга мөмкинсез. Ә менә читләр фотосы сезне бөтенләй кызыксындырмый. Шул рәвешле, үзеңне әйләнә-тирә белән чагыштыру функциясе башкарыла. Мин ничек күренәм? Селфи зарарсыз феномен кебек. Тик үз-үзеңне сурәткә төшереп, аны социаль челтәрләргә урнаштыру тормыш рәвешен билгеле башласа, патологиягә әйләнә. Башта матур сәнгатьчә югары фотолар куелса, соңыннан моңа ихтыяҗ шуның кадәр үсә ки, сыйфат санны алыштыра башлый. Тормышка комачауламаса, әйткәнемчә, селфи – гадәти бер феномен. Аны ябыгу белән чагыштырып карарга мөмкин. Артык авырлыктан котылу бик яхшы максат, хәтта ки кирәкле дә – сәламәтлек өчен файдалы. Ләкин ул тормыш мәгънәсенә әйләнә икән – анорексия авыруы килеп чыгачак. Селфи белән дә шул ук хәл булырга мөмкин. Мавыгу психологик та, патологик та була ала. Шуңа күрә үз-үзен сурәткә төшерүчеләрнең барысын да селфоманнар дип әйтергә ярамый. Моның өчен билгеле бер критерийлар бар. Кеше социаль челтәрләргә көненә биштән артык фотосын «элә». Сурәтен куймый тора икән, анда канәгатьсезлек хисе барлыкка килә, борчыла башлый. Бу инде бәйлелекнең беренче стадиясе. Соңгы стадиядә кеше реаль тормышын селфига алыштыра. Әлеге капканга яшүсмерләр эләгә. Аларга бер-берсенә иярү хас. Кагыйдә буларак, яшүсмерләр бервакытта да ялгыз түгел, алар нинди дә булса төркемдә. Һәм шул төркемнең нормаларына буйсыналар. Төркемнәр, еш кына бер-берсе белән ярышып, селфи төшә башлый. Кәттә селфи ясарга дип менеп, күпме яшүсмер биек йорт түбәсеннән егылып төшеп, якты дөнья белән хушлашты. Алар моның фаҗига белән тәмамланачагын, кызганыч, аңлап та бетерми. Дан, шөһрәт яратучылар да селфи белән артык мавыга, һәрвакыт макталып торырга ярәтканнар өчен дә әлеге фотолар читтән «ярдәм» эзләү чарасы. Кыскача аңлатсак, селфоманнар – бәйлелеккә тартылган шәхесләр төркеме. Алар гаиләдә ярату таба алмаган кешеләр булырга да мөмкин. Шул рәвешле, реаль тормышка туры килмәгән дөньяга омтылалар. Шулай ук һәрвакыт игътибарга мохтаҗ кешеләр дә әлеге феномен белән мавыга, чөнки алар ялгыз калырга яратмый. Әйләнә-тирәдәгеләрнең игътибарын алар өчен селфи алыштырырга мөмкин.

Селфомания күпкырлы авыруга әйләнергә мөмкин. Һәм аны куркыныч түгел дип тә әйтеп булмый. Һәр очрак – аерым. Аны диагнозлау да индивидуаль булырга тиеш.

Фото: www.pixabay.com

кызы!) Ул 1914 елда көзгедәге чагылышын сөйгәненә төшереп җибәрә. (Хәзер яшьләр арасында популяр булган шөгыльнең менә кайда икән чишмә башы!) Беренче селфи моннан 180 ел элек ясалуга карамастан, аның иң популяр чоры безнең көннәргә туры килде. Моны гаджетлар, әлеге максатлар өчен төрле технологияләр үсү белән аңлатып була. Беренче селфи ясаучыга 15 минут вакыт кирәк булса, хәзер бер минут эчендә үз-үзен бер мең ярым тапкыр фотога төшереп, Гиннесслар китабына керәләр. (Сүз уңаеннан: селфи сүзе дә инглиз теленнән – үз, үземне дип тәрҗемә ителә.) Бүгенге көндә дөньяда тәүлек эчендә генә түгел, хәтта бер минутта күпме селфи ясалганын берничек тә исәпләп чыгарып булмый, чөнки моңа ашау, юыну кебек үк ихтыяҗ бик зур. Ул яшәү рәвешебезгә шуның кадәр үтеп керде ки, селфи ясамыйча калган көннәрне күз алдына китерү дә авырлаша башлады. Психологлар билгеләвенчә, әлеге феномен шәхесара мөнәсәбәтләр кыйммәте югалганнан килеп чыккан. Кешеләр күбрәк карьера, бизнес, байлык җыю белән мәшгуль. Ә аралашу, дуслык, мәхәббәткә игътибар бик аз кала.

Селфи эпидемиясе

Селфи ясап, аны җәмәгатьчелеккә күрсәтү өчен әнә күпме интернет мәйданнар булдырылды. Акъәбиләребезнең киңәшләре онытылды. Алар сурәтеңне теләсә кемгә бирмә, теләсә кайда йөртмә, исраф булыр, үзеңә күз тияр, дип әйтә иделәр. Хәер, дөнья белән бергә әбиләр үзләре дә үзгәрде бугай инде. Цифралы виртуаль дөнья кочагында яшибез бит! Элекке заманда фотографияләр бик кадерле булып, өй түрендә – махсус ясалган рамаларда саклана иде. Хәзер фотога төшү берни тормый. Ә кешеләргә истәлек калдыру гадәте хас. Бәлки, селфи феномены да әнә шуннан киләдер. Блогерлар исә аны замана шаукымы, үзеңне күрсәтүнең бер төре дип аңлата. Социаль челтәрләрдә актив булган Әнисә Һадиева өчен, мәсәлән, селфи – тренд, җәлеп итүнең бер ысулы. Эстетик фотолар яраткан яшь ханым аны бары тик шәхеснең үз-үзен күрсәтү чарасы дип саный. «Бер начарлыгын да күрмим, нинди дә булса психик тайпылыш яки ярату җитмәгәннән дә түгел. Ул бары тик – эмоцияләр», – ди Әнисә.



Булат БӘДРЕТДИНОВ,
гаилә психологы:
«Селфи ясау – хобби, әмма артыкка китсә, ул психик тайпылышка китерә».

Селфины халык арасында танылган кешеләр – артистлар, сәясәтчеләр кертте. Дөрес, алар өчен ул – социаль статусны, әйләнә-тирәгә йогынтыны арттыру максатларында кулланылган чараларның берсе. Аны бәйлелек дип атап булмый, әлбәттә. Ә менә яшьләр арасында популярлашканнан соң, ул бөтенләй икенче төсмер алды шикелле. Беренче карашка, үзеңне сурәткә төшереп, социаль челтәрләргә урнаштыруның бер зыяны да юк кебек. Гап-гади бер хобби! Тик соңыннан социаль статусыңны раслау өчен «лайк»лар артыннан куу башлана. Ә бу патологиягә китереп җиткерергә мөмкин.

– Селфомания, кагыйдә буларак, нинди дә булса психик кичерешләр нигезендә барлыкка килә, – ди гаилә психологы Булат Бәдретдинов. – Кеше реаль тормыштан «кача», виртуаль тормышта ямь таба башлый. Тагын бер сәбәп: кемгәдер нидер расларга тырышу. Ә моңа китергән үпкәләүләр кеше тормышында бик күп булырга мөмкин. Бер мисал. Табибка яшүсмер белән ана килә. Алар икәү генә яши, тик бу очракта ана түгел, бала әнисе өчен җаваплылык алган – аны психологка алып барырга күндергән. Әни кешенең күп вакыты виртуаль дөньяда уза икән. Социаль челтәрләргә фотосын кую ананың тормыш рәвешенә әйләнә башлаган. Ә баласының кайгыртучанлыгын аңлап җиткермәгән. Утырып сөйләшкәннән соң, әни кешенең депрессиядә булуы ачыкланды. Аның өчен селфи, социаль челтәрләрдәге фотолар коткару чарасына әверелгән.

Кемнәр селфоманнар булып китә ала?

Беренче чиратта, яшүсмерләр. Алар бу дөньяда үз урыннарыннан битәр, танылу, башкалардан аерылып тору юлларын да эзлиләр. Бигрәк тә укуда, мәктәптән тыш секцияләрдә әллә ни уңышлары булмаганнар өчен селфи – иң җиңел танылу юлы. Яшүсмерләрнең экстремаль шартларда селфи ясарга тырышуы да әнә шуның белән бәйле. Психолог Булат Бәдретдинов ата-аналарга яшүсмер балаларына бик игътибарлы булырга киңәш итә. Аларга реаль тормышта мавыгу табарга ярдәм итәргә кирәген әйтә. Бәяләүне бала интернет челтәрендә түгел, чын тормышта табарга тиеш!

Үз-үзен бик яратучылар яки «нарцисслар» өчен дә селфи менә дигән мавыгу. Аларның һәр сурәте – «Менә мин нинди! Яратыгыз!» рухындарак. Дөрес, кешеләр

һавалы булуларын бервакытта да танымый. Ә менә читләрнекен тиз күрә. Тәкәбберлекнең дәрәҗәсе дә әнә шул селфиларда чагыла.

Һәрвакыт игътибарга мохтаҗ булучылар да – селфи корбаннары. Бу төркемгә яшь әниләрне дә кертергә була. Актив тормышта яшәгән яшь ханым, бала тугач, берничә елга икенче планга күчә. Аның аралашу мохите тарая. Ире иртәдән кичкә кадәр эштә, ул өйдә ялгызы. Менә шундыйлар өчен социаль челтәрләр юанычка әйләнә дә инде. Селфилар куйганнан соң, язылучылардан: «Син өйдә ятсаң да шундый матур», дип килгән шәрехләмәләр аларга яшәү дәрте өсти.

Ир-атларның бертуктаусыз селфи ясауларына да аңлатма бирергә мөмкин. Психологлар моны сексуаль канәгатьсезлек белән бәйли. Ир-ат социумда канәгатьсезлек кичерә: күп акча эшли алмый, социаль статусы юк, ә үзенә игътибар җәлеп иттерергә тырышу теләге һәркемдә яши.

Профессор Кәүсәр Яхин боларны селфоманнар түгел әле дип ассызыклый. Тик балны да күп ашасаң, әче тоела башлый... Һәрнәрсәнең чиге бар. Галим фикеренчә, һәр феномен патология китереп чыгарырга мөмкин. Шул ук алкогольне генә алыйк. Чаманы белмәгәндә, алкоголизм колына әверелү берни тормый бит. Психологлар әйтүенчә, кеше көненә дүрт-биш тапкыр селфи ясап, социаль челтәрләргә куя башлый икән, ул инде селфоман. Менә шунда гына чаң кагарга мөмкин. Дөрес, әлегә селфомания авыру итеп саналмый. Америкада аны психик тайпылыш итеп таныганнар инде. (Яңа технологияләр дә алардан башлана бит!) Ләкин ул диагноз дәрәҗәсендә кабул ителмәгән.

Тагын шунысын да онытмагыз, сезнең селфи башкаларның ачуын китерергә дә мөмкин. Моны соңгы тикшеренүләр дә раслаган (азмыни социаль челтәрләрне күзәткәннән соң депрессиягә китүчеләр?!) Бигрәк тә релфилар ягъни сөйгән ярлар белән төшкән фотолар ярсыта икән. Селфида кеше һәрвакыт елмая, һәрвакыт чибәр, һәрвакыт уңышлы. Анда яше дә күренми, чын кайгыру, борчылу да сизелми. Киресенчә булган очракта ул фотоларны язылучылар бәяләмәячәк бит. Халыкка матур тормыш кирәк. Селфиларда – без робот!

Яңача фикерләү

Ничек кенә тәнкыйть утына тотсалар да, кул сузымында төшерелгән сурәтләр – бик сөйкемле фотолар. «Мин монда һәм хәзер» эффектын тудыралар. Фотоны караган кеше дә үзен шул сурәт эчендә дип хис итә. Кайбер галимнәр фикеренчә, селфи – фикерләүнең яңа тибын формалаштыру процессы: мин картинаның бер өлеше.

– Нинди дә булса матур урынга килеп чыксам, шуны башкаларга да күрсәтәсем килә. Бу сурәтне күчереп алмадым, аны үз күзләрем белән күрдем дигәнне дәлилләү өчен селфи ясыйм, – дип аңлата әлеге феноменны социаль челтәрләр кулланучы Артур Фәлахов. – Ләкин максатым һич кенә дә ниндидер «лайк»лар туплау, үз-үземне күрсәтеп мактану түгел. Матурлыктан алган хистойгыларым белән уртаклашасым, башкаларны да шунда чакырасым килә. Бары шул гына.

Селфины тәкәбберләр «авыруы» дигән фикер белән дә килешеп булмый. Алар, нигездә, ялгызлар. Ә үз-үзеңне фотога төшереп, социаль челтәрләргә кую – яшәвеңнән тәм табып, шуны башкалар белән уртаклашасы килү теләге. Шул ук галимнәр белдерүенчә, селфи – каршылыклар эпохасы символы. Кеше башкалардан аерылып торырга да омтыла, шул ук вакытта аның аралашу теләге дә бик зур. Ә тормышта, күргәнебезчә, чын, җылы аралашулар бетеп бара. Аны социаль челтәрләр алыштыра. Танышыңның селфиен карыйсың да күрешкән кебек буласың, аралашуга ихтыяҗ кими.

Күпләр селфины үз-үзенә ышанган кешеләр генә ясый һәм «тарата» дип саный. Ә үзенең кыяфәтеннән канәгать булмаганнар башкалар фотосын караучылар дигән фикерләр дә бар. Селфины күп төшәбез төшүен, ә социаль челтәрләргә матур чыккан дип тапканнарын гына куябыз. Селфи – үзебезне ничек телибез, шулай күрү чарасы ул. Ә лайклар – моңа бүләк, безнең сөйкемле, чибәр, уңышлы булуыбызның виртуаль дәлиле, чөнки үзебезне фотога төшергәндә нәкъ әлеге сыйфатларыбызны күрсәтергә омтылабыз. Шул рәвешле, без үзебезне сатуга куябыз кебек (социаль челтәрләрдә акча эшләү чарасы да шуңа корылган түгелме соң?!) Юк, юк, болай гына төшәбез дип үзегезне алдарга тырышмагыз. Һәр эшнең максаты бар! Селфи төшүнең дә. Социаль челтәрләрдә иң чибәре, иң яхшысы, иң популяры булу өчен уен бара. Селфи – шул уенда бер корал!

Тарих битләреннән

Танылган кешеләр арасында беренче селфины бөек рус язучысы Лев Толстой төшерә. Ул вакытта бик сирәк булган фотоаппаратны язучы 1862 елда сатып ала һәм автопортретын ясый. Фото почмагына «Үз-үземне төшердем» дип язып куя. Агач камераның зурлыгын күз алдына китерер өчен: Ясная Поляна мәктәбендәге бер укытучыга биреп торганда, аны ике ат җигелгән арба белән алып киткәннәр. Әлеге сурәт Толстой исемендәге Дәүләт музеенда саклана. Толстойның сигез мең фотосы арасында селфи да бар.

Заманында бу хакта сөйләргә ярамаган. Ә хәзер... Хәзер ярый, тик... күзгә күз очрашып сөйләшергә бүген ул үзе генә юк. Бик сирәкләрнең генә батырлыгы үз вакытында бәяләнәдер, мөгаен. Разведчикларныкы бигрәк тә. Сугыш барганда серне чишәргә ярамый. Еллар үтеп, документлардан «үтә серле» мөһере алынгач, инде соңга калынган була.



Лилия ГӘРӘЕВА

23 ЯШЬЛЕК «ГЕНЕРАЛ»

Без – милли геройларыбыздан Муса Җәлилне, Газинур Гафиятуллинны, Абдулла Алишларны танып үскән буын. Алар арасында Даян Мурзин дигән кешенең исеме юк иде. Югыйсә Чехословакиядә Герой дигән аты бар, Злин шәһәренең бер урамы аның исемен йөртә, ул – Чехия, Словакия, Моравиянең 16 шәһәрендә почетлы гражданин. Англия, Германия, Чехия, Россиядә аның турында фильмнар төшерелгән, әсәрләр язылган. Әле үзе исән чагында ук Готвальдов шәһәрендә бронза һәйкәл куелган. Инглизләр аны Джеймс Бондка тиңли... Гап-гади бер татар егетенең Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары – тарих китабының укылмый калган битләре.

Гап-гади дидем дә, ялгышканымны аңлап, туктап калдым. Башкортстанның Бакалы районы Иске Балыклы авылында крестьян гаиләсендә туып-үскән бу укытучы егетне гади дип әйтү дөрес булмастыр ул. Педагогика училищесын тәмамлаган Даянны егермесе дә тулмаган килеш мәктәп директоры итеп куялар. Илдә фин сугышы бара. «Ир бурычы – ил саклау», – дип, армиядән яңа кайткан Даян Баян улы Мурзин үзе теләп өстенә кабат шинель кия. Яуда катнашырга насыйп булмый аңа, ул барып җиткәнче сугыш бетеп китә. Гаярьлеге йөрткәндер, егет Ригадагы хәрби училищега юнәлә. Бөек Ватан сугышын 10 нчы укчы дивизиянең взвод командиры булып каршылый.

1941 елның 22 июне. Баганалардагы «кара тәлинкә»ләр илгә көтмәгәндә дошман явы бәреп керүен хәбәр итә. Тик чик буендагылар өчен көтелмәгән булмый бу көн.

ДАЯН МУРЗИН ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН: *«Бөек Ватан сугышы минем өчен 19 июнь көнне башланды. Безне көтмәгәндә Орт-Крейтинг шәһәренә күчерделәр. 20 июньдә взвод командиры Харченко бер-ике көннән сугыш башланасын әйтте. Бу хакта ике немец коммунисты хәбәр иткән икән. Окоплар казыганда да без әле моңа ышанмадык. 21 июнь төнен окопларда уздырдык. Иртәнге*

дүрттә баш өстебездән үкереп немец самолетлары очып узды. Сәгать алтыда дошман танклары күренде. Коточкыч куркыныч көн иде ул: күктә самолетлар үкерә, танклар гөрселди, баш өстендә пулялар сызгыра, яралылар ыңгыраша. Дошман күп һәм көчле иде. Без ул көнне бик күп солдатны югалттык».

Шул көнне яшь солдат сугышның иң ачы сабагын үзләштерә: син үтермәсәң, сине үтерәчәкләр.

ДАЯН МУРЗИН ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН: *«Рига вокзалында немец солдатлары белән кул сугышы башланды. Штык белән арттан башыма китереп сuктылар. Күпме ятканымны хәтерләмим. Безнекеләр вокзалны фашистлардан азат иткәч, мине плащ-палаткага салып алып чыктылар. «Атыгыз», – дим. Ләкин берсенең дә кулы күтәрелмәде. Исән каласыма да ышанганнардыр димим. Мине урман буендагы канауда калдырып киттеләр. Ике көннән һушыма килдем. Яңгыр сибәли иде. Ничек кирәк алай юл буена үрмәләп чыктым. Арбасына сөт бидоннары төягән бер латыш кешесе табып алып, мине балалар хастаханәсенә илтеп тапшырды».*

Үлем кочагыннан бу юлы әнә шулай котылып кала ул. Ләкин сугыш кырында Газраилнең тозаклары – адым саен. Немецлар җир бетереп яралы солдатларны эзли. Һәр йорт, һәр бина тентелә. Кулга алынганнар йә үтерелә, эшкә ярардайлары лагерьларга озатыла.

ДАЯН МУРЗИН ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН: *«Немецлар Риганы алды. Монда калу куркыныч иде. Бер дустым белән икәүләп качтык. Минскига җитәрәк безне тоттылар. Әсирлек һәм кабат хастаханә. Бәхетебезгә, андагы шәфкать туташы якташ булып чыкты. Вера исемле. Ул, икебезгә дә киемнәр юнәтеп, төнге икедә безне арткы ишектән чыгарып җибәрде».*

Егетләрнең максаты бер: үзебезнең фронтны куып җитәргә. Партизаннарның «За Родину» отрядына Даян Мурзин әнә шул вакытта килеп эләгә. Украинаның Ямполь тирәләре була ул.

ДАЯН МУРЗИН ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН: *«Немецлар монда коммунистларны алып килеп асалар иде. Димәк, аларны кемдер сата. Без бер укытучыны таптык. Аның аша немец теле укытучысының һәм тагын бер педагогның немецларга эшләвен ачыкладык. Мин үзем дә педагог, коммунист. Балаларга белем биргән кешенең мондый намуссызлыгы башыма сыймый. «Моның өчен нинди җәза бирик?» – дигәч, бөтен кеше күрерлек җиргә асарга кирәк, диделәр. Хыянәтче үз җәзасын алды».*

Партизаннарның эшчәнлеге турында фашистларга да барып ирешә. Яшерен отрядларны тар-мар итү өчен бу тирәләргә Төркестан легионы китерелә. Тарихтан беләбез: легионнарда фашистларга әсирлеккә төшкән яки алар ягына үзләре теләп чыккан үз ватандашларыбыз. Партизаннар отрядына яңа максат билгеләнә – легионнарга үтеп кереп, аларны үз ягыбызга аударырга. Моның өчен төрки-мөселманнар белән уртак тел табардай агент кирәк. Ул кеше Даян Мурзин була.

Аның гомере өчен Гитлер 2 миллион рейхсмарка вәгъдә итә



■ Дошманнары өчен генә түгел, үзебезнекеләр өчен дә серле бер зат була Даян Мурзин. Аңа чынлыкта ничә яшь икәнен беркем дә белми. Хәтта булачак хатыны – партизанка Надежда Ермакова (уртада) да аны зур гаилә башлыгы булган өлкән ир дип уйлый. Үзенә кушамат булып ябышкан кара сакалын егет юри үстерә.

ДАЯН МУРЗИН ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН: *«Легионга мин Глухов пединституты студенты Юрий исеме белән барып кердем. Элемтәчем казакъ егете иде. Икебез дә русча сөйләшәбез. Аның аша Сталинград юнәлешендәге сугышларда катнашу өчен Идел–Урал легионы төзелгәнен белеп алдык. Бу хакта шунда ук Мәскәүгә хәбәр ителде. Легионерларның күбесе – коммунистлар. Кире үз ягыбызга чыгарга теләүчеләре күп иде. Алар өчен махсус коридор ачтылар. Иң алдан, Кызыл армия сафына кучучеләрнең исемлеген тотып, мин барам. Минем артта – немец формасындагы легионерлар...»*

1943-1944 елның көз-кыш айларында Төркестан һәм Идел–Урал легионы сугышчылары Кызыл армия ягына күчә. Аларның үзебезнекеләргә каршы сугышка кермәвендә батыр йөрәкле татар егетенең дә тырышлыгы бик зур. 1943 елның декабрендә Даянга яңа бурыч йөкләнә – оккупациядәге Молдавия җирләрендә партизаннар отряды төзергә. Ул шушы тарафка юнәлүче Кызыл армиягә булышлык күрсәтергә тиеш була.

ДАЯН МУРЗИН ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН: *«Ярдәмгә 8 кешелек отряд бирделәр. Одесса өстеннән очканда самолетка зыян килде. Летчик аптырашта, кире борылыргамы? «Кайсы тирәгә җиттек әле?» – дим. Молдавия чигенә якынлашканбыз икән. Шушында безне төшереп калдырырга куштым. Биш көн дигәндә без 130 кешелек отряд туплый алдык. Иң мөһиме – көтмәгәндә һөҗүм итү. Кичке тугыз-уннар тирәсендә һөҗүмгә күчтек. Румыннарның яртысы качты, яртысы бирелде. Ә немецларны яртылаш кырып салдык. Шунда ук отрядка халык агыла башлады. Тагын бер көннән безнең сафларда 650 кеше иде инде. Комендатураларны, полиция участокларын, корал складларын яндырдык, эшелоннар юл читенә капланды... Анда армия дә килеп җитеп, бергәләп Сороки шәһәрен алдык».*

Бу хәл штабтагыларны да хәйран калдыра. Мәгълүматны раслар өчен бирегә генерал Алексей Асмоловны җибәрәләр. 1944 елны Даян Мурзин Кызыл Байрак

Карап торышка кырыкны бирердәй бу егеткә нибары 23 яшь була.

ордены белән бүләкләнә. Фронт сызыгы инде үз чикләребезне үтеп, Германия юнәлешендә сугыша.

1943 елны КОМИНТЕРН таратыла. Оешма таркатылса да, разведчиклар әзерләүче яшерен мәктәпләре барыбер кала әле. Шундый мәктәпләрнең берсенә Даян Баян улына да юллама бирелә. Ул инде үз миссиясе тәмамлангандыр дисә, ил аның алдына тагын катлаулы бурыч куя. Бу юлы – Чехословакия.

ДАЯН МУРЗИН ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН: *«Безне Склабина авылы янында төшерделәр. Бер әйберне исәпләмәгәндә, бар да уңышлы узды. Парашютым белән агачка эләгеп калдым. Каешларны кисүем булды, башым белән ташка егылдым. Каяндыр бер хатын-кыз йөгереп килеп җитте. Үзе йөгерә, үзе кычкыра: «Без сезне көттек! Без сезне көттек!»*

Бернинә көн эчендә десантчылар 3000 кешелек партизан отряды туплый.

1944 елның августында Даян өчен сугышның яңа этабы башлана. Ул җитәкчелек иткән Ян Жижка исемендәге партизаннар отрядына Моравиягә күчәргә приказ бирелә. Моравиянең сәнәгать районнары немецлар өчен стратегик әһәмияткә ия җирләрдән була. Зур корбаннар бәрабәренә үтеп кергән Ян Жижка отрядына кадәр монда бер генә партизан отряды да аяк басмый.

ДАЯН МУРЗИН ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН: *«Безнең бригада фашист объектларын тар-мар итүне дәвам итте. Партизаннарга каршы тора алмаулары гитлерчыларны чыгырыннан чыгара иде. Максатларына ирешү өчен, алар безнең сафларга үз агентларын кертү ниятенә керештә. Шундый агентларның берсе – Дворжек фамилиялесе чактан гына безнең башка җитми калды. Ул безгә Прагадан килде. Күңелем шунда ук аның безнең кеше түгелен сизенде. Ләкин командир Ян Ушьяк, никтер, ышанды аңа. Дворжек беркөнне әйтә: «Сезнең белән Үзәк Комитет кешесе очрашырга тели», – ди. Сүзләренең чынлыгына шикләнсәм дә, мин, Ушьяк һәм бернигә сугышчы очрашуга киттек. Без алдан барабыз, ә Дворжек – арттан. Сизенүем расланды, ул безне туп-туры засадага алып килгән булып чыкты. Каршыбызга таза гына ир чыгып, кулын сузуга, атыш башланды. Беренче булып Ушьяк яраланды. Мин чоңгылга сикердем. Алай да дошман ядрәсе аягыма тиеп өлгерде».*

Немецлар тентемәгән бер генә йорт, бер генә куак, бер чокыр да калмый. Аю өненә яшеренгән җирдән ул барысын да күреп ята. Хәтта печән эскертләренә кадәр яндыралар, тик аны таба алмыйлар.

ДАЯН МУРЗИН ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН: *«Аягым бик каты шеште. Ә безнекеләр һаман юк. Пистолет түтәсе белән компасымны ватып, иң үткен кыйпылчыгын сайлап алдым да, күзләремне чытырдатып йомып, ярага батырдым. Аяктан шаулап кан китте, сызлавы бераз кимеде кебек. «Отряд белән ни булды? Ушьяк исән кала алганмы?» – бу көннәрдә мин бары шул хакта гына уйладым. Бернигә көннән мине егетләр эзләп тапты. Ушьякны атканнар, отряд тар-мар ителгән, ә Дворжек качкан...»*

1944 елның ноябрендә немецлар, җиң сызганып, партизаннарны эзәрлекләү эшенә керешә. Коткаручыларын сатмаган авыллар җир белән тигезләнә, кешеләре терелэй яндырыла. «Кара генерал» – Гитлерның шәхси дошманына әверелә. Әйе, дошманнары аңа шундый исем тага. Нәкъ менә аның аркасында фюрерның Прагадагы сәфәре өзелә. «Кара генерал»ны юк итүчегә миллионнар вәгъдә итә ул. Күктән меңләгән листовка ява: «Тере «генерал» өчен – 3 миллион, үлесе өчен 2 миллион марка». Моның кадәр зур отряд белән нибары капитан гына идарә итәдер дигән уй немецларның башларына да килми.

Сугыштан соң Даян Мурзин Башкортстан АССРның Бакалы районы халык мәгарифе бүлегендә эшли. Казан хокук мәктәбен һәм Бөтенсоюз юридик институтны тәмамлагач, өлкән тикшерүчедән башлап, Башкортстанның эчке эшләр министры урынбасары дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Бөек Җиңүнең 60 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә Россия Президенты Владимир Путин легендар «генерал» белән үзе шәхсән таныша. Әлегә кадәр аның түшен СССР һәм Россия Героеның Алтын Йолдызы бизәмәүгә бик аптырый ул.

Даян Мурзин 91 яшенә кадәр Уфа шәһәрендә гомер итеп дөнья куя. Үзе туып-үскән авылда аның исемен йөрткән урам бар. Ләкин ул яшәгән йортка әле дә булса истәлек тактасы куелмаган.



■ Радистка һәм тәрҗемәче, Кызыл Йолдыз ордены иясе Надежда белән алар сугышта таныша. 1944 елның октябрендә Надя хезмәт иткән партизаннар отряды дошман тылына җибәрелә. Десант вакытында кыз уңышсызлыкка юлыга, парашюты агачларга уралып, ул бик нык имгәнә. Даян Мурзин кешеләре аны шул хәлендә урманда табып ала да инде. Алар 1945 елның 9 маенда өйләнешә. 23 яшьлек татар егетенә кияүгә чыгуын кәләш шунда гына белә.

P. S. *Язмада Даян Мурзин истәлекләре һәм Карина Галләмованың «Уроки войны. Великая Отечественная война в судьбе нашей семьи» рефераты файдаланылды. Ветеранның оныгы Альбина Мурзинага, Башкортстанның Бакалы районы Ахман гомуми белем бирү мәктәбенең туган якны өйрәнү музеена рәхмәт белдерәбез.*

ОФИЦИАНТ БУЛЫР ӨЧЕН ЗӘВЫК КИРӘК!

«Мин тәрҗемәче булырга хыялланган идем. Тик баллар җитмәү сәбәпле, Казан сәүдә-икътисад техникумына укырга кердем. Ресторан менеджеры булып эшләгән апам киңәшен тотып, җәмәгать туклануында хезмәт күрсәтүне оештыру юнәлешен сайладым. Мәктәптә яхшы укысам да, белем алуны техникумда дәвам итүемә баштарак бик кыенсындым, тик WorldSkills хәрәкәтенә кушылгач, уйларым үзгәрде», – дип сөйли WorldSkills Russia эшче һөнәрләре бәйгесендә «Ресторан сервисы» компетенциясендә беренче урынны алган Казан кызы Айсылу Нуретдинова. Татарстанда ресторан бизнесы буенча ул хәзер иң каттә яшь белгеч. Мастер-класслар үткәреп, башкаларга һөнәри яктан үсәргә ярдәм итә.







Республикада рестораннар күп, ләкин сервис камил дәрәҗәдә түгел. Официант, бармен хезмәте дә студентлар өчен өстәмә акча табу юлы дип кенә кабул ителә. Ә ул бит үзе бер культура. Моны Айсылу WorldSkills хәрәкәтенә кушылгач кына аңлый. Техникумның беренче курсында укый башлауга ук бу бәйге турында уку йортының сайтыннан укый, кызыксына башлый. Теләгең бик зур икән, сиңа бөтен җиһан ярдәм итә дигән сүзләр хактыр. Дәрестә бик матур итеп чыгыш ясаганын күреп, аны хәрәкәткә кушылырга чакыралар. Һәм аның өчен яңа тормыш башлана. Берөзлексез өйрәнүләр, сынаулар бәйгеләр... Ул төбәк турында җиңеп, Татарстан җыелма командасына керә. Россия беренчелегенә әзерләнә башлый. «Ресторан сервисы» компетенциясе дүрт төрле юнәлешне үз эченә ала: официант, бармен, бариста һәм сомелье эшләре. Бәйгедә алар коктейль, кофе ясап күрсәтергә, шәрабны исеннән сортларга аерырга, өстәл сервировкалап, кунакларга хезмәт күрсәтергә тиеш булалар. Өстәл бизәүнең бер кыенлыгы юк дип әйтүчеләргә: әллә ничә төрле кашыкчәнечке генә бар! Аларны симметрияле итеп куярга кирәк – һәр сантиметр күз уңында. Үз эшен яратып, җиренә җиткереп башкарса да, ялгышып, командасын уңайсыз хәлгә куюдан курка Айсылу. Җитмәсә, әзерлек вакытында мәңгелек йөрәк ярасына тагын бер яра өстәлә – игезәге юл һәлакәтендә үлә. Әнә шул кайгыларны җиңәргә дә булышмый микән әле аңа WorldSkills?! Булган өметләрне акларга, куйган максатларга берничә карамый ирешергә кирәк. Тырышлыгы бушка китми: Сахалинда узган Россия беренчелегендә үз компетенциясендә беренче урынны алып, Россиядә иң яхшы профессионал исеменә лаек була. Җиңү аңа Италия чемпионатына юл ача. Ресторан сервисы буенча бөтен Европадан җыелган иң яхшы 13 катнашучы арасында 4 нче урынны ала. WorldSkills хәрәкәтендә дүрт ел эчендә илнең бик күп шәһәрләрендә булырга туры килә Айсылуга. Хәзер аның дуслары бөтен Россия буйлап чәчелгән. Кая гына чыгып китсә дә – белә: анда аны иптәшләре каршылаячак, ярдәм итәчәк. Әлеге хәрәкәт – яшьләр арасында дуслык күпере салучы да. Ә сәяхәтләр тормышта яңа максатлар куярга илһамландыра... «Мин институтта бу кадәр тәҗрибә туплый алмас идем. Моның өчен техникумыма да, WorldSkills хәрәкәтенә дә чиксез рәхмәтлемен. Бу чор – тормышымдагы иң шәп вакыт», – ди Айсылу. Хәзер ул үз компетенциясендә эксперт та, тренер да. WorldSkills хәрәкәтеннән китәсе килми: башкаларны бәйгегә әзерли. Югары белем алу кирәклеген дә аңлый. Үз һөнәрен теоретик яктан да үстерер өчен читтән торып югары уку йортына укырга керергә җыена. Бүген Айсылу ресторан сервисы өлкәсендә алыштыргысыз белгеч. Аны мәртәбәле рестораннарга эшкә чакыралар, ул төрле мастер-класслар үткәрә. Хыялы – үзенең бизнесын ачу. Анда нинди дәрәҗәдәге сервис буласын күз алдына китерү кыен түгел инде. «Италиягә баргач, еладым, – ди Айсылу. – Анда ресторан сервисына яшьтән үк өйрәнәләр. Бу өлкәдә кешеләрдә зәвык тәрбияләнә. Ә бездә җәмәгать туклануы һөнәрләренә икенче сортлы итеп кенә карыйлар. Италиядә өлкән буын кешеләре ресторанда клиентларга хезмәт күрсәтә. Әлбәттә, иң югары дәрәҗәдә! Чөнки алар үз эшләренең осталары, үз эшләре белән горурланалар». Россиядә ресторан сервисы буенча мәктәп ачу турында уйланалар. Айсылу шунда укытырга тели. Үзе белгәннәрне башкаларга өйрәтәсе, рестораннарда сервисны югары дәрәҗәгә күтәрәсе килә аның.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА



Эльмира ЗАКИРОВА

АЛАБУГАНЫ САКЛАУЧЫ ФӘРЕШТӘ

Алабугада булганыгыз бармы сезнең? Ул хәзер бөтенләй башка! Татарстанда гына түгел, Россия, дөнья күләмендә туристларны үзенә тартып тора торган шәһәр. Европаның иң яхшы музейларының берсе. Тикмәгә генә аны Чулман буеның энҗе бөртеге дип йөртмиләр шул инде! Регионның, Россиянең, ниһаять, Европаның иң яхшы музее исемнәренә лаек булу үзе үк күп нәрсә сөйли…

Чулман буеның энҗе бөртеге

Бу шәһәргә аяк басуга ук заман шау-шуы өреп очыргандай кинәт юкка чыга. Син инде XIX гасырның сәүдәгәрләр шәһәрендә. Ике катлы зәңгәрсу йортлар, борынгы фонарьлар, кояшта алтындай ялтырап күренгән чиркәү гөмбәзләре, кәрнизләре челтәрләп эшләнгән тәрәзәләр, чуен рәшәткәләр, сәүдә рәтләре… Еракта, калкулыкта – Кама белән Тойма кушылган биек ярда – серле Шайтан шәһәрчеге җәйрәп ята. Ашыкмый гына тын урамнардан атлыйсың…

Бизәкле капкалар бөек рәссам Шишкинның балачагы узган йортка чакыра. Рәссамның әнисе Дарья Романовна образына кереп, музей хезмәткәре туристларны каршылый. Йорт террасасыннан күренгән зәңгәр елга-күлләр, яшел болын-урманнар күзне иркәли. Ул күренешләр булачак рәссамны да әнә шулай сокландырган, илһамландырган…

Мәскәү урамындагы бу йортта Дурова яшәгән. Өеннән чыгып качып, 1812 елгы Ватан сугышында офицер ир-ат булып катнашкан җайдак-кыз Надежда Дурова! Кутузовның ординарецы булган ул. «Записки кавалерист-девицы» әсәрен югары бәяләп, Пушкин Надежда Дуровага хатлар язган.

Атаклы психоневролог Бехтерев та Алабуга төбәгендә туган. Өяз медицинасы музее аның исемен йөртә. Шәфкать туташлары, аптекарьлар, төрле үләннәр белән дәвалаучы әбиләр – бар да музей хезмәткәрләре.

Һәм нибары ун гына көн Алабугада яшәп, гомере шунда өзелгән Марина Цветаева. Бу йортта шагыйрьнең шәхси әйберләре, соңгы язмаларын саклаган дәфтәр…

Көмеш гасыр китапханәсе, «Портомойня» музее, Күргәзмәләр залы, Заманча этносәнгать музее, Хәтер музее, Декоратив-гамәли сәнгать музейостаханәсе… Казан, Спас, Яр буе, Зур Покрау, Гассар урамнары буйлап сузылган тарихи музей кварталы театр декорациясе сыман: XIX йөздә төзелгән йортлардан дворяннарча киенгән сәүдәгәрләр килеп чыгар да үзләре белән алып китәр сыман. Шәһәр тарихы музеенда инде шул дөньяда йөзәсең…

Күр инде бу XIX йөзнең интерактив фотоательесын! Сәүдәгәрләр белән чәй эчеп утырган рәвештә борынгы салоннар стилендә мин дә фотога төшәм. «Трактир» музей-театрында – шул чор рестораны. Имән өстәлләр, борынгы самавырлар, фарфор савыт-саба… Романслар яңгырый. Кайнар коймаклар белән үлән чәе эчәм… Сәүдәгәрләр шәһәре Алабуга буенча сәяхәт «Сәнгать салоны» музей кибетендә сувенирлар сайлау белән тәмамлана. Осталар теккән чигүле сумка күңелемә аеруча хуш килә…

Кураж белән эшләргә кирәк!

Чып-чын шәһәр-музей. Шәһәр-әкият. Искиткеч матур! Могҗиза дисәң дә могҗиза! Мин бүген шул могҗизаны тудыручылар янында. Моннан 30 ел элек,

1989 елда бу якларның бай тарихи-мәдәни мирасын саклау максатларында Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы ачыла. Менә 17 ел инде Алабуга музей-тыюлыгы белән аның генераль директоры Гөлзада Рәкыйп кызы Руденко җитәкчелек итә. Тәҗрибәле, талантлы, тәвәккәл, зирәк, булдыра торган җитәкче. Алабуга исемен яңгырату, музей-тыюлыкны таныту, шәһәргә йөз меңләгән туристларны җәлеп итү өчен ничек кенә хыялланмый, нинди генә планнар кормый,ниләр генә уйлап тапмый ул! Кайда нинди мөмкинлек бар, кайда җай чыга, гел Алабуга турында гына сөйләп торыр иде! Мондагы матурлык, тәртип, зәвык, затлылык... Күпләр аның үзен Алабуганың саклаучы фәрештәсе дип йөртәләр. Чаллыда яши, Алабугада эшли. Юк, икесендә дә яши дә, эшли дә дисәк, дөресрәктер. Актив җәмәгать эшлеклесе. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Иҗтимагый палата рәисе урынбасары, Россиянең кечкенә туристик шәһәрләре ассоциациясе әгъзасы, Чаллы шәһәре хатын-кызлары ассоциациясе рәисе... Алабуга шәһәр мэрының туризм һәм мәдәни мирасны саклау буенча урынбасары. Россия музейлар берлеге президиумы әгъзасы. 2018 елгы сайлауларда Президентлыкка кандидат Владимир Путинның ышанычлысы... Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Гөлзада Руденконың Россия, халыкара дәрәҗәдәге бүләкләрен санап бетерерлек түгел. Бүгенге көндә Алабуга дәүләт музей-тыюлыгында 16 музей объекты бар.

Алабуга музей-тыюлыгын дөнья күләмендә танытуга ничек ирешә алганнар? Уңышларның сере нәрсәдә? Тормышта нindирәк икән бу Гөлзада ханым?

...Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы директорының эше аеруча тыгыз вакытка туры килдек. Әле генә Борис Березовскийның «Летние вечера в Елабуге» халыкара музыка фестивале тәмамланып, инде Бөтенроссия Спас ярминкәсенә һәм «Колокольный звон» фестиваленә санаулы гына көннәр калган чак. Шәһәр-музейда урак өсте! Бөтен коллектив, ягъни 165 кеше эшкә күмелгән. 32 экскурсиягә инде заказ бар ул көнгә. Димәк, 32 экскурсовод килгән кунаклар күңелен күрәчәк. Хәер, Алабугада унлап таксист та гид ролендә шәһәр белән таныштырып йөри ала. Махсус әзерләгәннәр. Аның өчен өстәмә түлиләр. Монысын да Руденко уйлап тапкан. Гөлзада Рәкыйп кызы белән күрешкәнче үк тә музей хезмәткәрләре сөйләгәннәрдән әллә никадәр мәгълүмат алдым. Биредә экскурсоводлар аерым бер катлам икән. Барысы да белемле, әзерлекле, зыялы. Эшләре дә кызыклы, дәрәҗәле. Ак кофта, кара итәк йә чалбар, зәңгәр шарф – экскурсоводлар өчен дресс-код шундый. Алабуга экскурсоводлары Россиядә иң беренче булып микрофоннар белән тәэмин ителгән. Гидлар төрле аудитория өчен яраклашкан. Һәм аларның чыгышы методикасы белән бер-берсеннән аерыла. Балалар өчен, өлкәннәр өчен, чит ил туристлары өчен махсуслашканнары бар. Музей-тыюлык әле яңа оешып

Ул дөньяның атаклы шәһәрләре белән ярышырлык!



Алабуга дәүләт музей-тыюлыгында узган гасырлар мирасын саклау һәм популярлаштыру эшенә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов гаять зур ярдәм күрсәтә

кына килгән мәлдә кызлардан: «Сез кайда эшлисез?» – дип сорыйлар икән. «Музейда, экскурсовод булып», дигәч, «И-и-и!» – дип кызгану белдерәләр. Ә хәзер шул ук җавапка: «О-о-о!» – дип сокланалар! Имидж шундый югары, эш бик дәрәҗәле!

«Сезнең экскурсоводлар югары квалификацияле. Эшләрен, музейны, Алабуганы яратканнары сизелеп тора!» – диләр һәрчак. Монысы да Руденко мәктәбе! Масштаблы уйлый белгән кешеләрне җыя ул командасына. «Кураж булырга тиеш эштә!» – дип гел искә төшереп тора. Шәһәргә килүчеләргә Алабуга көннән-көн кызыклырак күренсен өчен алар күп эшли. Һәм аларны сайлап алалар! Бар кеше дә бу эшне булдыра алмый. Яңа кешегә экскурсовод булып бер ай эшләгәннән соң, аттестация уздырыла. Барып чыкмаса, аны башка юнәлешкә билгелиләр. Ә болай генераль директордан башлап кадрлар бүлеге начальнигына кадәр экскурсияләр үткәрә икән. Лондон йә Берлин, Истанбул йә Париж, Мәскәү, Питер, Самара, Екатеринбург, Уфа, Казан... Алабуга экскурсоводлары үзләре дә бу шәһәрләргә командировкаларга бара, музейларда була, өйрәнәләр, эзләнәләр...

Яңа причал әзер!

Белә сегез килсә, хәзер Алабугага туристик теплоходлар туктала! Аның өр-яңа причалы бар! Ничек кенә хыялланмый Гөлзада бу көн турында! Ак теплоходлар төшләренә керә хәтта. Ә тарихы болайрак. 18 ел элек туристик теплоходлар Түбән Кама пристанена туктый да, туристлар сәгать ярым автобуста Алабугага килеп, Шишкин музеен карарга гына өлгерә. Аннары тагын сәгать ярым теплоходка кайтасы. Өч сәгать вакыт җилгә оча! Алабуганы бөтенләй күрә алмый кунаклар! Директор булып килгәч тә, Гөлзада Рәкыйп кызының җаны әрни бу хәлгә. Проблеманы күтәрергә җай да чыга! Мәскәүгә киңәшмәгә баргач, круиз компанияләренең маршрутларын билгеләп утырганда, Руденко

Моннан 30 ел элек Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы ачыла!

торып баса да: «Алабугага килегез! Бездә Шишкин, Дурова, Цветаева... Киләсе елга дебаркадер да булачак!» – дип ярып сала. Сораулар яудыра башлыйлар. «Нинди модификациядәгесе, ничә квадрат метр...» Аңлап та бетерә торган түгел. Ләкин директор югалып калмый: «Соравыгызга җавап бирә алмыйм. Ләкин дебаркадер булачак!» – дип өздереп әйтә.

...Хәзер инде алар елына 150–170 теплоход кабул итә. Бөтен Россия буенча 200 дән артык туроператор белән хезмәттәшлек итәләр. Моннан 25 ел элек Алабуга пристане булган урында яңа причал ачылачак. Моның өчен Алабуганың мэры Геннадий Егорович Емельянов күп көч кертте. Килгән кешеләр дә елдан-ел арта. 2002 елда 19 мең кеше килгән булса, 2018 елда ул сан 505 меңгә җитә. Туризм сферасында эш җайга салына. Музей-тыюлыкның кереме дә арта. 2002 елда 159 мең сум булса, 2018 елга ул 34 миллион 403 мең сум тәшкил итә!

Хәтер дулкынында

Ниһаять, Гөлзада Рәкыйп кызы белән сөйләшеп утырырга җай чыга. Моннан берничә ел элек аның юбилеен «Минем хәтер дулкынында» дигән кичә итеп оештыралар. Тормышының шул кичәдә гәүдәләнгән кайбер мизгелләре күз алдыннан уза. Ул сөйли, мин тыңлыйм.

«Кайларда, кем булып эшләсәм дә, коллегаларым дусларыма әйләнде. Дусларым бик күп! Мин бәхетле!

Арча районы Үрнәк авылында тудым. Лесхозга җәяү йөреп, рус мәктәбендә укыдым. Чая, үзсүзле идем. Хәтта малайлар курка иде миннән. Бәләкәйдән үк укытучы булырга хыялландым. Сигезенчедән соң Арча педучилищесына укырга кереп кайттым. Нәкъ шул җәйне әтигә Алабугадагы СПТУда директор урынбасары эшен тәкъдим иттеләр. Мине дә үземне генә Арчага чыгарып җибәрәселәре килмәде бугай – әти белән әни җыена башлады. Әле дә күз алдымда: 1971 елның 30 августы иде. Минем туган көндә, йөк машинасына төялеп, әти-әни, мин, энем Рафил, сеңлем Лилия Кама буендагы шәһәргә күчеп киттек. Анда 1 нче мәктәпне тәмамлагач, Алабуга пединститутының физматына укырга кердем. Чит телләр факультетында укыйсым килә иде. Немец телен бик яратсам да, математика укытучысы белән әни, техник фәннәр дәрәҗәлерәк, дигән булып, мине физматка кодаладылар. Еллар узгач кына әни серне чиште: институтта инглиз теле буенча биш төркемгә кабул иткәннәр, ә немец теле төркеме берәү генә икән. Керүчеләр исемлеге алдан ук әзер булган... Институтта комсомол комитетына сайлап куйдылар. Студентлар отряды белән 80 кызны Әстерханга помидор җыярга алып киттем. Башта отрядның комиссары идем, аннары командир булдым».

«Минем Чаллыда яшисем килә иде. Диплом алгач, группадаш Чаллы кызы белән ПТУлар, мәктәпләр буенча эш эзләп йөрдек. Хәтта балигъ булмаган балалар инспекциясендә дә эшләргә исәп бар иде... Муса Җәлил проспекты буйлап барганда күземә язу чалынды: Чаллы шәһәре Комсомол районының ВЛКСМ район комитеты. «Сездә эшләргә телим», – дип барып кердем. Беренче секретарь кабул итте, сөйләшеп утырды. «Без сине алабыз эшкә, ләкин бүген үк Казанга зона комсомол мәктәбенә укырга китәргә кирәк», – диде. Менә шулай уйламаганда, көтмәгәндә! Очраклы нәрсәләр тормышта булмыйдыр ул, мөгаен. Юк, мөгаен түгел, дөресе дә шул!..»

Укып кайткач инде, Гөлзада Мөбарәкшинаны пропаганда бүлегенә инструктор, аннары III секретарь, бераздан II секретарь итеп куялар. 1984 елда КПССның Комсомол райкомында эшли башлый. Аннары – «Камгэсэнергострой» парткомы. «Эврика» мәдәният үзәген җитәкләү. Чаллы мэриясенең мәдәният-сәнгать идарәсе башлыгы булып эшләгән еллар. «Леон-ТУР» туристлык компаниясе генераль директоры. Һәм 2002 елдан – Алабуга дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгының генераль директоры.



Россия музейлар берлеге президенты, Дәүләт Эрмитажы директоры М. Б. Пиотровский Алабугада Россия музейлар берлеге вәкилләре арасында. Апрель, 2019 ел.



Алтынчы агрегатта өйләнештек, җиденчедә улыбыз туды...

«Җитәкче кешелекле булырга тиеш дигән кагыйдә балачактан сеңгән. Гомер буе сәүдә системасында җитәкче булып эшләгән, оештыру эшенә сәләтле әнием Язилә Нәби кызы Мөбаракшина бик зирәк хатын иде. «Кызым, эшеңдәгеләрне берүк рәнҗетә күрмә!» – дип гел әйтә килде. Әтием Рәкыйп Мөбаракша улы Мөбаракшин – чын укытучы, чын интеллигент. Әти дә шул ук сүзләрне кабатлый: «Ачуланма! Каты бәрелмә!» – ди. Һәрчак истә тотам киңәшләрен, рәхмәт аларга!»

«Булачак ирем Александр Руденко белән дусларның туган көнендә таныштык. Саша – энергетик, Түбән Кама ГЭСында гидрокөч җиһазларын монтажлаучы мастер-прораб иде. Бөтенсоюз «Спецгидроэнергомонтаж» тресты вәкиле, гидроэлектростанцияләрдә монтажлау, реконструкцияләү белән шөгыльләнә. Бөтен СССРда нибары 3 мең белгеч иде алар. Менә шундый сирәк һөнәр иясе. Октябрьдә өйләнештек. Сашаның җитәкчесе шул вакыт миңа: «Хәрби кешегә генә дә чыкмыйсың, командировкалардан кайтып та керми торган егет белән яши башлыйсың!» – дип, тормышның нindирәк буласын сиздереп куйды. Туйдан соң ул яңа агрегат эшләргә китте, ә мин комсомолның отчет-сайлау конференциясен әзерләү эшенә чумдым. Икебез дә ялларсыз эшлибез. «Алтынчы агрегатта эшләгәндә өйләнештек, җиденче агрегатта улыбыз туды», – дип хәзер дә еш искә төшерәбез ул елларны. Түбән Кама, Павлов, Чабаксар, Жигулевск, Сергиев-Посад ГЭСлары... Ерак илләргә командировкалар. Сербия, Сирия, Марокко, Эквадор, Һиндстан, Аргентиналар... 1986 елда аны Вьетнамга җибәрделәр. Мин дә киттем. Парткабинет мөдире булып эшләдем. Латин Америкасында – Колумбиядә дә яшәргә туры килде. Александр Леонидович – «Камспецэнерго» директоры, техник фәннәр кандидаты. Россия монтажчылары ул төзегән норматив җыентыклар буенча эшлиләр. Улыбыз Станислав әтисе янында эшли. Чит телләр институтын, Икътисад, идарә һәм хокук институтының юридик факультетын тәмамлады. Инглиз, испан, немец, татар телләрен белә. Мин дә телләр өйрәнергә яратам. Испанча иркен сөйләшәм. Ә Германиягә барсам, бер-ике көннән немец телем «уяна».

Алабуга дәфтәреннән...

«2002 ел, ноябрь. Беренче тапкыр Шишкин музеена килүемне хәтерлим... Аш исе килеп тора, хезмәткәрләр башмаклардан йөри... Һушсыз калдым. Кәеф кырылды. Цветаева исемен йөрткән үзәк бөтенләй шыксыз... Дурова музей-утарында түшәмнән пычкы чүбе коела. Күргәзмәләр залында күселәр чабыша... Шәһәрнең тарих музеена барып керсәм, каршыма киез итекләрдән, билләренә мамык шәл ураган музей хезмәткәрләре чыга. Бинада 12–14 градус кына җылылык... Бөтенесен яңадан торгызырга, үзгәртергә, яңартырга, өр-яңа команда тупларга кирәк иде... Шул вакытта барлыкка килгән иҗади берлек – Алабуга башлыгы Илшат Гафуров, Зилә Вәлиева һәм музей хезмәткәрләре белән мин Алабуганы үзгәрттек. Шәһәребез Татарстанның мәдәният һәм туристлык үзәге статусларын алды».

«Беренчеләрдән булып сәнгать салоны – музей кибетен ачтык. Мин үзем турист кеше. Каядыр барырга, музейлар карап йөрергә яратам. Теләсә кайсы илдә, шәһәрдә сине иң элек сувенирлар янына алып китәләр. Шуны истә тотып, без дә декоратив сәнгать осталарын, рәссамнарны җыйдык... 2005 елда туристлык мәгълүмат үзәген булдырдык. Музей-тыюлык зур мәйдан били – 495 гектар җирдә урнашкан».

«Ташландык урынны чүпләрдән чистартып, «Портомойня» музеен ясадык. Миңа «Алабуга санитары» дигән кушамат тактылар. Анда элек кер юу йорты булган. Шишкинның әтисе, шәһәр башлыгы Иван Васильевич 1833 елда беренче агач суүткәргеч үткәргән».

«Балалар өчен укыту үзәге ачарга хыялланам. Мультимедияле, айти-технологияле, компьютер мөмкинлекләре зур булган... дөнья музейлары буйлап виртуаль сәяхәткә чыгарлык итеп... Моңарчы күрелмәгән, беркайда да булмаган бик кызык музей итеп күз алдына китерәм аны. Һәм ул бердәнбер булачак! Экранлы гаҗәеп планетарий галәм киңлекләренә алып китәр, җир асты, су асты киңлекләрен күзәтер балалар...»

«Алабуга халкының үзенә бер музей мәдәнияте! «Балалар бакчасыннан алып 3400 бала «Музей һәм мәктәп» музей-укыту программасына җәлеп ителгән. Ел саен Алабуганың һәр өченче баласы музей дәресләре аша үтә. Бөтен Татарстан буенча 300 дән артык бала Алабуга тарихына багышланган фәнни-гамәли конференциядә катнашып, фәнни эшләрен якларга безгә килә. Укытучылары, әти-әниләре, әби-бабалары белән бергә киләләр. Алабуга институты профессорлары, фән кандидатлары, музей хезмәткәрләре фәнни җитәкчеләр була. «Я рисую как Шишкин» рәсем конкурсында республикабызның 49 сәнгать мәктәбеннән 800 дән артык укучы катнаша. «Моя Елабуга» викторинасында җиңүче ун бала Россиянең теләсә кайсы музеен барып карау мөмкинлеген ала. Мәктәп балалары гына түгел, өлкәннәр дә үз шәһәренең тарихын белә, музейларга яратып йөри».

«Кешеләр файдасына игелекле эшләр кылырга алынсаң, җае да чыгып тора, акчасы да табыла, юлыңда һәрчак синә булышырдай изге затлар да очрый. Дүрт дистә елдан артыкка сузылган хезмәт юлымда мин шуңа инандым. һәрбер башлангычны күтәреп алган, ярдәм күрсәткән Минтимер Шәймиевкә, Рөстәм Миңнехановка, Зилә Вәлиевага, Илшат Гафуровка, Геннадий Емельяновка, тормыш иптәшемә, күпсанлы дусларыма, иганәчеләремә рәхмәтемне белдерәм».


* * *

Менә шулай. Гөлзада Руденконың тормышы – гел үзгәреп торган гаҗәеп матур эшләр, яңа башлангычлар, йөз меңләгән туристлар, фестивальләр, симпозиумнар, эшлекле очрашулар, ерак илләр, канатлы хыяллар калейдоскобы ул. Ә без шул калейдоскопның кайбер бизәкләрен генә күреп сокландык әле...




Ярты миллионлы тираж белән бөтен союзга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да… Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

ПОЕЗД АВАЗЫ – ЯШЬЛЕГЕМ КАЙТАВАЗЫ




































Фото: Екатерина Самсонова

Эльза ДӘҮЛӘТШИНА:
Сез шалтыраткач, башта каушап калдым. Сөйләшеп бетереп, телефонны куйгач, 1973 елгы ул журналны эзләп таптым мин. Яшь чаклар искә төште. Иң беренче эш көнемнән алып, соңгысына кадәр тимерьюлда үтте. Поезд кычкыртса, яшьлегемнән сәлам тапшырадыр кебек.

«Азат хатын» журналының 1973 елгы август саны тышлыгыннан кызыл кофтадан, комсомол әләме кебек балкып, Әгерҗе локомотивлар депосы технигы булып эшләүче кыз елмая. Ул чагында Эльза Дәүләтшинага (хәзер Исхакова фамилиясен йөртә) нибары 18 генә яшь була әле, мәктәпне тәмамлап кына килгән чагы.

Моннан 46 ел элек булган әлеге вакыйганы бик яхшы хәтерли ул. «Кояшлы матур көн иде. Оешмага журналистлар килгән, диләр. Ул вакытта «замерщик» вазыйфасын башкара идем. Әйдә, фотога төшәбез, дип, мине дә чакырдылар. Кофтаңа туры килә, дип, башыма кемнеңдер яулыгын бәйләттеләр... Бик тиздән ул фото журнал тышлыгында басылып та чыкты. Яшьлегем белән мин аның тормышымдагы нинди зур вакыйга булуын аңлап та бетермәгәнмендер, ниндидер бер гадәти хәл итеп караганмындыр. Ә бит бу нинди зур мәртәбә булган. Танучылар, сине «Азат хатын»да күрдек, дип әйтүчеләр күп булды», – дип сөйли Эльза ханым.

Фотосы журнал тышлыгында дөнья күргәннән соң, Алатырь тимер юл транспорты техникумын тәмамлый ул, булачак ире Флюрны очрата, гаилә кора, уллары туа...

Декрет ялыннан соң, Эльза хезмәт юлын Әгерҗе тимер юл станциясендә дәвам итә. Станциядә кизү тора, диспетчер вазыйфасын башкара... Ул елларда ук инде Әгерҗе зур сортировка тукталышы була. Дүрт юнәлешкә карап кузгалучы поездларга юл ачып, Горький тимер юлының Ижевск бүлегендәге иң мөһим узелы вазыйфасын үти.

«Эшемне яраттым, – ди Эльза апа. – Төнге сменаларга чыгарга туры килсә дә, күңелем теләп бара идем. Ул чакта үзебез дә яшьләр, комсомоллар. Илебезгә файда китерәбез дип янып йөрибез. Эшем җаваплы иде: вагоннарны аерып, төрлесен төрле юнәлешкә озатырга кирәк. Юлны аерырга соңарсаң яки иртәләсәң, каза чыгасын көт тә тор. Булды инде, төрлесе булды: вагоннарга зыян килеп, хезмәт хакыннан тотып калган чаклар да булды».

Үзе туып-үскән, яшьлеген уздырган Әгерҗесен яратканы сизелеп тора Эльза Хуҗаәхмәт кызының. «Бөтен гомерем Әгерҗедә узды. Юдиногa да чакырып караганнар иде, туган шәһәремне калдырып китәргә теләмәдем», – ди. Бакчасыннан, түтәлләреннән бушаган арада акрын гына парклардан урап кайта, кайчандыр үзе эшләгән станциягә сугыла, бергә эшләгән дусларын очрата. «Кичәге Әгерҗе белән бүгенгесе арасында җир белән күк аермасы, диярсең. Эшкә барганда аякка галош киеп, корыга чыккач, туфлиләргә алыштырган чаклар бер дә булмаган кебек. Бүген шәһәребез бик матур безнең. Хезмәттәшләр белән очрашкач та, гел шуны сөйләшәбез», – дигән сүзләрендә туган төбәге белән чиксез горурлану яңгырый.

Лилия ГӘРӘЕВА

САРЫ ДИҢГЕЗ



– Машина сайлыйсың икән – иң шәбе булсын, ә үрдәк икән – иң токымлысы! Уенын-чынын кушып сөйлиләр! Җөмләнең беренче өлеше турында әйтә алмыйм, әмма икенче өлеше... Аңа барысы да сыйган! Үрдәк, аны үстерү турында ничә сәгать сөйләп була? Берме, икеме, бишме? Минем хәзер моңа җавабым бар: әгәр токымлы үрдәк икән – тәүлек буе!



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

...Бу 25 август көне була. Барысы да шушы көнне хәл ителә. Авылда ялда чакта.

– Без күчеп кайтабыз!

Аларга гаҗәпләнеп караучыларны аңларга була: уналты ел яшәп, инде шәһәрдә тамыр җәйгәннән соң бит бу! Торыр урыннары бар, бизнеслары... Карьера дисәң – аның баскычлары буйлап та шактый югары күтәрелгән. (Айгөл: «Эштән үз теләгем белән китәм», – дип гариза язып кергәч, министрлыкта аңа хәтта яңа вазыйфа тәкъдим итәләр: «Кал гына!»)

– Әниләрдән берничә чакрымдагы Биклән авылында ташландык булып яткан фермаларны сатуга куйганнарын ишеттек. Барыбыз бергә барып карарга булдык. Әти белән әни, сеңлем, ирем белән мин... Георгий белән бу фикергә шунда, ферма эчендә басып торганда ук килдек... Калганы бик тиз булды: 1 сентябрь җитә иде бит – Казанга кайтып, мәктәптән баланың документларын алдык, фатирны саттык, кредит артыннан йөри башладык...

Хәер, читтән генә күтелмәгән адым кебек күренә бу. Айгөл үзен беркайчан да шәһәрнеке дип санамадым ди. Беренчедән, Суыксу авылыннан алар ул мәктәпкә керәсе елны гына шәһәргә киткәннәр. Аннан яллар, бәйрәмнәр,

Алар командасына кушылырга теләүчеләргә таләп бер – эшләргә теләк булу кирәк. Күзләр янып тору!

каникуллар саен Зәй районында яшәүче әби-бабайлары янына кайтып йөргәннәр. Ә әниләре кабат авылга күченгәндә Айгөл институтта укый торган була инде. Аның әти-әнисе – Гөлнур һәм Ренат Хановлар – Тукай районының гына түгел, ә Татарстанның беренче фермерлары. Кошчылык белән шөгыльләнүне безнең республикада алар башлый. 1990 елның сентябрендә Калинин дигән авылга кайтып төпләнәләр. Берсе – инженер, икенчесе – педагог. Үз яннарына: «Эшлибез!» – дип атлыгып торган биш гаиләне туплап, кооператив төзиләр. Колхозлар таралгач, буш калган ферманы арендага алалар. Боларның барысы да Айгөлнең күз алдында була: очрашулар, сөйләшүләр, планнар корулар... Бер елдан кооператив тарала – һәркем үз юлы белән китә. Ул чакта яңа эшкә тотынучыларның бүген инде икесе генә эшли, шуларның берсе – әтиләре Ренат Ханов. Әйе, Айгөл белән Георгий буш җиргә кайтып төшми: алар артында әти-әниләренең өч дистә

лекслары группасы булып үзгәрә. Айгөл Ханова – шушы группаның башлыгы. Хуҗалыкны бары тик саннар телендә генә сөйләштерүгә ул күчерә. Икътисадчы буларак, тәҗрибәне менә ни өчен туплаган икән!

Ә дүрт ел элек... Эшкә тотынабыз дип кабат Бикләнгә аяк басканда инде көз җиткән, яңгырлар башланган була. Ферма бинасына керәләр дә аптырап калалар: түбәдән тамчы тама. Бөтен җирдән су үтә! (Алдан ук әйтеп куям: авылга күчеп кайтканнарына алар үкенми. Бер тамчы да! Хәзер дә ул уй юк аларда, дүрт ел элек тә булмаган.) Нишләргә? Түбәне алыштырырга кирәк – башка чара юк... Ремонт төгәлләнгәндә инде кыш җитә. Әмма яңартылган корпуслар эчендә урамдагы салкын

– Быел гына алдык... Чаллы төзелә башлаганда, шәһәрне ит белән тәэмин итү өчен салынган дуңгыз комплексы булган бу. Аның сатылуы турындагы хәбәрне күрдем дә, иремә: «Әйдә, барып карап кайтыйк әле», – дим. Киңәергә дигән уй да юк иде әле. Тик комплексны әйләнеп кире чыкканда хәл иткән идек инде: алабыз. Нинди акчага икәнен әле белмибез, тик алабыз!

(Әти-әниләре фатиха бирмичә эш башлау гадәте юк аларда. Бикләндәге фермаларны карагач, Ренат ага: «Мин үзем сезнең яшьтә мондый эшкә тотынмас идем», – дип икеләнебрәк торса, Мусабайдагы корпусларны әйләнеп чыккач: «Үсәргә була монда!» – дип нәтиҗә ясый. Эчкә җылы керә: ата кеше, димәк, кызына ышана. Ә аның ышануы бик зур көч!)



Фото: Анна Арахамия







елга якын ел эчендә туплаган тәҗрибәсе, ялгышлары, уңышлары... Янәшәдә – әти-әниләренең эшен алардан алдарак дәвам итәргә алынган апасы Чулпан һәм сеңлесе Гөлнараның гаиләләре. Алар бүген ирешелгәнне саклаучылар, юк, алай түгел, аны күбәйтүчеләр, ишәйтүчеләр.

Алар кайтып эшкә тотынгач, әтиләре нигез салган крестьян-фермер хуҗалыгы гаилә кош комп-

сизелми дә. Тавык бик сизгер кош: микроклиматта да, яктылыкта да үзгәрешләр булырга тиеш түгел. Сүз уңаеннан: Айгөл белән Георгий эшләрен ул чакта 50 мең тавыктан башлыйлар.

Ә бүген... Бүген без алар белән Яңа Мусабай авылындагы предприятиеләрендә очраштык. Бикләнг белән мондагы мөмкинлекләрне чагыштыра торган да түгел!

Бер хуҗа кулыннан икенчесенә, аннан өченчесенә күчкән, шактый таркалган комплексны аякка бастыру өчен күп кирәк әле. Тагын өч ел, диләр алар үзләре.

– 85 КамАЗ машинасы чүп-чар гына чыгарып түктек. Ике корпуста реконструкция эшләре бара хәзер. Күрәсезме, алар инде әзер диярлек. Түбәләр алыштырылды, идәннәр җәелде... Тиздән җиһазлар урнаштыра башлаячакбыз. Ә бу корпус-

Күрше өлкәнең 50 ел элек оешкан бер кош фабрикасы узган ел алар бренды белән үз үрдәкләрен сата. Сатып алучылар бу ялганны бик тиз ачыклый...

лар әле чират көтә. Барлыгы унау алар монда. Сез икенче килгәндә бөтен җирдә инде ямь-яшел газон булачак. Объектның инфраструктурасы көчле. Хәтта корпуслар арасы да бетонланган. Дүрт этаплы чистарту системасы бар – ул эшли, төзек. Янәшәдә 13 гектар җир. Күрәсез, урманга терәлгән. Янәшәдә – күлләр... Без анда үзебезгә өй салырга җыенабыз. Хезмәткәрләребез өчен дә йортлар төзисе килә...

Сөйләшә-сөйләшә инде төзекләндерелгән корпуслар янына да җитәбез. Ишекләр ачык. Ә анда... Анда – диңгез! Үрдәк бәбкәләре диңгезе! Хуҗаларының: «Бакбак!» – дип бер дәшүе җитә – дулкын булып синең якка агылалар...

Хановларның атаклы токымлы үрдәкләре шушы инде! Алар турында: «Күзгә күренеп үсә», – диләр. Айгөл белән Георгий бу үрдәкләрне беренче тапкыр Биклән фермасына кайтарткач, әниләре Гөлнур апа килеп, аларны карап китә. Берничә көннән ул кабат «кунак» бәбкәләрнең хәлен белергә килә. Берничә минуттан әниләре офиска йөгереп керә:

– Нишләттегез? Нәрсә ашаттыгыз? Алар бит кабарганнар!

Кызы белән кияве үрдәк бәбкәләренә махсус ризык биргән дип куркуга төшкән икән. (Кайчак кошчылар, тиз үстерү өчен, кошлар алдына шушы ризыкны сала. Әмма ул аларның бавырына бик тәэсир итә – берничек тә аны ашатырга ярамый.) Үзе кабат кереп, комбикормны тикшергәч кенә тынычлана ул.

Утыз ел буе кош-корт үстергән кешене дә шаккаттыргач!

Айгөл: «Әле күптән түгел, республикада узган «Кыр көне»ндә төшердек», – дип, фотосурәт күрсәтә: үрдәкне үлчәүгә бастырганнар. 4 килограмм 300 грамм! Кайбер каздан да авыррак бит! (Сез аларның ул үрдәкләрен Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның инстаграмыннан да кереп карый аласыз: зурлар, матурлар, төсләләр!)

Әңгәмәбез бик озак шушы үрдәкләр тирәсендә генә әйләнә. Беренче елны бройлер үрдәкләрен көчкә сатып бетергәннәр. Ә аннан... кулдан тартып алып китә башлаганнар. (Чагыштыру өчен: әти-әниләре сезонга 80 мең кошкорт сата торган булса, Айгөлләр инде ике елдан 300–400 мең баш сата, өч елдан бу сан 800 меңгә җитә. Быел исә 1,5 миллионнан артык булыр дип көтелә.)

Халык ни өчен нәкъ менә аларны алырга тели соң? Ул тиз үсә (уникаль үрдәк бу: аның йөрәк тибеше башкаларныкыннан шактыйга ешрак. Шуңа организмында аш-кайнату, кан әйләнеше кебек процесслар тизрәк бара – иммунитеты күтәрелә. Башка үрдәкләр 24 көннән «ката», ягъни үсүдән туктый, ә ул – юк), ите майлы түгел, «үрдәк су ярата» дисәләр дә, аңа су да кирәкми. Иммунитеты югары булгач, юлда алып кайтканда да, үстергәндә дә югалтулар юк диярлек. Ә Темп кая гына таралмый: Башкортстан, Удмуртия, Мари Иле... Оренбург, Түбән Новгород, Чиләбе, Пермь, Самара, Севастополь, Әстерхан, Саратов, Краснодар... Иркутскига кадәр, мәсәлән, өч тәүлек кайталар. Быел Алтайдан килгәннәр: махсус җиһазланган машинага 3-4 мең бәбкә төяп киткәннәр... Ә алар ике айда үсеп җитә: сезонга өчәр тапкыр алучылар бар. (Бозауны әнә бер ел ашатырга кирәк!) Ите тәмле – шулпада үрдәк исе дә килми (күпләр өчен бу да бик мөһим!)

Бу үрдәкләрнең тамырлары инглиз токымлы үрдәкләргә барып тоташа. Моңа кадәр аны үстерү, тарату белән Белоруссиядә шөгыльләнгәннәр. Хәзер Хановларныкы – яңа токым. Болар – төсле үрдәкләр. («Халыкка ак үрдәкләр генә кызык түгел, төслесен яратыбрак алалар», – ди Георгий.) Бүген Хановларның тагын да көчлерәк үрдәк токымы барлыкка китерү буенча селекционерлар белән килешүләре бар. Киләсе елга инде алар авырлыгы бишәр килограммга җитүче үрдәкләр сата башлаячак. Юк, хата түгел – биш килограммлы! Ышануы да кыен!

Үрдәк бәбкәләрен бастырып чыгару белән Оренбургтагы партнерлары шөгыльләнә. Һәр ике көн саен аннан Тукай районына бер көнлек 15–20 мең бәбкә кайта. Сары диңгез! Үрдәкләрне ашату, эчертү, микроклиматны саклау – боларның барысын автомат башкара. Атна-ун көн узуга – капка төбенә су буе чират тезелә: ике көн эчендә 20 мең бәбкә таралып та бетә. Һәм барысы да яңадан башлана...

Һәрбер эшнең үз нечкәлекләре. Үрдәк бәбкәләренең читлектә түгел, идәндә генә үсүендә дә хикмәт бар икән.

– Бүгенгесе көндә Европа кошкортны читлектә үстерүдән инде баш тарта. Менә без корпуска керәбез дә барысы да күз алдында: бәбкәләр йөгереп йөри, авырмый, боегып утырмый. Бу сатуда да чагылачак. Читлеккә япсаң, безнеке кебек корпусларга 25 мең түгел, ә 90 меңгә кадәр бәбкә урнаштырып була. Җылытырга да азрак кирәк булыр иде. Әмма хуҗа 365 нче читлектә ни булганын күрмәячәк бит... Асларын көн аралаш алыштырабыз: кошларның сәламәтлеге өчен бу бик мөһим.

Юллар төшеп, тагын өч елдан Мусабайга килеп чыксак, монда инде күп нәрсә үзгәргән булачак. (Георгий кебек: «Алла боерса!» дип тә өстик әле!) Ун корпусның унысыннан да үрдәк бәбкәләре

тавышы киләчәк. (Айгөл дә, Георгий да аларның ничә көнлек икәнен тавышларына карап та аера. Күрмичә дә!) Корпуслар күбәйгәч, үрдәкләрне азрак үстереп сату мөмкинлеге дә туачак. Бу вакыт инде ит эшкәртү цехы да төзелеп бетеп, ишекләрен ачар, мөгаен... Уллары гына түгел, инде кызлары да кул арасына керә башлар. («Улыбыз Адельгә карата безнең таләп башка хезмәткәрләргә караганда кырысрак, – ди Айгөл. – Аңа 17 яшь, быел инде эшкә тәмам тартылды: көн саен шушында. Кош-кортка азык әзерләү – аның өстендә. Ул барысын да белергә тиеш: кайда ничек, күпме эшләнә... Моны үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм. 1999 елда Казанга күчеп килгәч, Татарстан дәүләт торак фондында эшли башладым. 1 нче категорияле белгечтән идарә башлыгы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелдем. Һәр баскычны үзем үткәнгә, кул астымда эшләүчеләрдән нәрсә таләп итәргә кирәклеген яхшы белдем.)

Күмәртәләп сатып алучылар тагын да арткан булыр. (Элегрәк фермер кош-кортны үзе үстереп, үзе сатып та йөргәнгә, кошчылык рентабельле булмаган. Ә Георгийның бүген ватсаптагы төркемендә – 1400 күмәртәләп сатып алучы. Һәм ул исемлеккә сезон саен яңа исемнәр өстәлә. «Беренче тапкыр алучыларга: «Нәтиҗәне күргәч, «рәхмәт» дип бер сүз генә язгыгыз, сезнең канәгать икәнне шуннан аңларбыз», дим. Телефоныма бертуктамый хәбәр ява: «рәхмәт», «рәхмәт», «рәхмәт»...)

Хәер, бөтен нәрсә дә үзгәрмәс. Мәсәлән, этиләре Ренат Хәниф улы көн саен ферманы бер урап китә – җитмешкә җитсәләр дә, аларның эштән аерылганы юк. Һәм бу әле озак еллар шулай калыр. Иртән уянгач, иң беренче эш итеп, этиләре һәр көнне интернет аша барлык фермаларны күзәтеп чыгар. «Фәлән фермага сатып алучы килгән, нигә каршылаучы юк?» – дип, балаларына шалтыратырга да онытмас. Аларга биргән киңәшләре дә гел шул калыр: «Тәүлегенә 24 сәгать, атнасына 7 көн сез фермаларда булырга: бөтен җиргә үзегез барып җитәргә, кул белән тотып карарга, күз белән күрергә тиешсез!» (Берьюлы бөтен җирдә дә була алуның заманча юлы табылган: сак хезмәте (ә анда нибары ике кеше эшли!) видеокамералар аша бөтен фермаларны күзәтә: кем килә, кем китә... Айгөл бер минутка гына телефонына күз сала: «Калининдагы базага оптовик килгән... Бу атнада анда сатабыз. Менә Биклән... Күрәсезме, машина тора. Күмәртәләп сатып алучы, димәк, инде бәбкәләрне төягән. Офиска документлар тутырырга кергән...»)

Алар кул астында эшләүчеләр дә гел шул калыр, мөгаен. Кабат килсәк, Валя апаны да очратырбыз, Гриша дәдәйне дә, башкаларны да... Бүген гаилә кош комплекслары группасы фермаларында 50 кеше эшли! Бу әле ремонт ясаучылар кебек килеп эшләүчеләрне санамаганда.) «Эштән китүчеләр күпме?» – дип сорагач, Айгөл белән Георгий, аптырап, бер-берсенә караштылар: «Ә бездән кеше китми...» Шулай, бер көнлек уртача хезмәт хакы 1500 сум булган җирдән нигә китсеннәр?!

«Бездә проблемалар юк – хәл итәсе мәсьәләләр генә бар», – ди алар. Онлайн-касса кирәк дип таләп итәләр менә, андый кассасы булмаучыларга тиздән штраф яначак. Ә авылда интернет та булмаса нишләргә? Аны китереп җиткезү 300 меңгә төшәчәк... Зарланып сөйләмиләр. («Нинди зарлану, ди?! Иң авыр вакытта – кредитлар 28 процент булганда эшләгән эти белән әнидән оялмыйчамы?!») Үзләре әйткәнчә, Татарстан авыл хуҗалыгы министрлыгы бәяләп бетергесез ярдәм күрсәтә бүген алар кебек фермерларга. Аннан башка бизнесны үстерү авыр булыр иде. (Ялгыштым! «Бизнес» дип әйтеп ялгыштым. «Безнең өчен яшәү рәвеше бу! – диләр ирле-хатынлы беравыздан. – Табыш артыннан кумыйча, җан рәхәтлеге алып эшләү башка ул...»)

...Токымлы үрдәкләрнең нинди була алганына инандырдыммы инде сезне? Айгөл белән Георгий минем үземне моңа тәмам ышандырып җибәрделәр. (Үрдәк турында сөйли-сөйли, Айгөлнең ел ярым элек кабат әни булганын – өченче баласын алып кайтканын әйтергә дә җай чыкмады менә.)

...Узган ел аларга Оренбургтагы партнерлары янына барырга туры килә. Кич буе Георгий үрдәкләре турында сөйли. Ахырда кош комплексы директоры Рөстәм Исәнбәтов түзми:

– Минем сезгә барып, ул үрдәкне сатып аласы килә инде! Үземдә дә алар ничә корпус югыйсә! – ди.







Эльмира
ШӘРИФУЛЛИНА

ШӘХЕСЛӘРГӘ БАЙ МИЛЛӘТ БЕЗ

Хан ярлыгыннан хатын ярлыгы көчлерәк. Безнең халыкта әнә шундый тирән мәгънәгә ия мәкаль бар. Тарих үзе мөһер суккан, гасырлар дәвамында сыналган әлеге гыйбарәне күптән түгел республикабызның Тукай районында Бөтендөнья татар конгрессының «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы «Киләчәге бар милләт без, шәхесләргә бай милләт» дип исемләнгән күчмә утырышы дәвамында чын-чынлап раслады.







Бөтен нәсел-нәсәбе белән туган халкының телен, динен, фәнен, сәнгатен үстерүгә хезмәт иткән Хәлфиннарның йорт-нигезләрен күреп сөендек.

Апрель аенда үткән II Бөтендөнья татар хатын-кызлары корылтаенда кабул ителгән резолюцияне үтәү нигезендә оештырылган бу җыенга Австралия, Франция, Белоруссия, Латвия, Болгария, Луганск, Казакъстан һәм Россиянең 18 төбәгеннән, Татарстан районнарыннан 150 дән артык хатын-кыз килгән иде. Тукай районының Салих-Тукай авылы кызы, Татарстанның халык артисты, якташлары Зөһрә Сәхәбиева, шулай ук Татарстанның халык, Россия Федерациясенең атказанган артисткасы, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Дания Нуруллина, язучы, тарихи романнар авторы Марат Әмирханов, журналистлар бу чараны тагын да ямьләде. «Ак калфак» оешмасы рәисе Кадрия Рәес кызы Идрисова җитәкчелегендә өч төркемгә бүленеп, иртәннән башлап төнге берләргә кадәр программага кергән 17 авылны өч көн дәвамында йөреп чыктык. Аккалфаклыларны үзенең җәмәгате Эльмира Рөстәм кызы белән район башлыгы Фаил Мисбах улы Камаев, башка җитәкчеләр, район «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Эльмира Әхмәтҗанова, район халкы ипи-тоз, якты йөз белән каршы алып, озатып калдылар. Рәхәтләнеп халык белән аралаштык, районда туып-үскән шәхесләрне барладык, авыл халкы белән бергә уйнадык, биедек, җырладык, төнге берләргә кадәр аккалфаклылар үткәргән мастер-классларда катнаштык. Очрашуларның программасы искиткеч бай, эшлекле, тыгыз итеп төзелгән иде.

Теләнче Тамак. Урта мәктәп урнашкан калын диварлы мәһабәт биналар, ак таштан биек койма белән әйләндереп алынган ихата – барысы да заманында абыйлы-энеле Хәлфиннар биләмәсе булган. Әйтик, 1732–1785 елларда яшәгән Сәгыйть Хәсән улы Хәлфин, тирән белемле педагог, тәрҗемәче, киң эрудицияле кеше булуы белән бергә, татарның беренче «Әлифба»сын төзүче-автор буларак та кадерле! Аның ике томлык татар-рус сүзлеге, татар теле грамматикасы шулай ук кыйммәтле дәреслек саналган. Хәлфиннар нәселе турында иркенләп сөйләрлек. Сәгыйтьнең уллары Исхак һәм Исмәгыйль, оныгы Ибраһим, туруннары Шаһин-Гәрәйләр дә – гомер буе татар теле укытучылары, тәрҗемәче-тылмачлар булып, халык мәнфәгате өчен зур эшләр башкарган мөхтәрәм затлар. Берничә мәчет, мәдрәсәләр, тегермәннәр, кызыл мал белән сату итүче кибетләр – ашлык амбарлары төзеткән, халыкка һәрвакыт ярдәм итеп торган Исхак Хәлфинның улы сәүдәгәр Садыйк Хәлфинныкы булган.

Тукайның замандашы, 1886 елда шул ук Теләнче Тамакта туган Мөхәммәтнәҗип Латыйп улы Хәлфин исә, югары белемле педагог һәм тәрҗемәче булуы өстенә, сәясәтче, әдәби тәнкыйтьче, география белгече дә. Ул 1917 елда Казан өязе Милли Шура әгъзасы, 1917–1918 елларда Милли Мәҗлес депутаты була. Казан, Баку университетларында студентларга белем бирә; Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура, ХХ йөз башы татар шагыйрьләре әсәрләре турында гыйльми мәкаләләр яза; Карл Фукс хезмәтләрен татарчага тәрҗемә итә. 1938 елда



Теләнче Тамактагы Хәлфиннар йорты шушы инде!

шәхес культы корбаны буларак атыла. Теләнче Тамак – татарның әнә шундый асыл улларын биргән авыл.

Аннары безне Чебенледә көтәләр иде. Чебенле – зыялы һәм затлы шәхесебез Мөхлисә Бубыйның әнисе Иманкул хәзрәт кызы Бәдрелбәнат абыстай туган авыл. Шул хөрмәткә анда элмә такта куелды. Мөхлисә Бубый Иж-Бубыйда туган, шул авылның данлыклы мәдрәсәсендә укыган һәм укыткан. Татар хатын-кызларын белемле дә, әхлаклы да милләт аналары итеп үстерү өчен бөтен көчен куйган, берничә җирдә кызлар гимназиясе ачкан (беренчесе 1901 елда – Иж-Бубыйда) педагог. Рәсәй тарихында бердәнбер казыя, дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Быел аның тууына – 150 ел. Бертуган Бубыйлар (Гобәйдулла, Мөхлисә, Габдулла) ачкан әлеге уку йортының никадәр зур кыйммәткә ия булуын ассызыклап: «Киләчәктә Иж-Бубый мәдрәсәсен татар Афинасы дип бәяләрләр», – дип язды күренекле тарихчы Альта Мәхмүтова. Чебенле авылы урынында (авыл үзе Түбән Кама сусаклагычы төзелү сәбәпле, районның 22 авылы белән бергә су астында калган) менә шундый данлыклы шәхесләрне биргән Ананы олылап искә алу булды. Вакыйганың зурлыгын аңлап, кырык эшен кырык якка ташлап, Ркаил Зәйдулланың «Үлеп яратты» спектаклендә Мөхлисә образын тудырган актриса Дания Нурлының да Чебенлегә кайтуы, әсәрдән өзек күрсәтүе әлеге чараны тагын да тулыландырды, баетты. Бәдрелбәнат абыстай хөрмәтенә истәлек тактасы куеп, аның һәм нәселенең рухына дога багышладык.

Татарстан халкы өчен генә түгел, Россия тарихына утлы мәхшәр булып теркәлгән Әфганстан сугышы хатирәләре белән танышып та тетрәнү кичердек. Ул – Иске Абдул авылы мәдәният йортына урнашкан «Гиндукуш» музеенда булды. Бу музей шушы авыл егете, әфганчы Айбулат Якупов иницитивасы белән оешты-

Азан моңнары, чәкчәк һәм чәчәкләр, үз якларына хас гореф-гадәтләр – бар да матур, күңелләрне кузгатырлык иде.

рылган, райондагы бар әфганчылар, бөтен халык һәм дәүләт ярдәме белән җиһазландырылган. Кайчандыр 18–20 яшьлек янып торган егетләр чәчләренә чал кергән азамат ир-атлар булып тигез сафларга басканнар. Әлеге сугышта мәңгелеккә ятып калган дусларын искә төшереп, чып-чын танк янында җыр сузды алар:

Нигә икәнен дә белмичәрәк,
Килгән идек сиңа, Гиндукуш.
Карлы түбәләрдән бөтенләйгә
Кайтып килешебез, инде хуш...

Рашат Низами сүзләренә әфганчы Рөстәм Әхмәтханов иҗат иткән әлеге гимн йөрәк-бәгырьләрне актарып чыгарып, күпләребезне яшькә коендырды.

Музей 2009 елның 22 февралендә – совет солдатларын Әфганстаннан чыгаруга 20 ел тулган көндә ачыла. Ул елдан-ел үсә, экспонатларга байый бара. Һәлак булган әфганчыларның әти-әниләрен чакырып, ел саен хөрмәт күрсәтәләр, кунак итәләр икән. «Алар, – ди музейны оештыручы һәм җитәкләүче, үзләре теле белән әйтсәк, музейның генералы Айбулат Якуповның әнисе Вәсимә ханым, – бирегә килгәч, улларының стенага куелган фотоларын, таш плитәгә уелган фамилияләрен сыйпап, балаларының исемнәрен әйтеп, сөйләшеп йөриләр. Киткәндә, йөрәк парәләренең рухлары белән очрашкандай тынычланып, рәхмәтләр укып саубуллашалар... Ә мин үзем улым ут эчендә йөргән көннәрдә тынычрак булдым, – ди Вәсимә ханым юмор хисе белән, – чөнки Айбулат, Монголиядә хезмәт итәм, барысы да тәртиптә, дип яза иде.

Яңа Бүләктәге Илһам Шакиров музее һәм «Илһам» чишмәсе, Иштирәк авылындагы хирург Вәгыйз Сәйфуллинның экспонатларга гаҗәеп бай музей-йорты, кирегә агучы «Керәч тау» чишмәсе янында известь чыгару, 3 яшьлек балалар белән үткәрелгән «Туган тел» фестивале, Боерган авылында «Тукай чәкчәге» фестивале күренеше һәм бу авылга аеруча хас булган «Мунчала чыгару», «Кирпеч сугу», «Чабата үрү» йолалары, Иске Абдулда «Басу яру» йоласының ничек үткәрелүен күрсәтүләре, Биклән авылында «Киленгә су юлын күрсәтү» йоласы, шәхси эшмәкәр Римма Крицкая кибетләре, Иске Җирекле авылындагы «ТАССРның 100 еллыгы» паркында «Уйна, Тукай гармуны» фестивале, Бакчасарай, Иске Җирекле авылларындагы Минталип Миңнеханов, Равил Миңнехуҗиннарның фермер хуҗалыклары, авылда яшәп иҗат итүче шагыйрәләр, язучылар, сәнгать әһелләре белән очрашулар – болар барысы да кызыклы, күңелләргә хуш килерлек итеп оештырылган иде...

Иске Дөреш авылында 150 хатын-кызның өч командага бүленеп, бирелгән он, йомырка, бәрәңгедән ике сәгать эчендә төрле-төрле ризыклар пешереп, «Кунак каршы алу» йоласын күрсәтүе хатын-кызның бервакытта да югалып калмавын, дуслык-туганлык җепләрен, тиз арада оештыру сәләтен тәрбияләүгә зур этәргеч булуын дәлилләүче бер күренеш булды.

Сәфәребезнең соңгы сәгатьләре. Новотроицк авылының өр-яңадан ремонтланган мәдәният йортында пленар утырыш бара. Мәртәбәле кунаклар республикабызның премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев, Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Тукай районы башлыгы Фаил Камаевларның тирән мәгънәле чыгышлары кул чабып хуплаулар белән бүленә-бүленә тыңлана. Котлаулар, рәхмәт сүзләре, киләчәккә киңәштәкъдимнәр яңгырый. Барыбыз да аягүрә басып, татар халкының гимнына әйләнгән «Туган тел»не җырлыйбыз. Шушы тантаналы минутларда язма башындагы мәкаль искә төшә...

Шәхесләрне барлау, данлау юлында да шәхесләр кирәк шул!



Гамьле сөйләшүләр, киңәш-табыш, җыр-моңнар белән тулы өч көнебез сизелми дә үтте...

ИКЕ ЙОРТКА БЕР ИШЕК



Көндәшләрнең бер гаилә булып яшәвенә авыл халкы гаҗәпләнә иде.

Җәйге матур көннәрдә, шау чәчәктә утырган бакчага чыгып, иңенә үзе белән бергә картайган гармунын асып, борынгы моңлы көйләрне сузган чагында аның күпне күргән, сугышның афәтле ачлыгын кичергән күңеле ни уйлый, кайларда йөри икән?! Бәлки, ул туган туфрагына – Әлки районының гаҗәеп матур табигатьле Карамалы авылына очып кайтадыр. Үзе әйтмешли, гәүдәсендә чыкмаган җаны гына калган «озын бәдәнле» кыз, болынбасуларны айкап, ашарлык үлән-мазар эзлидер. «Заманында бер силос базын тутырырлык үлән ашадым», – дип тикмәгә генә әйтми ич ул...

Аның балачагы да миллионнарны корбан иткән, тарихта онытылмас эз калдырган сугыш чорларына туры килгән. Шуңа да 91 яшен тутырган Асия апа Вәлиуллина сүзен: «Сөйләрлек сүзем дә юк. Мин дә кеше күргәнне күрдем», – дип башлый. Тик ил белән кичергән ул авыр, дәһшәтле еллар җанга гына түгел, канга сеңгән. Бик еракта куркыныч төш булып калган ул истәлекләр юк-юк та бер сискәндереп җибәргәндәй була. Менә хәзер дә ул шул халәтенә кайтты ахрысы. Үзгәнә үткән көннәрнең иң ачы, иң хәтәр мизгелләрен тагын бер кат күз алдына китерәсе итте.

...Сугыш башланганда аңа күп дигәндә шул 12-13 яшьләр тирәсе була. «Әтиләрне сугышка алалар, әтисез калабыз», – дип елый кинәт олыгаеп киткән кыз. Тик әтисез калуның ни икәнен ул соңрак белә, соңрак аңлый. Юк, аның яраткан әтисе сугыштан бик тиз әйләнеп кайта, «күзе начар күрә» дип, аны өч-дүрт ай эчендә кире боралар. Әнисе Галия апаның куанычы эчендә сыймый. Басуда черегән бәрәңгегә, үсеп утырган кычытканга кадәр ашалып беткән, ә ике баланы яшәтергә кирәк. Тик ире Габдулланы гына әйтерсең алыштырып куйганнар. Көннәрдән бер көнне ул: «Балалар, мин аерылам, сездән түгел, әниегездән аерылам», – ди. «Карга да баласын туйдырып очырта. Китмә...» – дип елый кыз. Соңыннан әтисе, баласының әйткән сүзләрен оныта алмыйча, үзе дә озак вакытлар елап йөри әле. Менә шулай кинәт, һич көтмәгәндә, уйламаганда... Югыйсә тыныч кына яшәп яталар иде бит әле. Әллә кая да чыгып китми әти кеше. Янәшәгә – күршегә генә күченә. Амбардагы соңгы ашлыкны да, абзардагы карап торган малны да алып чыгып китә. Малны суеп, яшь хатынга кием-салым юнәтә. Гарьләнә, сыкрана Галия апа, тик нишләтәсең, бирмеш көне шундыйдыр. Килешә. Балалар да әкренләп тынычлана. Әллә кая китмәде бит әтиләре, күршедә генә...

Тора-бара бу ике гаилә, көндәшләр – Галия апа белән Факиһә (аңа әле нибары 19 яшь була, ә Габдуллага – 45) дуслашып китәләр. Бер табактан ашап, уртак борчу белән яшәп яткан Вәлиуллиннарны авыл халкы аңламый. Ничек шулай була инде? Алар Галия апаның түземлегенә, олы җанлы булуына хәйран кала. Хәер, бу вакыйга тиз онытыла, чөнки һәркемнең дә үз кайгысы, үз хәсрәте. Көн дә бер капканы кара пичәтле хат ачып кергәндә, кешенең башкаларда нинди кайгысы булсын...

– Ике йортка бер ишек иде, без бер гаилә булып яшәдек, – дип сөйли Асия апа. – Бер-бер артлы туган биш баланы әни гел мунча ягып кертә торган иде. Безнең әти дуамал кеше, балаларга бик кырыс, усал булды. Әни моны белә. Алар ягыннан әтинең кычкырган тавышы ишетелсә, шундук: «Тагын Камиләгә суккандыр», – дип, чыгып чаба иде. Кызлары Камилә исемле иде.

Аннары Асия дә кияүгә чыга. Тормышлары бик авырдан барса да, зарланмый. Бөтен кеше шулай яши ич, бер алар гына түгел. Өч бала таба. Бүген аның биш оныгы бар. Оныкларының балалары гына да сигез! Ул балаларына, киленнәренең акыллы, мәрхәмәтле, үзенә карата шәфкатьле булуларына шөкрана кыла. Гомерең офыкларга баккан бер мәлдә кадер-хөрмәттә өйнең фәрештәсе булып яшәүдән дә рәхәте юктыр ла ул.

Асия апа бүген кече улы, килене белән Яшел Үзән районының Осиново бистәсендә яши. Тыныч, рәхәт тормышка куанып бетә алмый. Заманында «Майский» совхозының алдынгы эшчесе булган Асия апа Вәлиуллина инде күпләргә үрнәк булырдай әни, дәү әни. Аңа әби дип тә әйтәсе килми. Гасыр тутырып килүенә карамастан, ул әле сөбханалла! Хәтере яшьләрне бер якка куярлык. Матур итеп сөйли дә, кычкырып көлеп тә җибәрә. Әле ул гармунына, каешы өзелгәч, мунчаладан ишеп бау ясавы турында сөйләп көлдереп ала. «Авылда кеше бетеп бара. Ни фермасы, ни мәктәбе юк, яшәр чама калмаган», – дип әрнеп тә куя. Әби әле дә заман белән бер адымда, дөнья хәлләрен дә синнән-миннән шәбрәк белә. Утта янмый, суда батмый, диләр бит әле. Менә шул... Асия апа хакындадыр инде бу сүзләр!

Мәдинә АВЗАЛОВА



АЛТЫНЧЫ БУЫН БАЛЧЫ



Биек өрәңге агачына менеп, сарган умарта кортларын җыеп төшкән кечкенә кызга соклана да, аптырый да авылдашлары – Лаеш районы Кече Елга халкы. «Сине Казаннан алыштырып кайтарганнар», – ди аңа әбисе белән бабасы яратып. (Болай дип әйтергә сәбәбе бар!) Ә шук кыз Баһаутдин нәселе дәвамчысы булуын раслый: умартачылык белән шөгыльләнә һәм бабасы кебек үк үткәннәр белән кызыксына. «Минем өчен яңалыкның бәясе юк, ә менә тарих – бәһасез», – ди Гәүһәрия ханым ВӘЛИУЛЛИНА.



Морзалар нәселеннән ул. Буш сүзләр генә түгел бу. Архив документлары белән расланган шәҗәрәсе – өй түрендә. Һәр кеше җиде буын бабасын белергә тиеш, ә Гәүһәрия апа үз буынын гына түгел, әнисе тамырларын да таба. Ике шәҗәрәле ул!

– Шәҗәрә, дин күзлегеннән караганда, оныкларга җиде буын әби-бабасы рухына дога кылу өчен кирәк булса, ханлык чорында морзалар үзләренең туганлык бәйләнешләрен җир биләмәләре белән килеп чыккан аңлашылмаучанлыкларны хәл иткәндә кулланганнар. Ул чорда шәҗәрә рәсми документ булып саналган, заманча итеп әйтсәк, юридик көчкә ия булган. Бүген документ итеп кабул ителми. Аңа карап кына әһәмиятен дә югалтмый. «Нәсел тарихы – буыннар арасындагы бәйләнешне саклый торган зур хәзинә», – ди Гәүһәрия апа.

Җиде буын бабасын эзләп таба ул. Тик Иркен бабасыннан соң чылбыр очы югала. Берчак төш күрә. 40–45 яшьләрдәге костюм кигән кешене Иркен бабаң дип таныштыралар. «Нинди минем бабам булсын, ул бит кыргызга охшаган», – ди Гәүһәрия. Төш аның исендә кала. Тарихи документларда эзләнә башлагач, әлеге бабасының 45 яшьләрдә үлгәнен ачыклый. Тик берничек тә аннан соңгы буынны таба алмый. Димәк, бабасы бу җирлеккә кайдандыр килеп урнашкан. Кыргыз булуы да хактыр, чөнки бездә әлеге халык чалымнары бар дип фаразлый. Зур эш башкара ул, барлык документларны туплап, нәсел тарихы турында китап яза.

Тарих белән кызыксынмаса, бүген мин алтынчы буын умартачы дип әйтә алыр иде микән?! Ә ул белә: морза Ишморза бабасы сәүдәгәр була. Алтышар айга читкә чыгып китеп, сәүдә эшләре белән йөри. Авылга беренче помидорларны да ул алып кайта. Бакчада кызарып үскән помидорларын күреп, авыл халкы Ишморза урыс ризыгы ашый дип гаҗәпләнә. Ул заманда җирле халык кызыл, кара төсләрне өнәмәгән, андый төстәге ризыкларны да яратып бетермәгән. Авылга беренчеләрдән булып умарта кортлары алып кайтучы да – Ишморза карт. Алар нәселендә умартачылык әнә шулай ерак тамырлардан башлана. Бабасы Баһаутдин да умарта тота. Аның бал кортларына кагылышлы язмалар белән тулган калын дәфтәре әлегә кадәр саклана. Анда кортларларны кайчан кышларга керткәннәр, кайчан чыгарганнар, ел яхшы килгәнме, юкмы – барысы да язылган. Әтисенең дә шундый ук көндәлеге бар. Хәзер умартачылык белән шөгыльләнгән Гәүһәрия дә алар тәҗрибәсен куллана – һәр оя корт өчен көндәлек язып бара һәм балачагын, әтисен бик сагына. Җитми, бик җитми әтисенең киңәшләре...

Әтисе белән әнисе 35 ел буе умартачы булып эшлиләр. Республика күләмендә зур уңышка ирешәләр. Һәр көн кояш чыкканда ук Кашан урманнарындагы умарталыкка чыгып китәләр. Өйдәге эш – җиде балага. Әтисе иртән эшкә киткәнче аларны торгызып, бакчага алып чыгып тезеп бастыра да, һәрберсенә эш бүлеп калдыра. Кичен кайткач, өйгә кергәнче үк балалары

Нәсел бәйрәменә 400 туганы җыела.



башкарган эшләрне тикшереп чыга. Баһаутдин бабаларына бакчадагы 30 баш умартаны карарга да ярдәм итә балалар. Гәүһәрия апа кечкенәдән умарта кортларының әһәмиятен белеп үсә. Тикмәгә генә, аерылып чыгып китеп, өрәңгегә сарган кортларны җыеп төшми бит инде ул кечкенә чагында. Шуклыгы белән дә гаиләдәге башка балалардан аерылып тора. Шуңа да «Казан шпанасы» дигән сүзне еш ишетергә туры килә аңа. Үпкәләми, ул аны мактау итеп кабул итә. Казан хастаханәсендә туганга шулай дип әйтәләр бит аңа! Эш болай була: Гәүһәрия белән көмәнле әнисе, инде бала туар вакыт җитсә дә, ун капчык бәрәңгене таксига салып, Казанга юл тота. Колхоз базарында бәрәңгесе сатылып бетүгә үк тулгагы башлана. Аны Тукай урамындагы бала тудыру йортына илтәләр. Гәүһәрияне әнисе авылга ун бәрәңге капчыгына төреп алып кайта.

Әтисе Гәүһәриянең умартачы булуын тели. Тик кыз Казан дәүләт педагогика институтының физик тәрбия бүлегенә укырга китә. Укырга кергәндә дә бал кортлары ярдәм итә әле аңа. Ничекме? Имтихан сорауларының берсе буынтык аяклылар хакында була. Кем кем, ә менә бал кортлары арасында үскән Гәүһәрия алар хакында сәгатьләр буе сөйли ала. Укытучы берничә тапкыр туктатырга тырышып карый. Юк, сөйләп бетермәде бит әле – тукталмый. Ахырда имтихан алучы укытучы аны аудиториядән куып чыгара. Җавабым ошамады, дип елап җибәрә кыз. Трамвайда да бертуктаусыз елап кайта. Имтихан билгеләре куелган кенәгәне ачып караса, анда – «бишле»!

Институтны тәмамлап, Имәнкискә авылы мәктәбенә физкультура укытучысы булып урнаша. Шушы авылда Спас районы Үрнәк авылы егете, тормыш терәге Җәвит белән очрашып кавыша. Бер ул белән бер кыз үстерәләр. Лаеш шәһәрендә гаилә оясы корып, сукыр һәм начар күрүче балалар мәктәбендә ЛФК укытучысы булып эшли башлый. Кулында спорт инвентарьлары булса да, милли җанында шигърият уты яна аның. Ул балалар белән уздырган Нәүрүз бәйрәмен күргән РОНО җитәкчелеге аңа татар теле укытучысы булырга киңәш итә. Укытучыларның белемен күтәрү институтына кереп, һөнәрен татар теле укытучысына үзгәртә. Һәм иҗат чишмәсе ургыла башлый. Шигырьләрен укыганнан соң, Туфан ага Миңнуллинның: «Кулыңа туп түгел, каләм алырга кирәк иде», – дигән сүзләре дә үсендерә аны. Иҗаттан аерылмый. Бүгенге көндә ике шигырь китабы дөнья күргән.

Укытучы булып озак эшләргә туры килми. Сәүдәгәр бабалары каны үзенекен итә. Ике меңенче еллар башында – шәхси кибетләр күренә башлаган чорда – Лаешта беренчеләрдән булып кибет ачалар. Кечкенәдән намазын калдырмаган Гәүһәрия өчен аның хәләл булуы шарт. (Кечкенә чакта намаз вакыты

Фото: Анна Арахамия

Бал кортлары – җан шифасы.

житкәч, урамнан йөгереп керә идек тә, яулыкларыбызны ябып, намазга баса идек, укып бетергәч, кабат уйнарга чыгып чаба идек, дип искә ала ул. Бабасы әйткән була: «Дин кануннарын тотканыгызны песи дә сизмәсен!») Алты ел элек әтисенең дә теләген тормышка ашыра: умарта тота башлыйлар. Җәвите дә эшнең җаен белә. Аның да әтисе умартачы була бит. Юк, мал артыннан куар өчен башламыйлар бу эшне. Күңелне ял иттерер өчен тотыналар. «Урмандагы матур аланда урнашкан чүнлеккә (умарталыкка) барып, кортларны сәламләгәч тә, бөтен борчулар, алҗулар онытыла», – диләр. Умарта кортларының акыллылыгы, тырышлыгы хакында сөйләп туя алмыйлар Вәлиуллиннар. Бөтен серебезне әйтәбез, тик умарталарга кагылышлысы хакында сорамагыз, диделәр. Умарта тотуны чәкчәк пешерүгә тиңлиләр. «Чәкчәкне дә бер үк төрле рецепт белән пешерсәләр дә, кемнекедер уңа, кемнекедер юк. Кулга да карый, сере дә булмый калмый», – диләр. Балның файдасы хакында пәйгамбәребез хәдисен китерәләр: «Бал кортлары җитештергән хәзинә, үлемнән кала, бар авыруларга да шифалы…»

«Минем Гәүһәрия үзе дә бал корты кебек», – ди Җәвит абый. Бизнес, умарта, йорт мәшәкатьләре (бакчасын матурлау өчен Камадан чуерташлар ташып, бөтен өслекләргә кечкенә ташлар беркетеп чыккан!), архивларда утырып тамырларыңны барлау, тарихи бәйрәмнәр үткәрү…

Шәҗәрәсен төзегәннән соң, авылында ике ел нәсел бәйрәме үткәрә. 400 туганы җыела. Озын итеп ясалган өстәлләрдә, әйләнеп утырып, җиде буын бабалары рухына Коръән укыталар. Үзенекеләргә генә түгел, ярты авыл бабаларына дога уку бит инде бу! Борынгы әйберләр җыю – Гәүһәрия апаның тагын бер яраткан шөгыле. Ниләр генә юк анда: 1870 елга караган өстәл җәймәсе – Таифә әбисенең бирнәсе, 1876 елгы самавыр, Баһау бабайның 1910 елда кулланган көмеш кашыгы, бабасының сугыштан язган өчпочмаклы хатлары, борынгы календарьлар… Туган нигезендә гаилә музее да ача. Анда 200 дән артык экспонат. Менә шулар аның өчен алтынга тиң әйберләр. Буыннар чылбырын ныгыту өчен тагын бер зур эш. «Оныкларыбыз Гәүһәрия әби ачкан музей дип горурлансын иде», – ди ул.

Гомер бер генә бирелгән, аны бәрәкәтле итеп, аралашып, гөрләшеп үткәрергә кирәк дип яшиләр. Шуңа да кыш саен авылга кайтып, бөтен авылдашлары белән чаңгы шуарга чыгалар. «Андагы күңеллелекне сөйләп бетереп булмый, кайтып күрегез әле бер», – ди кунакчыл, киң күңелле Гәүһәрия апа. Чаңгы шуганнан соң, өстәл әзерләп күңел ачалар. Гармуннар уйнап, җырлар җырлыйлар. Бу инде авылның традициясенә әйләнгән. Кызганыч, аларга чаңгы шуарга үзенең «Буран»ы белән эз салучы, авылга күпер төзетүче Шамил ике ел элек фаҗигале төстә һәлак булган. Исемен мәңгеләштерер, тарихка кертеп калдырыр өчен авыл янындагы бер тауга аның исемен бирәләр. Авыл җыенында рәсми төстә игълан итәләр. Азан әйтеп, намазлар укыганнан соң, бәйрәм башлана. Сабантуйга тиң була ул. Авылдашлар җыенны ел саен үткәрүне дә күтәреп алалар. Авыл халкының бердәмлеге – җитәкчеләрдән. Ә алардан уңа Кече Елга халкы.

Киемнәрдә дә милли традицияләр саклана бит. «Авыл Сабан туенда балитәкле күлмәк киеп килүчеләргә бүләкләр булачак дип игълан иткәч, бер апа төн утырып күлмәк тегә», – дип сөйли Гәүһәрия апа. Бүләксез калдырмыйлар. Ул да хәзер традициягә әйләнгән инде. Авылында тарихи бәйрәмнәр уздыруда башлап йөрүче ханымны «Ак калфак» оешмасының район бүлеген җитәкләргә чакыралар. Йолаларны саклау белән янып йөргән Гәүһәрия җиң сызганып эшкә керешә. Гореф-гадәтләрне яңарту өчен төрле кичәләр оештыра, быел район Сабан туенда үзләренә аерым бер сәхнә бирәләр. Сабантуй эчендә Сабантуй оештыра ул. Кич утыру йолаларын күрсәтәләр, борынгы кәсепләргә нигезләнгән ярышлар оештыралар. Катнашучылар, балачакны, яшьлекне искә алдык, дип рәхмәт укыйлар аңа. Әле борынгы исемнәрне кайтару максатларында җыен уздырырга ниятләп йөри. «Кайчак балаларына, оныкларына әллә нинди ят исемнәр белән эндәшәләр. Ә безнең халык мәгънәле, матур яңгырашлы исемнәргә бай бит. Аларны искә төшерергә генә кирәк», – ди Муса, Ибраһим, Йосыф, Исмәгыйль, Сабирлар әбисе Гәүһәрия апа.

«Безнең бизнестан кергән керемнең күп өлеше әнә шулай тамырлар эзләүгә, китаплар чыгаруга, милли бәйрәмнәр оештыруга китә», – дип көлә Гәүһәрия апа. Юк, җәлләми ул аларга акчаны. Изге эшкә киткәне йөзе белән әйләнеп кайта ди. Иң мөһиме – бәрәкәтле булсын. Ярдәм сорап килгәннәргә дә булышмый калмыйлар. Соңгы киемеңне салып бирәсең бит инде, дип, туктатып калырга кеше дә юк. Җәвит абый да шундый ук киң күңелле (Лаешта үткән чаңгы ярышында фирменный ухасы белән бөтен район халкын сыйлый Җәвит абый). Башкаларда уңыш булмаган елларда да умарталарының күп бал бирүен дә әнә шуннан күрәләр. «Бал – Ходай биргән нигъмәт. Димәк, Аллаһы Тәгалә бездән разый», – диләр.

– Кешене язмыш җилләре кайда гына йөртсә дә, ул барыбер аны туган-үскән җиренә, болынлыкларына, балачак сукмаларына алып кайта. Кем генә булмасын, нинди урында гына эшләмәсен, ничек кенә бай тормышта яшәмәсен, ул туган авылының тарихын, табигатен хөрмәт итәргә, кешеләрен барларга, зурларга тиеш, – ди Гәүһәрия апа тормышының мәгънәсе хакында сөйләгәндә. Бездән соң зур-зур сарай, тау-тау маллар түгел, тарих калырга тиеш. Тарихта эзебез калу мөһим. Бәлки, байлык әнә шул эзне ясарга ярдәм итүче генәдер. Балалар бәяләгән иң зур бүләк – рухи бүләк. Үткәне булмаганның киләчәге дә юк бит.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА



Илнар хәзрәт
ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым»
мәчете
имам-хатыйбы

ХӨСЕТЛЕК

Хөсетлек белән көнчелек бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Дин буенча моның аермасы юк. Көнчелек – кемдәдер нәрсәдер күреп кызыгу ул. Һәм бу кызыгу синдә нинди теләк уята – хикмәт шунда. Кешедә берәр нигъмәтне күреп, ул миндә дә булса иде дип теләүне ак көнчелек дибез. Ә инде кешедә ниндидер нигъмәтне күреп, көнләшеп, бу нигъмәт анда бетсә иде дип теләү – монысы кара көнчелек, ягъни хөсетлек була. Хөсетлекнең нигезе – тәкәбберлектә. Чөнки бүтәннәрдәге нигъмәтне күреп: «Ни өчен ул аңа эләккән, мин бит моңа лаеклырак», – дип уйлыйсың. Хөсетлекнең нигезен бетерү өчен Аллаһы Тәгалә: «Нигъмәтне бирүче – мин», – ди. Аллаһы Тәгалә ни өчен нигъмәтне шулай бүлеп бирә – кайчакта логика да күрмисең. Күп эшләгәнгә күп бирәме? Алай дисәң, җыештыручы аз тырышамы? Ялгыз бала тәрбияләүче хатын өчәр эштә аз хезмәт куямы? Аллаһы Тәгалә беркайчан да бернәрсәне дә болай гына эшләми. Кемгәдер нигъмәтне биргән икән, аның үзе генә белгән мәгънәсе бар. Сиңа бирмәгән икән, моның да мәгънәсе бар. Иманлы кеше көнләшми, чөнки ул Аллаһы Тәгаләнең шушы бүлүе белән ризалаша.

Хөсетлектән котылып буламы?

– Беренчедән, әйткәнемчә, нигъмәтне Аллаһы Тәгалә бирүче дип аңлау коткара. Бер хәдистә Аллаһы Тәгалә болай ди: «Колларым арасында сәламәт кешеләр бар: аларга авыру бирсәм – иманнары бозыла. Минем колларым арасында авыру кешеләр бар: аларны сәламәтләндерсәм – иманнары бозыла». Моны ничек аңларга? Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылып, намаз укып йөргән сәламәт кеше авырып китә дә: «И-и Раббым, күпме намаз укыйм, ә син миңа чир җибәрдең», – дип әйтә һәм иманы бозыла. Димәк, Аллаһы Тәгалә иманын саклар өчен бу кешегә авыру бирми. Икенче берәү, чирләгәч дингә килә, намазга баса: төннәрен гыйбадәттә уздыра. Терелсә, ул боларның барысын онытачак. Шуңа күрә иманын бозмас өчен, Аллаһы Тәгалә аңа сәламәтлек бирми. Бар бай кешеләр, Аллаһы Тәгалә аларны фәкыйрьгә калдырса: «Сәдака кызганмыйм, изгелекләр кылам, ә син миңа хәерчелек бирдең», – дип әйтәчәк, Аллаһы Тәгаләдән канәгатьлеге югалачак. Малы аз чакта мәчеткә йөргән, гыйбадәт кылган икенче берәү, баеса туганнарын онытачак, кәеф-сафа корып, гыйбадәткә вакыты калмаячак – диннән ерагаячак. Димәк, бу кешенең дә иманы бозылачак. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә аңа байлык бирми. Аллаһы Тәгаләнең сиңа карата нигъмәте үзгәрсен дисәң, үзеңне үзгәртергә кирәк. Ягъни күңелең әзер булырга тиеш. Байлыкка битараф булганда гына баеп китә аласың.

Аллаһы Тәгалә кемгәдер, нәрсәдер биргән икән, икенче кешегә дә шуны ук түгел, ә башкасын бирергә мөмкин. Димәк, Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтен үзеңдә күрә белергә тиешсең – бу көнчелектән дәваланырга ярдәм итә. Ә күпләр күрми... Башкаларга карый да: «Машинасы да, йорты да бар – бөтен нәрсәсе яхшы», дип уйлый. Аның гаиләсендә тынычсызлык икәнен, ул өйдә бала хәсрәте барын, аның инде озак еллар авырганын – берсен дә белми.

Башка берәүнең байлыгын күреп, үзеңдә көнчелек, хөсетлек сизсәң, аңа карап, «сөбханалла, машалла», дип әйтү дөрес. Бу байлык Алладан, дигән сүз. Икенчедән, кемнән көнләшәсең – шуңа: «Ярабби, аның малын арттыр», – дип, дога кылырга кирәк. Бу – үзеңне дәвалау: көнчелек белән көрәшә алмаучылар да очрый. Моның тагын бер хикмәте бар. Пәйгамбәребез: «Башка кешегә нәрсә теләсәң, үзеңә дә шул булыр», – ди. Димәк, кешедә нигъмәт күреп, аның үзеңдә дә булуын теләсәң, дога кылырга кирәк. «Аның нигъмәте бетсен», дисәң, ул кешегә зыян килергә мөмкин. «Аның нигъмәте миндә дә булса иде», дисәң, синдә булмаска мөмкин. Әмма «аның нигъмәте артсын», дип дога кылсаң, Аллаһы Тәгалә ул нигъмәтне сиңа да бирәчәк.

Башкаларның сиңа карата хөсетлегеннән ничек сакланып була?

– Әйе, кара көнчелек зыян да китерә ала. Хөсетле кешенең зыяныннан дога укып сакланабыз. Хөсетлектән саклануның тагын чаралары бар. Мәсәлән, байлыгыңны күрсәтмәү, мактанмау, кешегә чыгармау. Мөмкинчелегең булса да, артык зур йорт салдырмау, иң кыйммәтле машинаны алмау. Күп кешене шул харап итә. Хәлең ничек диючеләргә, «бар да әйбәт», дип җавап биргәнче, «әлхәмдүлилләһи» диюең хәерле. «Моныкы яхшы икән, ә минеке бит алай түгел», дип, көнләшеп уйларга мөмкиннәр. Кешенең ике халәте бар, беренчесе – Аллаһ каршында: аның биргәненә дә, бирмәгәненә дә без канәгать булырга тиеш. Икенчесе – кешеләр алдында: көнчелек тудырмас өчен, аларга «хәлем ярый, түзәрлек», дип сөйләү дә гөнаһ түгел.

Хатын-кыз бер-берсеннән нык көнләшә. Шуңа күрә дус хатыныңа да бар сереңне, байлыгыңны күрсәтеп бетерергә кирәкми. Инстаграм бу яктан бик зыянлы. Башка хатын-кыз инстаграмдагы битеңә синең өчен куанырга гына керми – аны көнләшү кертә. Шулай булгач, нигә бөтен нәрсәне дә анда чыгарырга? Бер хатын-кыз икенчесенең матурлыгыннан да көнләшергә мөмкин. Андыйларга хәтта безнең мәзгабтә дә үзләрен саклау өчен битне каплап йөрергә киңәш ителә.



Нәни генә буйлы бер яшь кыз күңеле тулган саен тәрәз төбенә килеп, мөлдерәмә күзләрен күккә төби дә, гел бер теләк тели: «...акыллы, бар яклап та миңа туры килә торган асыл егет бирсәң иде!» Ә бу вакытта Казанның бөтенләй икенче читендә яшәүче асыл егетнең күңелендә үз ялваруы: «...кечкенә генә буйлы, әйбәт бер кыз белән таныштырсаң иде!» Күкләрнең мондый теләкләрне ишетми калганы бармы соң?! Берсенә – 24, икенчесенә 17 яшь тулгач, Җирдә бу икәүнең танышу тарихы башлана.

Раилә
ХӘЯЛИЕВА

ЯРАТУГА КҮКЛӘР ШАҺИТ

«Мин – Раил, ә Сез – Зөлфия...»

Сүзем – Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры актеры Раил Шәмсуаров һәм аның тормыш юлдашы, хыялдагы әнә шул «кечкенә генә кыз» – Зөлфия турында. Раилне Камал сәхнәсендә яңгыраган моңлы җырлары, башкарган рольләре аша беләбез. Ә йомшак назлы тавышка ия калфаклы Зөлфияне төрле әдәби, милли чараларны алып баручы буларак таныйбыз. Ул Камал театрында диктор-тәрҗемәче булып эшли. Татарстан китап нәшрияты оештырган аудиокитаплар яздыруда катнаша. Фатих Әмирханның «Хәят» әсәрен Зөлфия Шәмсуарова укый.

Шәмсуаровларларның гаилә тарихын язар өчен махсус Камал театрында очраштык. Монда әле бик тыныч. Коридорда безнең аяк тавышлары гына ишетелә. Пәрдә төшкән. Камал театрында җәйге антракт. Ә без грим бүлмәсендә танышу тарихын барлыйбыз.

Раил Зөлфияне беренче тапкыр монда, сәхнә артындагы 301 нче бүлмәдә күрә. Чыгарылыш курс студентлары спектакль куя. Тамашачы булып Казан театр училищесы студентлары да килгән. Түгәрәк колак алкалары белән уйнап утыручы кыйгач кашлы бер кыз бигрәк ягымлы күренә Раилгә. Ягымлы да, чибәр дә... юк, андый үткен кызлар Раилгә карамас шул... Егет чикләрне үзенә үзе куя ул вакытта. Һәм яңадан театр тормышына чума. «Гөргөри кияүләре»ндә – Микуш, «Диләфрүз-remake»да – Җәмил, «Кечтекле уен»да – Рәсүл, «Мәхәббәт турында сөйләшик»тә Рөстәм образлары иҗат ителгән чоры яшь актерның. Репетиция, иҗади эзләнүләр...

Берникадәр вакыттан соң театр янында кыйгач кашлы кыз янә очрый аңа. Тагын йөрәкне урынын-



Һәр гаилә нәселдән көч алып, нәсел энергиясе белән яши.

Фото: Энҗе Садыкова

нан кузгатып узып китә ул. Бу юлы Раил аны «Вконтакте» челтәреннән эзләп таба да, хат юллый: «Исәнмесез! Мин Камал театры актеры Раил Шәмсуаров булам. Ә Сез – Зөлфия...» Зөлфия дә җавапсыз калмый. Театр училищесында Илдар Хәйруллин төркемендә укуы, театрга йөрергә яратуы турында язып җибәрә. Җавап алгач та әллә ни зур өметләргә бирелми әле Раил. Һаман да шул үз-үзенә булган ышанычсызлык сыйфаты комачаулый. Артык кәттә, артык чая кебек тоела аңа Зөлфия. Ни дисәң дә, Казан кызы бит! Раилнең йөрәк хәлләрен сизеп алган дусты Радик ситуацияне үз кулына ала. Раил исеменнән интернет аша Зөлфиягә матур сүзләр яудыра башлый ул. Ә Зөлфиянең гаиләдә тәртип кырыс, әнисе Рузалия апа да, юк-бар гашыйк булулардан кызын сакларга теләп, артист халкына ышаныч юк дип, укырга кергәндә үк кисәтеп куйган була. Һи-и, танышыр-танышмас бу кадәр купшы сүзләр язгач, егеткә ышаныч юк инде дигән нәтиҗә чыгара Радик хатларын укыган Зөлфия. Чактан гына май ботканы бозмый кала! Әле ярый Раил, беркөнне батырлыгын җыеп, Зөлфияне театрга «Бәби» спектаклен карарга чакыра.

– Безнең курстагы бөтен кызлар да Раилне, «Зәңгәр шәл»дәге шәкертне, аның моңлы итеп матур җырлавын әйбәт белә иде. Читтән генә гыйшык тотып йөрүчеләр дә бар иде бугай. Ә мин менә белмим. Артист буларак аңа беркайчан да игътибар иткәнем булмаган. Беренче тапкыр очрашуга барганда да Раилне башкалар белән бутамас өчен, театр сайтындагы фотосын әллә ничә кат ачып карадым. Беренче күрүдә үк гашыйк булмадым әле. Аннары яраттым мин аны. Бик яраттым. Ул уйнаган спектакльләрне кат-кат карый, аның турында барысын да белергә тырыша идем. Берсендә, «Искән җилләр көенә» спектакле вакытында Раил сәхнәдә читән аркылы сикергәндә, аягы таеп китеп, читән белән бергә егылды. И кызгандым, и борчылдым шул чакта! Сигез ай очраштык без. Аннан...

– Аннан Зөлфия миңа тәкъдим ясады, – дип елмая Раил.

Ә хәл болай була. Җәй башында Раилнең Иштирәктә яшәүче әти-әнисе Наил абый белән Галия апа бергә яши башлауларына 30 ел тулу уңаеннан мәҗлес оештырырга уйлыйлар. Зөлфиянең сүзгә осталыгы, алып бару таланты барлыгы турында Раилдән ишеткән була инде алар. Гаилә бәйрәменә алып баручы итеп Зөлфияне чакыралар. Шулай итеп, егет кызны беренче тапкыр авылга алып кайта.

– Бәлки, мине күрер өчен, сынау белән чакырулары булгандыр, – дип, ул көнне искә төшерә Зөлфия. – Башта авыл Сабан туенда булдык, аннары кич гаилә бәйрәмен Раил белән бергәләп алып бардык. Раилнең туганнары да, әти-әнисе дә бик якын итеп кабул итте мине, баштан ук «кызым» дип эндәштеләр. Яныбызга килеп, «бер-берегезне тапкансыз, берүк югалтмагыз» диючеләр дә булды. Яшьлек бит! Йөрәкләрнең бер-берсенә омтылган чагы! Кире Казанга кайткандa инде Раил белән үзебезнең никахны планлаштыра башладык.

– Артист халкына бик ышанып бетмәгән әниең Раилне ничек кабул итте? – дим.

Ул вакытта инде әти-әнием Раил белән таныш иделәр. Яңа ел алдыннан, 30 декабрьдә танышырга килгән иде ул безгә. Танышкан көнне үк аңа «улым» дип эндәштеләр, үз итеп кабул иттеләр. Беләсезме, безнең бар да төштәге сыман бик тиз килеп чыкты, бернинди киртәләр дә булмады. Никахыбыз да, туебыз да бик матур узды.

Нәсел

Җиде буын бабаңны бел диюләре дә юктан гына түгел бит. Әби-бабаларыбызның нәселдән-нәселгә күчеп килгән сыйфатларын белү – бүген безгә балаларыбызны яхшырак аңларга ярдәм итә.

Зөлфиянең нәсел тамырлары Кайбыч районына барып тоташа. Әтисе Зөфәр – Кече Кайбыч, әнисе Олы Урсак авылында туган. Зөлфиянең әнисе Рузалия апа Кайнәт (мулла кушкан исеме – Нурлыкайнәт) әнисенең иркә кызы булып, Әһликамал дәү әнисенең итәгендә үсә. Әтисе бик иртә вафат була. Кайнәт апа үзе – Борындык авылы кызы. Ә Борындыкныкылар җыргамоңга гашыйк, дөнья тота торган үзгә кешеләр. Олы Урсак авылына килен булып төшкәч тә Кайнәт апа сынатмый, тол калу ачысына бирешми. Гомер буе укытучы булып эшли һәм артистларча матур тавыш белән үзәкләргә үтәрлек итеп җырлый торган була ул. Авылга спектакль, концерт белән килүче артистлар һәрвакыт Кайнәтләрдә туктала. Кайнәт апа үзе дә артист булырга хыяллана. Шуңа да кызы Рузалияне артистлыкка укырга

Бала тәрбиясендә беренче чиратта әби-бабай киңәшләренә таяналар.

җибәрә. Зөлфиянең әнисе дә кайчандыр театр училищесында Празат Исәнбәт, Шәһсәнәм Әсфәндиярова, Асия Хәйруллиналардан белем ала. Студент чагында ук Камал театрында уйный. Әмма яшьлек мәхәббәте – хәрби кеше Зөфәргә кияүгә чыгып, Мәскәүгә күченә. Бер-бер артлы кызлары туа, язмыш аны башка юлдан алып китә. Кызганыч, Кайнәт дәү әнисен Зөлфия күрми кала. Әмма аның кыйгач кашларын, үткерлеген, чибәрлеген нәкъ менә дәү әнисенең яшь чагына охшаталар. Кызык бит, нәсел агачының тармаклы кәүсәләр буйлап сузылган кызыл җебе кайвакыт язмышларны бер сукмакка әйдәп кертә, киләчәкне кисештерә. Мәктәпне «бишле» билгеләренә генә тәмамлаган Зөлфия дә әнисе сукмагыннан китә...

Ә Раил – Лениногорск районы Яңа Иштирәк авылы егете. Әнисе Галия – химия һәм биология укытучысы. «Халык мәгарифе отличнигы», «Хезмәт ветераны» кебек мактаулы исемнәргә ия мәртәбәле кеше. Әтисе Наил гомерен колхозга, туган җиргә багышлаган. Бик матур бормалы моңлы тавыш Раилгә әтисеннән күчкән. Аларның нәселендә дә җырчылар, сәнгатькә гашыйк кешеләр шактый.

2013 елның җәендә менә шушы ике нәсел кушылып, Зөлфия һәм Раил Шәмсуаровлар гаиләсе туа.

Сынау

Матур мәхәббәт тарихларын тыңлау да, язу да бик күңелле, әлбәттә. Ләкин күп очракта ялкынлы мәхәббәт хисләре тормыш сынаулары каршында көчсезрәк булып чыга шул. Яшь гаиләләр яши башлауга ук беренче катлаулыклар белән очраша. Кемдер җиңә аны, ә кемнәрдер...

– Әйе, бездә дә булды андый хәл, – ди Зөлфия белән Раил.

– Мәхәббәтебезнең иң самими чагында, гашыйклыкның күкләрдә очып йөргән чорында өйләнештек. Гаилә булып бергә яши башлагач, уйламаган аңлашылмаучанлыклар килеп чыга башлады...

Әйтәләр бит, якын кешеңнең кыек сүзе дә икеләтә авырлык китерә, дип. Минем дә шулай, уйламыйча әйтеп, кайбер сүзләр белән Зөлфиянең күңелен төшергән чакларым булды. Берсендә бик каты ачуланыштык. Юк кына бер сүз өчен инде. Зөлфия нык рәнҗеде шунда...

– Һәм мин әти-әни янына кайтып киттем...

– Ә мин бик курыктым ул вакытта. Бөртекләп җыйган бәхетемне үз кулларым белән җимергән кебек булдым. Эшкә килгәндә юлымда группадашым Эмиль очрады. Утырып сөйләштек. Төпле матур киңәшләр бирде, Зөлфияне югалтырга ирек куймa, диде. Шул ук көнне мин Зөлфия янына бардым. Аңлаштык, килештек, өйгә бергәләп кайтып киттек.

– Ә мин шул көнне, Раил белән үпкәләшкәннән соң, башка беркайчан да әти-әни өенә кайтып китмим дип үземә сүз бирдем. Аларны шундый борчуга салдым ул чакта. Менә шул вакыйгадан соң без гаиләгә җаваплырак карый башладык. Раил гаилә дилбегәсен үз кулына алды. Ни дисәң дә, ул бит миннән җиде яшькә зуррак, тәҗрибәлерәк! Ул вакытта 18 яшьлек кызда нинди зирәклек булсын ди инде! Үпкәләгән, сүземне бирмәскә тырышкан чакларымда ул сабыр була белде, барысын да җайлады. Шулай акрынлап гаилә кадерен белергә өйрәндек. Хәзер инде без бер җан булып яшибез. Мин дә хатын-кыз зирәклегенә өйрәнә барам. Иштирәк әни белән озаклап сөйләшергә яратабыз. Ул миңа үзенең Гамилә әнисе сүзләрен гел әйтә: «Кар эресә дә, бозы кала. Бер-берегезгә авыр сүзләр әйтеп күңелегезне җәрәхәтләмәгез!» – ди. Һәр әйбернең үз җае бардыр инде ул тормышта. Безнең бит әле гаилә девизыбыз да бар: «Артка чигенергә юл юк!» дип яңгырый ул. Туйда әти-әниләребез, бер-берегезне үзегез сайладыгыз, таптыгыз, инде кирегә чигенү юк, алга барырга гына рөхсәт, дигән иде. Хәзер кайчак үпкәләшеп алсак та, бик тиз дуслашабыз. Матур яшисе килә безнең, гаилә тормышын мәгънәле итәсе килә.

Сынау вакытында узылган, сабак алынган. Бер-берсенә йомшак кына «Иркәм-җаным» дип эндәшә хәзер алар. Зөлфия гаиләдә көчсезлеге белән көчле булуын аңлаган, ире күләгәсенә күчкән. Раил исә Зөлфиясен «ул безнең гаиләнең визит карточкасы» дип йөртә. Бербөтен булып, серләрне уртак итеп яшәргә өйрәнгәннәр. Раил гастрольләргә киткән чакта икесенең дә кулыннан эш төшә, тамактан ризык үтми. «Бер-беребезне тулыландырабыздыр инде, икәү булганда безгә күбрәк игътибар итәләр», – дип елмаялар.

Нәфисә

Нәфисә исемен Раил белән Зөлфиягә Рузалия дәү әни тәкъдим итә. Яшь әти-әни кызларына менә шундый назлы исемне сайлый. Нәфисәне бала туу йортыннан алып кайтып өч көн узуга Зөлфия укырга чыга. Илдар Хәйруллин төркемендә уку шактый җаваплы. Диплом спектаклендә дә уйнарга өлгерә яшь әни, баласын күкрәк сөтеннән дә аермый. Тырышлыгы, үҗәтлеге аңа үзенең группадашлары белән бергә диплом алырга булыша. Оныкны караудa Рузалия дәү әни беренче ярдәмче була.

Инде 5 яше тулуны бәйрәм итәргә җыенган Нәфисә әти кызы булып үсеп килә. Спектакльләр карарга ярата, аннары сәхнә геройлары турында уйланып йөрергә, күп итеп сораулар бирергә... Тәпи киткәнче үк әнисеннән ишетеп шигырьләр сөйләргә өйрәнгән, нәни булса да, төрле театраль күренешләрдә катнаша. Иштирәк дәү әнисе догалар өйрәткән. Гаиләдә дә, дуслары белән дә бары тик татарча аралаша, татар мохитен сеңдереп үсә һәм әнисенең калфакларын кияргә ярата. Ә иң мөһиме... тиздән апа булырга җыена.

ФОТОБӘЙГЕ:
«ОБЪЕКТИВТА – ӘНИ»



Фото: Ләйсән Абдиева. Стәрлетамак.

«Объективта – әни» бәйгесе дәвам итә. Аның оештыручылары – «Сөембикә» журналы редакциясе һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы. Фотосурәтләрегезне 31 октябрьгә кадәр җибәрә аласыз.
Исегезгә төшерәбез: иң уңышлы дип тапкан эшләр журнал битләрендә дөнья күрәчәк, ә көзгә – Әниләр көнендә – Казанда, «Манеж» күргәзмәләр залында алардан күргәзмә оештырылачак.
Җиңүчеләрне планшет, кесә телефоны кебек кыйммәтле бүләкләр көтә.
Конкурсның нигезләмәсе һәм шартлары белән сайтыбыздан таныша аласыз: www.syuyumbike.ru.

PRESSA


Газинур МОРАТ

Аның шигырьләре – бөтенләй башка! Тикмәгә генә зәвык тәрбияләүче шагыйрь дип йөртмиләр шул үзен. Миф-риваятьләр, катмарлы метафоралар, фикер тыгызлыгы, көчле романтизм – поэтик алымнарның ниндиләрен генә кулланмый ул! Һәм укыган саен яңача ачыла бара, шигъри юллары күңелдә канатлы сүз булып тибрәлә. «Көйри-көйри көн яна», «Гел соңарам, һаман кабаланам», «Җәяү атлыйм Киек Каз Юлыннан...», «Мизгел эзлим дөньялыктан», «Җилкәннәрдә җилләр черем итә...», «Көйсез көннәр килде, Синсез көннәр...» Бар дөньяңны онытып, шигырьдән шигырьгә күчә-күчә, рәхәт бер халәткә кереп чумасың. Шигырь китапларының исемнәре генә дә ни тора! «Җир хәтере», «Мин дөньяны тыңлыйм», «Оча җырлар», «Җәяүле кошлар», «Кош хокукы»... Газинур Морат шигырьләре!
Түгәрәк юбилеен билгеләп үтүче шагыйрьне гомер бәйрәме белән котлыйбыз! Иҗат уңышлары телибез!

ҖИЛЛЕ ЧАКЛАР БАР ИДЕ...

Манзара

Гашыйк парлар узып китте
Йолдызларга орынып.
Бабасының каберенә
Чәчкә куйды оныгы.

Орышлардан арып-талып,
Дөнья талды йокыга.
Йөкле хатын кереп китте
Бәби табу йортына.

Күңелнең бер көне

Гаҗиз булып ташкаланың
Тынчу, таш карашыннан,
Йөрим кайчак урамнарда,
Адашкан мәче сыман.

Килеп чыгам вокзалларга,
Нинди уй белән – белмим.
Һәр юлаучыга кул изәп,
Хәерле сәфәр телим.

Килеп чыгам мәйданнарга,
Мәйданнарда – шау, халык.
Хөрлекнең яшел чыраен
Ерактан киләм танып.

Килеп керәм кибетләргә,
Чиратка басам. Көтәм.
Без бәхет көткән чиратлар
Үткән шул инде күптән.

Килеп керәм фатирыңа,
Каршылый мине ишек.
Ишектә – язу: «Чит-ятка
Керү тыела!» –
Ничек?!

Килеп керсәм күңеленә,
Каршылар кебек ятлар.
«Чит-ятлар керү тыела!» –
Бу – синнән соңгы ядкарь.

«Чит-ятлар керү тыела!»
Утырган күңел, тынган.
Чыгып киләм подъездыңнан,
Адашкан мәче сыман.

Ары китәм.
Аэропортка.
Нинди уй белән – белмим.
Канатлылар кавеменә
Хәерле очыш телим.

Син вә мин

Син ул – гүзәл!
Син ул – нәфис!
Миндә һаман элеккечә:
йөгәнләнгән
уй-хис.

Син ул – камил!
Син ул – матур!
Миндә һаман
элеккечә:
хөкем итә
салкын акыл.

Нигә әле күңелемдә
уянмаган уй соң?..
Ә бит синдә
күрер күзгә
искитәрлек
буй-сын...

Ялгызлык исемле кыз

Эзләмәгез мине бүген,
Мин юк бүген дөньягызда.
Күңелнең сыңар ачкычы
Ялгызлык исемле кызда.

Ул кыз мине тоткын итте,
Сарылды да иңнәремә.
Тәмәкемнең күк төтене
Кочып алды билләреннән.

Ул кыз мине гашыйк итте,
Таратты да толымнарын,
Пышылдады... Ишеттем мин
Күзләр күзгә орынганын.

Тезләр тезгә орынганын
Ишеттем мин, ишеттем мин.
Сыңар ачкычын күңелнең
Сорарга, аһ, кичектем мин,
Кичектем мин.

Ялгызлык атлы кыз белән
Калырмын күк мин мәңгегә.
Ул кыз миңа шундый якын –
Сеңә барам пакь тәненә.

Ул кыз миңа шундый якын –
Гүя хатын – мин ялгызга.
Эзләмәгез мине бүген –
Мин юк бүген дөньягызда.

Әгәр...

Алиһәм булсаң –
Табыныр идем.
Ал гөлләр булып
Кабыныр идем.

Еракта булсаң –
Сагыныр идем.
Хискә уралып
Абыныр идем.

Бергә булырга
Безгә соң инде.
Гөл-серебезгә
Кыраулар тиде...

Төнге этюд

Күл уртасында – Зөһрә кыз,
Ярымай гүя көймә.
Салмак кына ишә сылу,
Ямансу бер көй көйләп.

Ишетәм аның сагышын,
Ишетәм чорлар аша.
...Бер-берсенә күз кысышып,
Йолдызлар пышылдаша.

Көмеш балкыш чыңы күктә,
Жәй шавы – тирә-якта...
Төнге тынлык төнбоекны
Йокысыннан уята.

* * *

Былбыллар читлектә елый,
Аранда елый атлар.
Күк-Тәңре аранында
Җилләр елый, болытлар...

Аранны ачар чара юк, –
Җанга эленгән келә.
Кочагымда син елыйсың...
Шунысы гаҗәп менә.

Сөю атлы чаптарга алдан язылган мәрсия

Дөнья бит – синең дә
Гөнаһлар булгандыр.
Гөнаһлы бу дөнья
Сиңа да тугандыр.

Булгандыр синең дә
Чыгымчы чакларың.

Сөю атлы чая
Ак ялны чаптарың

Аранда күптәннән,
Күптәннән – яралы.
Камытлы кайгыдан
Каралды яллары.

Канатлы иде ул –
Кистеләр канатын.
Яралы җаныннан
Кан акты... кан акты...

Аннары ыңгырчак
Салдылар биленә.
Чыбыркы чыжлады
Сыртында: «Тибенмә».

Колынлы иде ул –
Чалдылар колынын.
Төшендә күрә тик
Колынлы болынын.

Төшендә күрә тик
Ак ялны чакларын.
Җанара, тәнара
Бәйгедә чапканын.

Бәхетле иде ул –
Тапты да... югалтты.
Көнчеләр җанына
Хөсетле ук атты.

Ирекле иде ул –
Ә хәзер – йөгәнле...
Бигайбә – ярылса
Йөгәнсез йөрәге.
Бигайбә...

Төнге әверелеш

Икәү яккан учакмыни –
Чатыр-чотыр төн яна.
«Кемнәр ярын кемнәр сөймәс
Бу вафасыз дөньяда», –
Дип җырлаган җилле чаклар
Бар иде бит безнең дә...

Бүген менә кискәдә күк
Ята башым тезеңдә.

Керфекләрең йомылганда
Дертләп куям, сискәнеп.
Сулышыңнан ишетелә
Җилбәзәк җил искәне.

Күкрәкләрең гүя гөрзи,
Кулың гүя айбалта.

Шүрәледәй шәрә шәүләң
Йөри дивар буйлата.

Таш диварга сеңә бара,
Сыза бара сурәтең.
Икәү яккан учак кебек
Шыпырт кына сүнә төн.

Карашыңда – таң салкыны,
Өши барам, өшәнә...
Һәрчак шулай: шом баса, әй,
Яшьлек искә төшә дә.

Җилле чаклар, тиле чаклар
Бар иде бит безнең дә.
Бүген менә кискәдә күк
Ята башым тезеңдә...

* * *

Әллә сөеп горур булдык,
Башларны имәдек без.
Өрмәгән урындыкларга
Утыртмам, димәдек без.

Тормыш кебек кырыс идек,
Әйттеләр: «Таш бәгырьле...»
Кадер эзләп киткән ярлар
Булды микән кадерле?

Бәхетләре тулы микән,
Уңдылар микән ирдән?
Яшәмиме икән алар
Яшьлекне каргап-тиргәп?

Сөйдек. Нәфрәтләндек.
Ләкин
Башларны имәдек шул.
Өрмәгән урындыкларга
Утыртмам, димәдек шул.

Бүген менә сулык-сулык
Үксетәбез бәгырьне.
Кадер эзләп килгән ярлар
Чынлап микән кадерле?!

* * *

Кабаланмый гына учак яна,
Яна мәңгелеккә килгәндәй.
Йолдызларга үрли ялкын теле,
Әйдә минем белән, дигәндәй.

Ядрә булып йолдыз атылганда,
Сискәндереп куя ал тынлык.
Мескенлектә узган гомер төсле,
Чиксезлеккә сеңә яктылык.





Роза МУЛЛАНУРОВА

АЙНЫҢ ТУЛГАН ЧАГЫ

(Хикәя)

Кояш иртәдән үк нурларын мул чәчә. Эссегә китте көннәр, кыздыра, үлән сабаклары корый. Гөлләр суга сусый. Яргаланган җир дымга туеныр җай көтә.

Йокысы сак шул Айзирәнең. Иркәләнеп черем итәргә исәбе бар иде әле, ят ир-ат тавышына сискәнеп, торып утырды. Ишегалдында Фәсхетдин абзый икән:

– Чокырча ягында сабан ашлыгы өлгергән, коелып ята. Явым-төшемгә киткәнче җыеп алу мәслихәт. – Әнисенә сөйләсә дә, бригадирның тел төбен төшенде Айзирә: «Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла!» дип суктыруы бу аның. – Үзең беләсең, Сәхилә җиңги, урак өстендә көн дә юк, төн дә! Яшьләр төшенеп җитми шуны. Юлга җыенсын кызың! Идарә җаваплы бурыч йөкли аңа: Ерак басудан амбарга кайткан ашлыкны үлчәп торасы!

– Җир читендәге Чокырча басуынамы? Таңнан ничек барып җитсен соң ул хәтле җиргә? – Әнисенең каршы әйтүен килештермәдеме, тегесе кырт кисте:

– Мин уйлап чыгарган закун түгел, Сәхилә җиңги, урак вакыты – уттай эш өсте! Тәртип каты мондый чакта. Кәнсәләргә барып сөйлә зарыңны, персидәтел тыңлап торса әгәр? Кылны кырыкка ярырдай булып чабулап йөри ул да. Хәрби чәстән ялынып өч машина китертте. Атна-ун көндә уракны бетерәбез, дип йөри.

– Алай... муенга камытны бер кидерсәләр, җәй үткәнче бушатмаслар...

– Сатулашып тор тагын! Кызыңны калхуз түләп укытканны онытма!

Әнисенең авызын томалады бригадир. Кызның үзе белән киңәшүне кирәк санаучы юк, димәк. Бухгалтер-экономистлар әзерли торган көллияткә идарәдән юллама биреп җибәрүләре хак. Укыды. Эш күрсәтер чак җитте. Кайту белән керде идарәгә. Рәиснең үзен

туры китерә алмады. Баш бухгалтер исә: «Әлегә буш урын юк. Ял ит! Эш булуга хәбәр итәрбез», – дип калган булды.

Тапканнар бит эш! Сөендерерлек хәбәр түгел дә, сайланып торып булмый. Тик ераклыгы! Әнисен нигәдер курккуга салды бу хәбәр.

– Җыен килгән-киткән, урыс-улак арасына олактырмакчы алайса сез кыз баланы? Кайтып-китеп йөри аламы ул аннан? Юаш дигәч тә...

Әнисен борчыган сораулар һавада эленеп калды. Бригадирның:

– Тотып ашамаслар. Фатир төшәр. Ашлык ташучы машина шоферлары кайтарып куяр. Биш минуттан әзер булсын! – дигәне урам яктан ишетелде.

Айзирә киенеп куйган иде инде.

Куанып туймаслык якты иртә иде бу. Хыялый халәт очты каядыр. Каршы килеп кара! Шушы җирдә яшисе. Әнкәсенең: «Ни хәл инде бу? Рөхсәт сорау юк, киңәш итү! Имеш, укытканнар!» – дип сөйләнә-сөйләнә, кабаланып, хәзинәдә бары белән юллык азык-төлек хәстәрләвен беравык тыныч кына күзәтеп торды.

– Борчылма, язмаганы булмас! – диде. Әнкәсе дөнья күргән хатын шул, өзми-куймый үзенекен тукый, балавыз сыгып та алды хәтта. Казан кадәр Казанга чыгарып җибәргәндә дә болай ук пошынмаган иде шикелле.

– Шул тиклем җиргә... Ничек барып-кайтып йөрерсең икән, и бала?

– Сабыр иткән, морадына җиткән, – диде дә тынычланды Айзирә. Хәер, идарәдә дә: «Җаваплы эш, шулай кирәк! Вакытлыча!» – диюдән узмадылар.

Чокырча – алардан тугыз-ун чакрым арырак, ерып чыккысыз удмурт урманнарына терәлеп үк утырган, нибары егермеләп йортлы бәләкәй генә авыл. Яшь-җилкенчәк үсеп буйга җитүгә Ижау, Чаллы ягына чыгып китә. Таралып-бетеп бара торган авылда ни мәктәп, кышын эшлим дигән кешегә ни эше юк.

Көз курка, кул эшли, дип дөрес әйтәләр. Хәер, кулдан бигрәк, башыңны эшләтү зарур монда! Беренче карашка әллә ни катлаулы эш тә түгел кебек: выж да выж килеп ашлык ташый торган машиналарны бутамыйча, кайсысы кемнеке икәнен төгәл язып аласы да, әрҗәдәге ашлыкның күләмен чамалап, теркәп кенә куясы. Әмма ялгыштырмый исәп-хисап алып бару алай җиңел түгел, чөнки автоүлчәгеч колхозның төп хуҗалыгы – Айзирәләр авылында гына. Алдан ук ары-бире чабулап, транспорт куып йөрү кесәгә сугачак, дип кисәткәннәр иде. Башта буш машиналарны, аннан ашлык төялгәнен автоүлчәгечтә үлчәтеп йөрү мәшәкатьле булса да, тиз төшенде кыз эшнең асылына. Кайсы машина әрҗәсенә ничә тонна ашлык сыя? Ачыклагач, эш җайланды. Ындыр табагында ашлык җилгәрүче, киптерүче, келәтләргә кертүче ачык йөзле апалар да үз итте аны.

Беренче көн яңалыкка бай иде, күңелле үтте. Көз ияләшкәч, җаен алгач, бер авырлыгы да юк бу эшнең, дип сөенде. Комбайннар күз бәйләнгәнче ашлык суга. Чык төшмичә эштән туктамый. Машиналар агылып кына тора. Тамак ялгарга да вакыт тими кайчак. Баштарак амбарда эшләүче апалар өйләренә чәйгә чакырып караса да, Айзирә кыенсынды, бармады. Бабасы әйтмешли, постны ташлап китәргә базмады. Кабат чакыручы булмады. Өйдән алып килгән коры-сары: пешкән күкәй, кабыклы бәрәңге, яшел суган, кыяр ише ризык белән тукланырга калды. Әле дә ярый, алма бакчалары авылда бер дигән: бабасы утырткан биш төп алмагачның һәркайсы тиңсез хәзинә. Җәйге алма өлгерә тора, өлгергәне коела тора. Иртән җыеп алган ярты күлүк алма көнозын юанырга җитә дә, бетә дә: алма кимереп юана кыз.

Көн аралаш йә тана, йә сарык суеп, читтән килгән шоферларны колхоз ашханәсендә итле ризык, борчак ашы, бәрәңге боламыгы белән сыйлыйлар дип сөйлиләр. Кыз читтән килгәннәр исемлегенә кертелмәгән, күрәсең, чакыручы юк. Хәер, эштән бүленеп барып йөрмәс тә иде. Алтынга тиң орлык кайта бит, көшел зурая. Йөк бушаткан арада егетҗилән шаяртып аңа сүз кушарга өлгерә:

– Кем бәхетенә тугансың икән син, гүзәл кыз бала? – дигән була әнә берсе.

– Бүген мин озатам сине, матур кыз! – дип елмая икенчесе, күкчәчәк төсле зәп-зәңгәр күзле, арыш саламыдай алтынсу-сары чәчле, озын буйлысы.

Кыз серле елмая, көлемсери, өздереп: «Юк!» дияр иде, әле кайтасы да бар. Кем белә, комбайннар кайчан туктар, төн уртасындамы, иртәрәкме? Әгәр дә әйтми-нитми таралышып бетсәләр, калырсың утырып, горур башыңны иеп!

– Алай да син бу шома егетләргә ышанып бетмә, – дип кисәтә казакъ агай – Җикән дип атый аны кыз. – Теге хахул: Юрийны әйтәм! Җүри җөри, җүри генә шаярта дип бел. Күңел кылыңны тарткалый, ягъни. Уенда нидер, белгән юк.

– Кеше уен уку сәләте миндә дә юк, – дип көлә кыз. – Менә сезне Җикән ага дибез. Җикән камыш ягъни. Охшаганмыни сез камышка? – Тәбәнәк буйлы, төптән юан агайга җикән исеме һич ятышмый: рәхәтләнеп көлешергә шул җитә.

– Исемдәмени хикмәт? – дип сүз кыстыра ашлык җилгәрү белән мәшгуль авыл апасы да. – Кыз балага күз салучы, сүз кушучы кырык булыр. Кырык беренчесе – чыбык! Иделгә таянма, ир-атка ышанма, дип хак әйтә әбиләр.

Әллә чынлап, әллә юри: «Матур да матур!» дип өзгәләнүче «берәүгә» күз дә сирпемәс иде дә, тегесе кыз күңелен күрү хәстәренә керешә. Кичәгенәк чәй эчәсе килеп йөдәгән иде, Юра шуны сизде: «Сыйлан, Матур!» – дип, сап-салкын тәмле чишмә суы алып килде. «Матур» диюенә дә ышана башлыйсың хәтта.

– Сыйларга сыең булмаса да, сыйпарга телең булсын! – дип куя Җикән ага.

Сусаганда су – зур сый, дип акыл сатып тормас бит инде Айзирә! Әйтсә соң?! Әллә матур түгелме



ул?! Кушучка сыеп бетәрлек нечкә бил, зифа буйсын, иннек-кершән тимәгән ап-ак йөзенә ямь бирүче сызылып киткән кашлар, туры җыйнак борын, сөрмәле яшькелт-зәңгәр күзләрне каймалаган озын керфекләр, бөдрәләнеп иңнәренә сибелгән куе коңгырт чәчләр – һәммәсе дә үзенеке ич! Берсен дә сатып алмаган, каш-керфегенә буяу тимәгән. Энҗе тешләрен балкытып көлсә, йөзе яктырып китә. Тик торганнан көлеп йөрми ул. Көлсә, көләрлеге бар. Әнә, Казан университетына укырга китәм дип җилкенеп йөрүче Нәҗип – Таштау авылы мәктәбеннән үк таныш егет – аны күрде исә: «Әһ, кызый, яндырасың йөрәгемне», – дип, күкрәген тотып «аһ» иткән була. Өч яшькә генә олы, район газетасына тәрҗемәче итеп эшкә алдылар үзен. Дөньяның бер хыялые, каләм кыштырдатырга маһир. Айзирәгә язган хатларын укысаң «аһ» итәрлек. Айдагы Зөһрә кызга, ай янындагы якты йолдызга тиңләгән ул шигырьләр кызкыркын көнләшеп үләрлек! Әле дә ярый аңа багышланганын белми берсе дә.

Тау булып өелгән арыш, бодай көшелләре янында уйланып утырырга вакыт тими. Югыйсә яратты Айзирә ындыр табагын да, «Эш булсын!» дип туктаусыз кыштырдап йөргән апаларны да, алтын тавына тиң игеннең көн саен гынамы, сәгать саен өелә, арта баруын да... Хатыннар сүзенә ышансаң, Чокырча амбары тирә-яктагы авыл халкын ачлыктан коткарып калган серле келәт икән!

– И-и апаем, сез күрмәдегез ул елларның михнәтен! – дип башлый Сафия апа дигәне. – Туйганчы ипи ашар көн булыр әле дигән өмет кенә яшәтте безне. Күз карасыдай күреп, кадерләп үстергән, урылгансугылган ашлыкны кырып-себереп озату, дәүләткә тапшыру гадәти хәл иде ул чак. Үзең ач, балаң ачтан үлә дию юк, эшлә, бир, диләр! Кая гына озатып бетергәннәрдер, кем белгән! Таякка эшли халык, хезмәт көненә иген өләшерләр дип көтәсең, рөхсәт юк. Кеше хәлен аңлый торган кешелекле җитәкче Гыйльметдин Рифкатенә мең рәхмәт. Ярамый диюгә карамый, яңа уңыштан арыш өләште халыкка. Ипи салдык, яшибез әле, дип куанырга өлгермәдек, районнан тикшерү, комиссия килеп төште. Морҗадан чыккан төтен исе районга кадәр җиткәнме, кемдер чакканмы, башбаштаклыкта гаепли болар рәисне. Амбарларны тикшерәләр, йортларга тентү керә. Чират Чокырчага җитә. Киләләр, карыйлар, ындыр табагы буш. «Ә теге амбар ачкычы кая?» – ди бер акыллы баш. «Удмуртия җире ул, безнеке түгел! Актарынып, тентеп йөрергә рөхсәт бармы?!» Менә шулай саклап калды зирәк ир халыкка өләшәсе ашлыкны. Коткаручыбыз, дидек без аны», – дип тәмамлый сүзен Сафия апа, керфегенә эленгән яшь бөртекләрен ак яулыгының чите белән сыпырып.

***

Ул кичнеме? Ул кичне гомер онытмас Айзирә. Көн дә өенә озатып куюны гадәт иткән Җикән ага авырып киттеме, бүтән эш куштылармы, күренмәде. Кыз ындыр табагында ялгызы торып калды. Каравылчы бар барын, чукрак шул.

Айның тулган чагы иде. Яп-якты. Төн уртасы җитеп килә димәссең. Тып-тын. Ник бер гөрелте, ни машина, ни комбайн тавышы ишетелсен! Көнозын кызу кояш астында, шау-шу, тузан арасында кайнашып алҗыганга, баштарак тынлык тансык тоелды. Бераздан күңелгә шом керде. Курку эчкә төште.

– Ялгызымны калдырып киттеләрме? Оныттылар җирдә мин барын...

Еларга да, көләргә дә белми беравык өнсез калгандай басып торды.

«Басуны кырып-себереп киләбез, уракны бетерәбез», – дип сөйләнүләрен чынга алмаган иде, хак булган, күрәсең. Инде нишләргә? Кая барырга?

Еракта сукыр тычкан уты сыман ялтыраган саран яктылык күңелдә өмет уятты. Нурлы ут көлтәсен тыны белән тартып алырдай булып көтә иде инде ул.

– Онытып калдырганнар бит сине, Матур! Казакъ бабаң чирләп киткән. Бая ук таралышып бетте бит басудагы халык. Сизмәдеңмени? – Юри түгел, чынлап кайгыртучы бар икән аны! Ир-егетне кочаклап алырга әзер иде ул. Алай да сер бирмәде, сүзсез генә кабинага кереп утырды. Шулкадәр борчылу эзсез узамыни? Үпкә дә бар. Кинәт кенә хәлсезлек, битарафлык биләп алды аны. Сөйләшәсе дә килми, тизрәк кайтып җитәсе дә урынга авасы! Йоклыйсы!

Күзләр үзеннән-үзе йомыла, керфекләргә балавыз ябыштырганнар әллә?!

Дыңгыр-дыңгыр килде дә, мотор кинәт сүнде. Шофер сикереп төште.

– Әй, Матур, син дә һава сула. Тынчу, бөркү кабинада. Эш чыкты монда.

Ай яктысында, әбисе әйтмешли, энә сапларлык. Кыр яп-якты. Айның тулган чагы күңелне алгысыта, әллә нишләтә. Айзирә теләр-теләмәс кенә төште. Әллә ничек, җиңелчә генә баш әйләнә. Йокы килә дә, килми дә кебек. Аяклары үзеннән-үзе буй-буй булып тезелеп киткән салам кибәннәренә таба атлады. Хуш исле саламга баш төртәсе дә... Моторда казынган егет дәште:

– Син, кызый, ерак китмә. Салам арасында адаша күрмә. Хәзер була бу...

Күпме гомер узгандыр, ярты сәгатьме, әллә ярты төн, кыз азгамы-күпкәме онытылып, йоклап алды бугай. Дегет, май исе аңкып торган дәү куллар аны йомшак кына сыйпый, иркәли иде. Сискәнеп башын күтәрде, иреннәр генә: «Кирәкми!» – дип пышылдады. Йокы исереклегеме, ә бәлки егетнең көчле куллары аны кочагына кысканнан-кыса барып, тәмам хәлсезләндергән иде инде.

...Тулган ай алданган кыз баланы әллә кызганган, әллә шелтәләгән сыман мөлдерәп, туп-туры аларга карап тора, Айзирә тыела алмый үксеп елый иде.

– Белмәдем бит... Ник әйтмәдең саф кыз икәнеңне?! Үзең риза дип белдем ич! – Өзек-төтек

җөмләләр, төче сүзләр, юатуга да, яратуга да охшаган аһ-уһлар – кирәге бармы аларның хәзер... Туй узгач, дөмбергә диясе генә калды!

***

Таң сызылуга коеп яңгыр яварга тотынды. Күкнең төбе тишелгән гүя: коя да коя. Икенче, өченче көнне дә туктарга исәбе юк иде. Бөркү, эссе һава тәмам әлсерәткән агач-куаклар, чәчәк-үләннәр дымга тиенде. Башта печән, аннан урак өстендә иртәдән кичкә кадәр ял күрми нык арыган халык мунча якты, мич ашы пешерде, рәхәтләнеп ял итәр, көч җыяр өчен кулай хозур вакыт килүгә сөенде.

Тик Айзирәнең генә бөтен тәне, тәне генәме – җаны, бар вөҗүде тынгы белми, эче-тышы ут булып яна. Торырлык, сөйләшерлек, эндәшерлек хәле юк.

Әнисе курка калды, «авыл брачы» Фәридә апаны алып кайтты.

– Кояш суккан дисәң дә... Үтәли җил – сквозняк үпкәсенә бәргәнме?! – Ул да аптыраган иде. – Кичекмәстән район хастаханәсенә озатырга туры килер.

– Юк! Кирәкми! Беркая да бармыйм! – Айзирә, куркудан хәлсезлеген дә онытып, торып ук утырды. – Терелермен әле!

***

Әнисе аны күздән яздырмаячак. Иртәме-соңмы, аның хәл-халәте илгә-көнгә фаш булачак. Өйдә ятып торудан эш чыкмас. Йөрергә кирәк, чыгарга!

Су тарта бугай аны. Күл буена килде. Су тирән монда, муеннан икәнен дә белә... Болганчыграк яшькелт суга кереп чумарга да... Чыкмаскадыр, бәлки!


Елап юанырга күзендә тамчы яшь калмаган. Арыш саламына капланып үкси-үкси күп елады. Бар булган күз яше, курку-хәсрәте түгелеп беткән гүяки.

Эче агызып алынган йомырка кабыгы кебек бупбуш ул. Тик җан сызлый.

Суга чуму, күмелү өчен кыюлык та, батырлык та кирәк түгел ич. Кердең, барасың, барасың да күмеләсең. Бар да бетә. Алай гына бетсә иде ул?! Әнкәсе нишләр? Юньсез кызы артыннан күлгә ташлансынмы?! Энесе бар, сеңлесе, апасы. Үз-үзеңә кул салуны хупламый дин дә, гавам да. Килешмәс бу гамәл.

Дөнья матур, дөнья киң дип, ваемсыз яшәп булса икән! Авылда да озын телле тутәйләр җитәрлек. Сөйләрләр-сөйләрләр дә бер туктарлар, дисәң. Кайгы кайгыга охшамый, урыны бер дә бушамый. Үзенеке үзенә җитә ич һәркемнең...

Әгәр... җилдән туган бернәрсәне... итәгендә китерсә? Үзенә генәме, әти-әнисенә дә, туганнарына да хәсрәт! Хурлыгы ни тора, ояты! Йөрәгеннән өзелеп төшкән сабый димәсләр, мыскыл итәрләр... Шашкан! Кызганасың, тумаган тайның билен сындырасың?! Шулчак таныш тавыш ишетелгәндәй сискәндерде:



Рәсем: Наталья Васильева



– Менә син кайда икән? Эзлим, эзлим. Ә син... төнбоеклар күзлим дисеңме?

Авызын ерып аңа таба атлаучы егет Нәҗип иде. Гамьсез кешеләр дә бар шул, рәхәт итеп көлә. Ап-ак күлмәктән, ак чалбардан иде ул. Аклык бөркелеп тора үзеннән. Чирәм юпь-юеш, моны сизми, Айзирәгә терәлеп үк утырды.

«Утырма, пычранасың», диясе килсә дә, кыз авызыннан сүз чыкмады.

– Дөнья бетереп эзләп йөрим бит мин сине! Уракны төгәлләгәнсез икән. Интервью әзерлим. Синең авыздан бер-ике сүз. Газетага язарга яраклы...

– Яраксыз, бернигә яраксыз мин! – Күкрәктән йолкынып чыккан аваз телсез итте: егет, күзләрен тутырып, ялгыш ишеттемме дигәндәй, аңа текәлде. Ә Айзирә тораташ булып каткан иде. Янәшәсендәге егеткә күз дә төшермәде.

Нәҗип аның кулын учына алды, озаклап, йомшак кына сыйпап торды. Кулын тартып алмады Айзирә. Дөнья гаменә, иркә-назга, ир-атка битараф иде.

– Ни булды? Сөйлә! – Катгый да, ягымлы да яңгыраган шул сүз уяттымы, Айзирә соңгы көннәрдә күргән-кичергәннәрен энәсеннән җебенә кадәр, түкми-чәчми бәян итте дә салды. Шулкадәр авыр йөкне күтәреп тора алмый иде аның нәфис, әмма зәгыйфь күкрәге. Беразын булса да түгәсе, бушанасы килә иде.

Хәер, тәмам чишелеп бетмәде, иң түрдәгесен чәчеп бетермәде: «Ишетче мине, мәрхәмәтле Ай, бәладән коткар! Баладан!» – дип ялваруын, тулган айга карап өзелеп елавын, акылдан язгандай кылануын сөйли алмый икән әле ул.

– Йә, беттеме? – Нәҗип тыныч кына аның кулын янәдән кушучына алды.

– Бетәр иде, әгәр бу газап бетсә? – Аптыраумы бу, ярдәм өмет итүме...

– Аңладым. Куркасың син... Туасы җан – туар. Беләм, ирсез бала табу гөнаһ санала. Кеше сөйләр, гаеп итәр дип борчылуың юкка. Бар да үтә... Бар да үтә дип язылган Сөләйман балдагына!

– Юк, аңлый алмыйсың... Әтәй үтерә мине! Әнәй акылдан шашачак.

– Шашма. Син гаепле түгел! Теләсәң, бүген үк, хәзер үк авыл советына барып язылышабыз. Кем гаеп итәр? Без бер-беребезне яратабыз... диярбез.

– Яратасыңмы соң син мине? – Әллә кычкырып әйтте, әллә уйлады гына, әмма аның ни әйтергә теләгәнен егет шул мизгелдә төшенгән иде. Елмаеп:

– Күрмисеңмени?! – диде дә кысып кочаклады. Рәхәт, җылы иде кочагы.

***

Аннан соң да күпме сулар аккан. Узган гомер күз алдында. Шау-шусыз, тыйнак кына табын корып мәҗлес ясадылар. Никах укытуга икәве дә каршы иде, әнисе өзми-куймый: «Мәңгелеккә камсамул дип түгел, мөселман өммәтеннән дип китәсе. Бәләкәй якта белмәгән атлы булып утырырсыз», – дигәч, риза булдылар. Тату гына яшәп киттеләр. Тормышларын әле дә начар дип булмый.

Тик җан ярасы төзәлми, ник кан саркып тора икән? Бу сорауга җавап юк.

Ай артыннан – ай, ел артыннан ел үтсә дә, Айзирә хәләлен ни бер малай, ни бер кыз алып кайтып сөендерә алмады. Вакытын белеп кенә яшь ай калка. Тула. Тулган Ай яктысы, сихерле нуры хатын күңелен алгысыта. Теге чакта, юләр, бүредәй улардай булып: «Мәрхәмәтле ай! Бәладән – баладан коткар мине!» дип ялваруы исенә төшә дә тәне чымырдап китә. Бәндәнең табигать илә ничек тоташканын, күпмегә ярашканын берәү дә белми. Күрәзәче дә фаразлый гына! Ай аның шул чактагы аһ-зарын чыннан да ишеткән дип фаразласаң... Айга ашкан Зөһрә кыз – әкият димә! Тилмереп үзенә дәшкән ятимәне үзенә алган Ай. Ашыгып, ахырын уйлап бетерми кылган гамәл җанны гел борчып, тынгысызлап торуы хак бит: ләззәтләнеп бала имезү, итәгенә утыртып сабыен сөю бәхетеннән мәхрүм ул.

Табибларга да күренде. «Исеменә «Ай» сүзе кергәннәр тәэсирләнүчән, көйсезләнүчән. Үтәр! – дип юатты берсе. – Сау-сәламәт хатын син. Булыр әле балагыз да! Көтәргә кирәк!» Күпме көтәргә кирәген генә әйтмәде. Хикмәт, бәлки, исемдә дә түгелдер. Тормышлары бөтен. Укып бетерүгә Нәҗипне җаваплы эшкә күчерделәр. Хатын-кыз кызыгырлык чибәр, таза, олпат ир-ат ул. Яшь чырайлы замана кешесе, тик утыруны белми. Булдыклы, абруйлы җитәкче булып үсте.

Айзирә авылда калган булса, «читават» булып йөрер иде. Шәһәр бичәсенә әйләнде, өзелергә торган нечкә бил сагынырга калды. Элекке чибәрлеге җуелып бетмәгән әле, күзләре генә моңлы. Әнкәсе, изге җаннардан булсын, тау башына – мәңгелек йортына күченде, әтиләре, сугыш гарибе, ялгыз калды. Каңгырып йөри-йөри дә, көтә балаларын. Ә Нәҗип авылга кайтырга ашкынып тормый. Әллә иренә, әллә ояла. Янәсе, эштән бушамый. «Күрәсең ич, командировкадан кайтып кермим, үзең генә кайтып кил», – ди дә котыла, ялгызлыкны хуп күрә.

«Әллә инде күңеле тар, әллә сөйгән яры бар», дип җырлыйсы килгән чаклары бихисап Айзирәнең. Әмма көнләшү, мөнәсәбәтләрне ачыклау белән мавыгуның ахыры хәерле булмасын сизә. Тәрбиягә бала алсак дигән уен кыяр-кыймас кына Нәҗипкә сиздереп карады. Ир йә ишетмәмешкә салышты, йә сүзне икенчегә борды. Ә кайнанасы: «Үксез бозау асрасаң, авыз-борының май булыр, үксез бала асрасаң, авыз-борының кан булыр!» – дип, шунда ук кырт кисте.

Бармы йөрәк серен аңларлык берәрсе? Енекәше – кеше кешесе. Сеңлесе яшь әле, апасын дөнья мәшәкате баскан. Авариягә очрап ире үлде, ике бала белән очын-очка көчкә ялгап яшәп яткан көне. Кырыс ул, моң-зарга исе китми:

– Юкка кыбырсыйсың. Баладан кем рәхәт күргән диң дә тыныч кына яшә.. Бар ич үз рәхәтенә сөенеп яшәүчеләр, – ди, юата, имеш. – Китап укы, шөгыль тап, эч пошуың басылыр. Картларга, ятимнәргә ярдәм итү дә – савап, – дип куя.

Акыл сату җиңел ул, ярдәм кулы сузу кыенрак икән. Айзирә аңа:

– Апа җаным, Алияне бир безгә, тәрбияләп үстерериек! – дип карады.

Кая ул, коры утындай кабынып китте апасы, үпкәләтәм дип тә тормады:

– Җаныңнан өзелгән газизеңне кеше кулына тапшырып булмый ул, апаем.

Шулай да: «Тормышың җиңелдән түгел. Бездә ризыкка, кием-салымга кытлык юк. Җәй көне бер-ике ай торып карасын», – дип бик ялынгач, көчкә ризалашты. Нәҗип белән икесенең ялын бергә туры китереп, өчәүләп Кырымга да бардылар, авылда бабасына иптәш булып та байтак кына яшәде Алия. Тәмам иялəшеп беткән кебек иде. Нәҗип булып Нәҗип бөтенләй икенче кешегә әйләнде. Эшеннән соңармый туп-туры өйгә кайта, тәм-томга акча кызганмый. Ә кичләрен 5 яшьлек кызчыкны муенына атландырып, ат булып кешнәргә дә әзер. Бәләкәй велосипед та алып кайткач, җизнәсенә тәмам берегеп бетте сабый.

Айзирәнең читләтеп кенә кылларын тарткалавына да инде риза сыман:

– Безнең кызыбыз булып бездә генә каласыңмы? – диюенә баш кагып куя.

Бәхетле иде Айзирә, күкнең җиденче катында йөзгәндәй хис итте ул үзен.

Әмма ләкин... әнисе кайткач, үзгәрде дә куйды бәләкәй кызчык. Башта үз әнисен ятсынган кебек тә булды. Әллә чынлап, әллә болай гына әнкәсенең:

– Монда рәхәт, дисез, әллә каласыңмы, кызым? – диюенә чәчрәп чыкты.

– Юк!

Җизнәсе дә аптыраган кыяфәт белән сүз кыстырмакчы булды.

– Ник алай дисең, Алия? Сүз куештык, калам дидең ич. Әллә үпкәләдең?

Нарасый мөлдерәмә күзләрен җизнәсенә төбәде, әкрен, әмма чатнатып:

– Әни бер генә була ул! – диде дә Айзирәнең үзәген тагын бер кат өзде.

***

Ай тулар чак җитеп килгәнгәдер, Айзирәнең чигәләрен кысып, башы авыртып тора иде. Саф һавада күңел ачылмасмы дип, өч катлы Мәдәният йорты эргәсенә җәелгән парктан әйләнеп кайтмакчы булды. Малайлар шау-гөр килеп шар суга, «Городки» уйный. Эһ, булса иде шундый бер улы, шаян булсын, шук, түзәр иде.

Шулчак колагына сабый бала елаган тавыш керде: «Көпә-көндез саташам, ахры», – дип уйларга да өлгермәде, «Городки» уйнаучы малайларның берсе кычкырып:

– Апа, агач ышыгындагы теге колясканы арырак тәгәрәтегез әле. Өстенә шар төшәр дип куркып кына уйныйбыз! – дип аваз салды. Ханым аптырап калды. Каян күргән ул коляска? Ялгыш түгел, ә-әнә, ерак та түгел бишек-арба тора икән. Бала елаган тавыш шул тарафтан ишетелгән.

Айзирә ал төстәге бишек-арбага якынлашты. Сытылып елаган сабыйның челтәр япмасын күтәрде. Кечкенә шешәгә имезлек киертелгән: су бу!

– Елама, нәнием, елама! Су эчеп кара! – Нарасыйның туктарга исәбе юк иде. Арбаны этеп, тирбәтә-тирбәтә шактый җир китте. Ник берсе туктатсын. Хәер, бар икән андый зат. Озын саплы себерке тоткан бакча себерүче хатын килеп җитте.

– Кая тәгәрәтәсең аны? Тимә кеше баласына! – дип ачулы мыгырданды. – Илтеп куй урынына. Хәзер үк!

– Куян баласы түгел. Күрәм! Малайлар өстенә шар төшәр дип курка.

– Ә, алай икән. Әнкәсе күренми никтер. Бу вакытта имезергә чыга иде...

– Мин аны иясез – ташландык бала дип торам.

– Булмаганны! Ал җилкәннәр көтеп хыялланган бер җүләрме әллә син? Ал бишек арбага салып, ал ефәк юрганга төреп чыгарып куйганнар ди сиңа бала...

Сүз көрәштереп тору урынсыз, мәгънәсезлек иде. Бала да тынычлап йоклап китте. Айзирә паркны бер әйләнде, ике, өч... Бишек-арба һаман шул төштә. Малайлар да таралышып беткән. Кызык та соң бу шәһәр, бер аймакта яшәгән адәм балалары бер-берсен белми, танымый. Үтеп-сүтеп йөрүчесе дә битараф. Колясқада кемнең сабые ята дип килеп караучы да юк. «Бу вакытта чыгып имезә торганые!» дигән хатын да күренми. Тып-тын бакча.

Айзирә песи адымнары белән йомшак кына басып арбага якынлашты. Як-якка каранмаска, шик уятмаска! Беркем сизмәсен, белмәсен. Арбаны өстерәп киткәнне күрүче булса... Тик сабый тыныч йокласын, уянмасын!

– Йокла, сабыем, бәү-бәү ит. Мин сиңа әкиятләр сөйләрмен. Яратырмын...

***

Ал бишектән тавыш-тын ишетелмәде. «Йоклый!» дип фаразлады хатын.

...Өч катлы бинаның иң өске катында эш белән мавыгып утырган Ана, баласының имәр вакыты җиткәнен сизеп, баягынак чыгып, сабыен үзе белән эшенә алып кереп киткән, ал бишек-арбада ташкурчак кына йоклап калган.

...Ай тулган чак иде.



ЯШӘЕШ

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Соңгы арада яратып укыган әсәрем – «Язмыш җиле» романы булды. Авторы да бик таныш, якын кеше – «Яшь ленинчы», «Ялкын»нарда баш мөхәррир булып эшләп, балалар матбугатында чарланып, хатын-кызлар журналын җитәкләүгә күчкән, «Сөембикә»не халыкара аренага чыгарган талантлы каләм иясе, күренекле җәмәгать эшлеклесе Роза Туфитуллова.

Романның исеме үк әсәрнең күптөрле вакыйгалар, күптөрле язмышлы кешеләр турында барачагын белдереп, алдан ук ымсындырып тора. Ә укый башлагач инде, берсеннән-берсе кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгалар үз эченә бөтереп алып кереп китә, ягымлы һәм матур теле җай гына бер дулкында тибрәтә. Әсәрнең төп герое Гөлсем – милләтебез горурлыгы. Гөлсем Камалова образы аша татар хатын-кызларының кайда гына, кем генә булып эшләүләренә карамастан, милләт язмышы сагында торуларын язучы бик ачык сурәтли. Татар хатын-кызлары тырыш та, горур да, максатчан да, әдәбиятлы һәм мәдәниятле дә.

Мәхәббәт темасы да киң чагылыш тапкан. Халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукайга хатын-кызларның, бигрәк тә Гөлсем һәм Зәйтүнәләрнең чиксез мәхәббәте аеруча матур, дулкынландыргыч итеп сурәтләнә.

Тукай турында нинди генә әсәрләр иҗат ителмәде. Шагыйрь турында күп беләбез дисәк тә, әлеге әсәрне укыгач, аның иҗаты һәм тормышы бөтенләй яңа яктан ачылды минем өчен.

Әсәр шулай ук халкыбызның олуг һәм зыялы шәхесләре Гаяз Исхакый, Муса Бигиев, Фатих Әмирхан, Фатих Кәрими, Йосыф Акчуралар турында мәгълүматка бай.

Һәр бүлек, һәр бит мавыктырып та, уйландырып та ерак елларга алып кереп китә. Тирән кичерешләр белән бер тынга укыла торган әсәр менә шундый була ул. Язучы анда тупланган материалны күп еллар дәвамында бөртекләп җыйган: кайларда гына булмаган, кемнәр белән генә очрашмаган, күпме генә чакрым юллар үтмәгән!.. Чорлар, вакыйгалар, шәхесләр... Тырышлык, тирән белем, эзләнүләр, талант... Һәммәсен акылы һәм йөрәге аша үткәреп, җаннарны кузгатырлык матур әдәби әсәр иҗат итә алган ул. Романның тагын бер үзенчәлеге шунда: ул шигъри тезмәләр белән үрелеп бара һәм эчтәлекне тагын да мәгънәле итә. Төгәл фактларга, документларга нигезләнеп язылуы исә дәрәҗәсен бермә-бер күтәрә. Татар тарихының бер чорын күзалларга, вакыйгаларны колачларга мөмкинлек бирә.

«Язмыш җиле»н яратып, андагы танылган шәхесләрнең үзләрен күреп сөйләшкәндәй хисләр кичереп, тәмам онытылып укыдым. Гөлсем образында затлы-зыялы, белемле-мәгърифәтле, инсафлы-тәрбияле милләт кызын күреп сокландым. Бу матур образны иҗат иткән Роза ханым Туфитуллова үзе дә Гөлсем кебек нәфис тә, зәвыклы да, батыр да, булдыклы да бит! Әйтерсең ул үзенең асыл сыйфатларын героена күчергән.

Җәмилә СИБГАТУЛЛИНА.
Балтач районы, Салавыч авылы.

Гомерем буе чәчәкләр яраттым. Ул минем, ират затыннан булган кешенең, бер йомшаклыгыдыр инде.

Кама Тамагы районының туган авылым Ишемдә яшәгәндә чәчәкләргә сокланганымны хәтерләмим. Әллә алар булмаган, әллә үзем күрмәгәнмен... Бездә урман аланнары юк, ә яшел болыннарны язын-җәен көтү таптап йөри. Бәлки, шуңадыр...

Табигатьнең бар матурлыгын беренче тапкыр Тәтештә укый башлагач кына күрдем, чөнки шушы елны күзлек ясаттым. Аны киеп чыккач, исләрем китте: дөнья никадәр матур икән бит ул! Төсләр шундый ачык, җете, көн яктысы – шундый нурлы, ә төнге күктә йолдызларның саны да, исәбе дә юк...

Без яшәгән Чибәркүл районы урманнар, басулар белән аралашкан. Апрель айларында чәчүгә төшәбез. Ул вакытта аланлыкларда, чәчеп

Фото: Анна Арахамия

үстергәндәй, умырзаялар тезелешкән була. Әйтеп бетергесез матурлык! Июнь аенда аланнарны зәңгәр нурга күмеп күгәрчен күзләре (незабудка) шау чәчәккә төренә. Аларны җыеп алып кайтып, бүген мине кайгыртып яшәүче киленемнең туган көненә бүләк итәм. Ә минем Люциям июль аенда туган. Сибгат Хәким язганча, чәчәкләре җәйнең ишләрәк дип, аңа инде җәй бизәкләрен кочагы белән тапшыра идем. Люциямнең миңа язган кырыклап хаты бар. Бүген аларны кат-кат алып укыйм, хатлар өстенә яшем коела... Хатирәләремне шигырь итеп ак кәгазьгә тезәм. Люциям булса, беренче укып чыгып, фикерен белдерер иде...

Менә быел да шау чәчәкле җәйнең ахыргы аена кердек. Исән кешегә җәе дә, көзе дә хәзер килеп җитә. Исән-имин яшик.

Нурислам АЙБУЛАТОВ.
Чиләбе өлкәсе, Чибәркүл шәһәре.



Ризаэтдин Фәхретдиннең: «Балалары һәм гаиләсе кеше өчен бер әманәттер. Аларны әхлаклы итеп тәрбияләү, гореф-гадәтләребезне өйрәтеп, милли һәм дини тойгылар белән үстерү безнең бурычыбыздыр», – дигән сүзләре бар. Бала – ата-ананың күзгесе, диләр. Мин моны үз гаиләбез үрнәгеннән чыгып әйтәм.

Әнием, Галиева (Шәфикова) Алсу Хәмзә кызы 1949 елның 14 октябрендә Оренбург өлкәсенең Иске Тирес авылында туа. Әтисе, Хәмзә бабам, Бөек Ватан сугышы ветераны, укытучы була – рус һәм немец телләреннән укыта.

Сигезенче классны тәмамлаган кызына бабакай Габдрахман Әбсәләмовның «Ак чәчәкләр» романын бүләк итә. Шушы бүләк әнием тормышында хәлиткеч роль уйный да инде: ул Башкортстанның Бәләбәй медицина училищесына укырга керә. Әни студент елларын кызык итеп искә төшереп сөйләргә ярата...

«Укуны тәмамлар алдыннан безне дәүләт практикасына җибәрделәр. Ул заманда әни Кыргызстанның Ош шәһәрендә яши иде. Иптәш кызларым – Илсөяр һәм Рәйлә белән практиканы әни янында үтәргә булдым. Чәчләрне ясатып, заманча матур күлмәкләребезне алып, сумочкалар тотып, ерак юлга чыктык. Хыялыбыз – зур шәһәр хастаханәсендә шәфкать туташлары булып эшләп, дөнья күреп, үзебезне күрсәтеп кайту иде...

Әни безне шатланып каршы алды. Дәртләнеп, Ошның үзәк хастаханәсенә эшкә урнашырга киттек. Барсак: «Кызлар, безгә санитаркалар кирәк иде бит... Палаталарны юып, авыруларның асларын чистартып торырга риза булсагыз, без сезгә бик рәхмәтле булыр идек...» – димәсеннәрме?! Кәефләр төште инде, без теләгәнчә булмады бит, ләкин башка чара юк, ризалашырга гына калды... Халат-перчаткалар киеп эшкә тотындык. Ике ай ярым вакыт сизелми дә үтеп китте. Эштә сынатмадык, татар кызлары тырыш икәнен күрсәттек. Практикабыз тәмамлануга без, мактау сүзләреннән тыш, ул вакыт өчен бик яхшы эш хакы да алдык. Беренче хезмәт хакыбызга күп итеп киемнәр, күчтәнәч-бүләкләр алып, тотып килгән сумочкалар урынына зур чемоданнар тутырып кайтып киттек. Шулай итеп, практикабыз күңелле дә, файдалы да булды. Ул безне эштән курыкмаска, авыруларның хәлен аңларга, кешеләр белән яхшы мөгамәләдә булырга һәм алган һөнәреңнең кадерен белеп эшләргә өйрәтте. Кайткач, санитарка булып эшләвебез турында әйтеп тормадык инде. Барысы да безне шәфкать туташлары булган дип уйлады...»

Училищедан соң әнием бергә укыган Илсөяр һәм Халидә апалар белән Башкортстанның Ярмәкәй районындагы ул вакытта гөрләп торган алдынгы «8 Март» совхозына эшкә урнаша. Авыл халкы аларның намуслы һәм тырыш хезмәтен әле дә рәхмәтләр укып искә ала.

Әни монда үзенең гомерлек мәхәббәтен – тирә-як егетләре арасында үзенең чаялыгы һәм үткенлеге белән аерылып торган асыл егетне – безнең булачак әтиебез Фаилне очрата. Ике яшь йөрәк никахлашып кавышалар, гөрләтеп туй уздыралар. Дөньяга бер-бер артлы өч балалары: абыем Илдар, мин һәм энем Ринат туа.

Хәтеремдә, әнием һәрвакыт татарча газета-журналлар яздырып ала иде. «Азат хатын», «Ялкын», «Кызыл таң», район газетасы өйгә гел килеп торды. «Азат хатын», соңыннан «Сөембикә» әниемнең иң яраткан журналы булды. Андагы мәкаләләр мисалында ул безне акны карадан, яхшыны яманнан аерырга өйрәтте.

Мин егерме ел инде балаларга башлангыч белем бирәм. Абыем – унбиш елдан артык дин әһеле, халыкка ислам дине нигезләрен һәм әхлагын өйрәтә. Бәләбәй шәһәрендә имам-хатыйп вазыйфасын башкара. Энем Ринат үз эшен ачып җибәрде. Өчебез дә әти-әни сүзеннән чыкмыйча, балаларыбызга шул ук тәрбияне бирергә тырышабыз.

Әнием Алсу утыз биш ел үз һөнәренә тугры булып, «Хезмәт ветераны» дигән мактаулы исем белән лаеклы ялга чыкты. Хәзер алар, әтием белән икесе, җиде оныкны тәрбияләшәләр.

Мин аларга чиксез рәхмәтемне һәм хөрмәтемне белдерәм. Сез булганга дөньябыз түгәрәк һәм бәхетле. Сезгә Аллаһы Тәгалә озын гомер, хәерле тигез картлык, корычтай нык сәламәтлек, баларыгызның һәм оныкларыгызның игелеген күреп яшәргә насыйп итсен.

Лилия АРСЛАНОВА.
Казан шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

ЧӘЧЛӘРЕҢӘ ҖИЛЛӘР ҮРЕЛМИ...

...Бу язманы укыганда сез дә шул халәттә булырсызмы икән? Өскә поезд килә. Товар поезды. Мин бала җитәкләгәнмен. Юк, аның кулын чытырдатып кысканмын. Берничә мизгел һәм... Берсеннән-берсе кыска ул мизгелләр эчендә ниләр уйлап өлгерергә була? Ул хатын – ике бала анасы – башыннан ниләр кичергән? Ә курчак кебек 9 яшьлек кызчык? Гөлназ...

Ак тасмалар инде җилфердәми,
Чәчләреңә җилләр үрелми.
Күзге җилләр түгел,
җаным елый
Сагышларым сүнми-сүрелми...

Тагын бер елдан соң әтисе шушы юлларны язачак... Җаны елаганга түзә алмаган көннәрдә...
Әйе, поездны туктату авыр – ул бу фаҗига кагылган гаиләләрне дә икегә бүлеп уза ала иде... Язмыш сынавы килгәндә бер-береңне, гаиләне ничек сакларга – Казан шәһәр филармониясенең концерт бүлеге җитәкчесе Рәис Шакиров һәм аның хатыны Гөлсирә ханым белән әңгәмәбез шул хакта. Ачыктан-ачык сөйләшәбез.

Гөлнур САФИУЛЛИНА

Һәр минутның кадерен белә башлыйсың: гомер, дөрестән дә, бик кыска икән…

Рәис: Чәршәмбе көн иде ул. 21 июнь… Алдагы шимбәдә безнең районның Сабан туе булды. Классташым, дустым, туганым Айдар кайтышлый хатыны, балалары белән безгә керде. «Әйдә, өйдә ятканчы Раушан белән Гөлназ безнең белән чәршәмбе бакчага барсыннар», – диде хатыны. Ризалаштык. Бакчалары безгә якын аларның, күперне чыгуга… Бу хәл кире кайтканда була. Безнең малай белән аларның ике кызы күпердән алданрак чыкканнар. Арттан товар поезды килгән. Поезд кычкырткач, ул хатын катып калган. Һәм кызның кулын ычкындырмаган… Айдар – хатынсыз, мин кызсыз калдым…

Поезд астына керә торган бала түгел иде ул. Холкы белән миңа охшаган иде. Бик шук иде – яшен ташы кебек. Биергә, җырларга яратты. Химиклар мәдәният сараена, Әнсәрия Кретова җитәкләгән ансамбльгә биергә йөрде. Бер видеоязма калды аңардан. Раушан белән икесе кыз озату йоласын төшергәндә катнашканнар иде. Тагын фотолары калды. Җырлаганда кигән калфагы… Гимназиядә бер бәйрәм дә аның чыгышыннан башка узмады. 13 нче гимназиядә укыды ул. Ата-аналардан гаризалар җыеп, аны ачу артыннан үзем йөргән идем… Безнең бөтен ишегалды белә иде Гөлназны. Озатырга да бөтенесе керделәр. Бу хәбәрне ишетүгә иң беренче булып Зәйнәп Фәрхетдинова белән Зөфәр Билалов килеп җиттеләр. Рәхмәт аларга… Ул көннәрдә янәшәбездә булган барлык дусларга да рәхмәт…

Минем туган ягыма – Арча районы Субаш Аты авылына җирләдек. Кабере өстенә кара гранит таш куйдырттым. Нәкъ менә шундыйны куясым килде… 8 яшьтә төшкән фотосын чокып ясаттым – ерактан күренеп тора. Ике зәңгәр чыршы утырттым. Авылга кайтканда да, киткәндә дә юлыбыз зират аша уза хәзер. Чардуганы эчендә, нигәдер, өч кешелек урын калдырганмын. Үзебезгә диптер инде…

10 яшьлек улыбыз күз алдында була бит бу хәл… Ул үзен моңа гаепле санады. Хәзергәчә шулай уйлый, оныталмый… Өч көн шок хәлендә йөрде. Аның өчен бик курыктым ул чакта… Өч көн, өч төн сөйләштем аның белән. «Улым, син берничек тә гаепле түгел», – дип аңлаттым. Беркөнне иртәнге өчтә, ниһаять, елап җибәрде, аннары инде рәтләнеп китте…

«Нишләргә, киңәш бирегез әле», – дип яныма килүчеләр бар. Безнеке кебек хәсрәт кичерүчеләр килә… Авыр инде, әмма бу хәсрәттән беркая китә алмыйсың. «Күпмегә кадәр авыр булыр?» – диләр. Искә төшкән саен һаман да авыр менә… Гаеплене табып булмый. Аны эзләргә дә кирәкми. Кайчак: «Өйдә генә торсалар ни була иде? Җибәрәсе калмаган», – дип уйлыйсың. Тик фаҗиганең кайсы яктан киләсен каян беләсең? Өйдә дә нинди-дер хәл килеп чыгарга мөмкин бит.

Кемдер биргән киңәшеңне тота, кемдер – юк. Эчүгә сабышучылар бар. Гаиләсен ташлап, яшь хатынга өйләнүчеләр. Бу хәсрәтне берни хәтерләтмәсен дип, оныту өчен башкага китәдер андыйлар. Ә мин, киресенчә, мондый сынау килгәндә хатының белән бергә булырга кирәк дип санадым. Ташлап китсәң, хәсрәте белән ул берүзе кала дигән сүз бит… Гөлсирә бик авыр кичерде бу югалтуны. Ир-ат барыбер ныграк ул. Без күз яшен яшерергә тырышабыз, хатын-кыз яшереп тә бетерә алмый. Булды инде, аерым-аерым елаган чаклар да, бергә дә…

Яшьрәк кешеләргә мин һәрвакыт: «Тагын бала табыгыз», – дим. Безнең үзебезгә дә ул чакта шушы киңәшне бирделәр. Ярый әле яшь идек, миңа – 34, Гөлсирәгә – 30 гына. Киткән бала урынын яңа туганы алыштыра алмый, әмма… Хатынга рәхмәт, ул миңа тагын ике кыз алып кайтты. Ел ярымнан соң Илүзәбез туды, аннан алты елдан соң – Язиләбез. Балалар хәсрәтеңне вакытлыча булса да оныттыра. Хәзер инде оныклар белән юанабыз – Тимерхан белән Раянабыз бар.

Илүзә холкы белән апасына охшаган. Раянада да шул холык…

Тагын нинди киңәш бирергә? Калганнар өчен яшәргә кирәк… Айдарга да җиңел булмады. Олы кызына – 10, кечесенә 7 яшь кенә иде. Берничә елдан соң кабат өйләнде. Тик, кызганыч, инде ул хатынын да югалтты. Берүзе яшәп ята хәзер.

Бик иртә тора иде ул. Күзен ачуга, килеп биттән үбеп китә иде. Шулай уята иде… Ничә еллар шул үбүләре җитмәде миңа. Егерме дүрт ел булды менә. Кичә генә кебек… Классташлары кияүгә чыктылар, инде балалар үстерәләр. Аларга карыйсың да, минем кызым да гаиләле булган булыр иде дип уйлыйсың… Авыр… Исемен кычкырып әйтү дә авыр… Иң зур хәсрәт – бала хәсрәте икән.

Гөлсирә: Шундый сөенеп китте ул көнне бакчага Гөлназ. Мин өйдә калдым. Рәис эшләре белән каядыр чыгып китте. Көтәм, көтәм, балалар һаман кайтмый. Кесә телефоннары юк чак бит әле – шалтыратып кына белешеп булмый. Ишеккә шалтыраттылар. Барып ачсам – бер хатын басып тора, артында Раушан белән Фәрдиянең ике кызы. «Гөлназ кайда?» – иң беренче соравым шул булды. «Балалар керсеннәр әле, минем сезгә сүзем бар», – диде таныш булмаган хатын… Өстемдәге халатны да алыштырмыйча чыгып йөгердем. Раушаннарны озата килгән хатын: «Исәннәрме?» – дигән соравыма, «Кая ул…» – дип җавап бирсә дә, күпергә таба йөгергәндә күңелемдә өмет бар иде әле: «Хәле авырдыр…» Ә үз күзләрем белән күргәч… Ул минутта күңелдәге чарасызлыкның зурлыгы! Баланы берничек кире кайтарып булмауны аңлауның авырлыгы… Икесенең дә бертөрле травма – баштан алып аякка кадәр. Уң яктан. Мизгел эчендә киткәннәр…

Тормышта төрле хәлләр булды... «Зур кайгыны да кичердек, монысын гына үткәрербез», – дия идем Рәискә.

«Ашыгыч ярдәм» килгән, милиция... Фәрдиянең кем икәнен дә белмиләр иде әле. Исем-фамилиясен, туган елын сорадылар. Айдарларның кече кызының кулында нидер булган – ул аны куркудан суга төшереп җибәргән бугай. Пляждан бу хәлне күреп торган халык балаларның берсе суга төшеп китте дип уйлаган – водолазлар чакыртканнар. Суга баткан баланы эзлиләр, тапмыйлар икән. «Юк башка бала, алар дүртәү генә иде, – дим. – Өчесе өйдә, берсе монда менә». Моргка алып киттеләр. Гөлназны тотам – ул әле җып-җылы. «Без соң нигә моргка барабыз?» – дип уйлаганым истә... Бу – көтмәгәндә килгән фаҗига, ә балалары авырып үлгән аналарга тагын да кыендыр. Безнең ишегалдында бер хатынның кызы үлде. Ул да Гөлназ исемле иде. 10 яшьлек баланың аналыгында яман шеш таптылар.
Күз алдына гына китереп карагыз...

Өйгә мине милиция машинасы белән кайтарып куйдылар. Подъезд төбенә халык җыелган. Кечкенә бала бит – бөтен кешегә дә кызганыч. Рәис тә кайтып җиткән, ул да алар арасында. Мин машинадан төшкәч, күзләремә шундый өмет белән карады!.. Барыбер яхшы хәбәр белән кайтыр дип көткән иде бугай. «Юк, Рәис, бала инде юк...» – дидем.

Казансу аша салынган, халык арасында «Горбатый мост» дип йөртелә торган борынгы күпер бу. Дәрвишләр бистәсе белән шәһәрнең «Төньяк вокзал»ын тоташтыра. Хәтәр күпер – үлем-җитем шактый булды инде анда... Аның бер ягында җәяүлеләр өчен киңрәк юл салынган, икенче ягында – таррак. Безнекеләр шул тар ягыннан чыккан. Ә анда юл тар булгач, халык рельслар өстеннән дә йөри. Борылыштан килеп чыкканчы поезд күренми. Әмма һәрвакыт юлның ул өлешенә җиткәндә кычкыртып килә. Төннәрен бу тавыш бигрәк тә каты яңгырап ишетелә... Рәис берара: «Әллә фатирны сатып, күчеп китикме моннан?» – дип тә уйлаган иде. Тәрәзәдән караган саен күз шул күпергә төшә иде бит. Аннары каршыга йорт төзеделәр – төнге поезд тавышлары да тоныкланды... Борылыштан чыккач, күпергә кергәнче 800 метрлар тирәсе ара бар. Пляждагы халык поезд килгәнен күреп: «Юлдан чыгыгыз!» – дип кычкырган. Фәрдия ишетмәгән... Борылып та карамаган. Уйланып барган, күрәсең. Үлем исереклеге беләндер инде. Товар поезды күпергә кереп, рельслар «сикерә» башлагач кына абайлаган ул аны. Кечкенә кызы гел кулына ябышып йөри иде Фәрдиянең – аны: «Тотынып тор!» – дип кырыйга чыгарып бастырган.
Үзе Гөлназ янына йөгергән. Янына барып җитеп кулыннан тоткан...
Юк, машинистны гаепләмим.
Безнекеләр дөрес юлдан бармаган. Гөлназ ирек ярата иде. Раушан аның кулыннан да тоткан булган – ычкынган. Күбәләк кебек, кулларын җәеп рельслар өстеннән атлаган...

«Аны мин саклап калмадым», – дип, Раушан бик озак үзен гаепләп йөрде. Җитмәсә, бакчага китәр алдыннан: «Улым, сеңлеңне кара!» – дип әйтеп тә җибәргән идем. Үзенә дә 10 гына яшь иде бит әле... Килен хәзер дә: «Искә төшерсә, Раушан һаман да «мин гаепле», дип елый, сагына», – ди. Югыйсә балаларны бакчага без үзебез җыеп җибәрдек, димәк, үзебез гаепле. Күрәчәк булган инде... Шуннан соң мин Илүзәне ничә яшькә кадәр гел җитәкләп йөрдем. Кулымнан беркайчан ычкындырмадым.

Рәис бик авыр кичерде.
Аның яшисе дә килмәде... Ир-ат көчле дип болай гына әйтәләр:
бу яктан бездән көчсезрәк алар.

«Однажды двадцать лет спустя» дигән совет киносын хәтерлисезме? Наталья Гундарева уйный анда. Бик яратам шул фильмны – өстәл китабы урынына ул минем. Төп героиня анда инде ун бала тапкан, унберенчене көтә. «Тормыш авырлыкларын кичерергә көч кайдан җиткезәсез?» – дип сорыйлар аннан. «Үзеңне онытып, якыннарың турында уйларга кирәк», – ди ул. Мин дә шулай... Ул чакта: «Рәисне бу авыр халәттән ничек тә чыгарырга кирәк», – дип уйладым. Яшәү мәгънәсе беткән иде бит. Шулкадәр авыр булды... Ул Гөлназны бик ярата иде. Ир-ат, «малай кирәк», ди дә, кыз тугач, «кызыыым», дип сөенәләр. «Малай туу – горурлык, ә кызны кулга алулары ук башка», – дия иде Рәис.

Гөлназны югалтканнан соң бер ел узгач, Рәис «Җаным елый» дигән җыр язды. Аны Әлфис Кыямов башкарды. Идрис Кәлимуллин да җырлады. (2002 елда, Германия өстендә Уфадан Барселонага очучы балалар утырган самолет авиаһәлакәткә очрагач, Башкортстанда өч көн буе шушы җырны җырлаттылар, диделәр.)

Сизсәң иде, күрсәң иде, балам,
Әнкәеңнең ничек түзгәнен, –
дигән юллар бар ул җырда. Ул җырны тыңларга да, сүзләрен ахыргача укырга да көчем җитмәде... Әйе, миңа, бәлки, авыррак булгандыр. Аны бит мин таптым, тугыз ай буе күтәрдем, дөньяга китердем... Тик миңа иремне дә саклап калырга кирәк иде. Аның уйларын читкә юнәлтергә.... Бик күңелсез уйлар белән йөрде Рәис ул вакытта... Йөзеннән күренеп тора иде. Яшисе килмәде... Ул күпергә ничәмә-ничә тапкыр барып кайтты икән?! Китәргә гел бер сәбәп эзләп йөри иде кебек... Шуңа да үз кайгымны онытып, күбрәк Рәискә игътибар бирергә тырыштым. Үземә ничек авыр икәнен аңа сиздермәскә теләдем. Хәер, аның да миңа белгертәсе килмәде бугай. Тик якыныңнан барысын да яшереп бетереп буламыни?! Сине сүзсез дә аңлаганга якын кешең бит инде ул!

Гөлназның кырыгына килгән Сәйдә абыстай Аппакова: «Нигә миңа бу кадәр авырлыклар бирәсең, дип, беркайчан Ходайдан сорама-

гыз. Яраткан бәндәмә күбрәк бирермен дигән», – дип сөйләде. Безнең өлешкә шундый сынау туры килгән икән, аны сабыр булып күтәрергә кирәк иде. «Авыр хәл – сүз юк... Әмма улың бар бит, Рәис, – дидем. – Аның өчен яшәргә кирәк. Иртәгә дөнья бетми...»

«Тагын бер бала алып кайтыгыз», – дип, ул вакытта киңәш бирүче бик күп булды. Шул ук сүзләрне үзем дә кабатлыйм хәзер. Мондый кайгы кичерүчеләргә генә дә түгел, бигрәк тә бер бала белән туктарга теләүчеләргә. Дөнья бит бу – нинди хәл булмас. Бу хәсрәт миңа килмәс дип берәү дә әйтә алмый. Каршы йортта яшәүче бер ир белән хатын әнә, икесе дә 50 яшькә җиткәч, бердәнбер улларын югалтты. Менә аларга нишләргә?.. Яшьләр: «Яшәү җиңел түгел бит хәзер. Табасы гына түгел, балаларны үстерәсе, укытасы, фатирлы итәсе бар», – диләр. «Дөрес итеп тәрбияләсәгез, барысын да үзләре алырлар», – дим. Иремә бер кеше булышмаган менә. Авылдан килгән, тулай торакта яшәгән. Өйләнешкәч, тулай торактан бер бүлмә сөйләште – шунда тордык. Бераздан «малосемейка»га күчтек. Аннан фатир дип йөри башлады: хезмәт хакы бик аз булса да, МЖКга урнашты (1991 елга кадәр «Яшьләр торак комплексы» дигән шундый хәрәкәт бар иде бит: фатирларны үзебез төзеп кердек. Шул отрядта эшләгәнгә үзебездә генә түгел, күрше йортларда яшәүчеләрне дә яхшы беләбез, бер-беребезне таныйбыз).

Рәиснең туган көненә бүләк ясыйсым килгән иде, тик Илүзә иртәрәк туды. Бик сөенде ул аңа. Кыз бала булыр дип өметләнергә дә курыктык. Гаиләдә ничә туган – бер-бер артлы гел ир бала гына туа Рәисләрдә. УЗИ табибы да: «Мин күрмим, кем икәнен белмим», – диде. Рәис: «Кәефе төшәр дип әйтәсең килмидер, малайдыр. Миңа кем булса да ярый», – диде. Бала тудыру йортына җәяү генә бардык. Бала тугач: «Кызыгыз бар», – диделәр дә, «Уф...» – дип җиңел сулап куйганмын. «Ни булды, әллә кыз көтмәдегезме?» – диләр. Кая ул көтмәгән?! Шул бала безне хәсрәттән күпмедер



Февраль, 1995 ел. Мәңгелек әрнүгә саласы җәйгә кадәр әле берничә ай бар...

аралады. Аның янында кайнашканда онытылып тордык. Рәис балаларны бик ярата. Безнең яшәү мәгънәсе дә балалар булды. Икебез дә гаилә өчен яшәдек. Авыр вакытларда безне шул коткарды. Бер-беребезне бик яратышып өйләнешкән идек – ул да булышкандыр. Гел бергә булырга тырыштык. Дусларга рәхмәт – безне ялгыз калдырмадылар. «Өйдә генә тормагыз, гел кайгы эчендә янмагыз әле», – дип, гел каядыр чакырдылар, концерт-театрларга алып бардылар.

Гөлназның фотоларын зурайтып бөтен өйгә тезеп чыккан идем. Кырыгына килгәч, Сәйдә абыстай: «Алып куегыз, үзегезне һаман яралап тормасын, кирәкми», – диде. Аңа карап кына күңелдән китми инде ул, әлбәттә. Егерме дүрт ел булды менә, ә йөрәктә һаман яра... Әмма фотосурәтләрне барыбер күз алдыннан җыеп куярга кирәктер.

Балаларны югалтудан курку хисе, әлбәттә, булды. Илүзә Олег Лундстрем исемендәге музыка мәктәбендә укыды, фортепиано классында. Укытучылары ел саен Самарага, джаз фестивалендә катнашырга алып бара иде аларны. Бездән сорамыйча гына Илүзә дә барырга ризалык биргән. Башта миңа әйтте. Курыктым, билгеле. Әмма җибәрәсем килмәсә дә, ризалаштым. Нидер буласы булса, үзеңә бәйләп кенә саклап кала алмыйсың. «Барысы да әйбәт булыр», – дип үземне тынычландырдым. Рәис тә барырга рөхсәт биргән кебек булды. Балалар әзерләнәләр, фортепианода дуэт уйнарга җыеналар. Китәр вакытлары якынлашты. «Билет алырга кирәк», – дим Рәискә. «Беркая да бармый. Мин баланы беркем белән дә җибәрә алмыйм», – ди. Кыз елый: «Ничек әйтим хәзер?» – ди. Укытучысы янына үзем киттем. «Шундый фаҗига кичердек. Безне дөрес аңлагыз. Юлда ни булмас?» – дим. Әмма Илүзәнең дә холкы үҗәт: алдагы елда әтисен ризалатты. Гран-при алып кайттылар! Мин аларны каядыр җибәрергә хәзер дә куркам, әмма... җибәрәм. Җибәрергә кирәк.

Айдарлар белән аннан соң да аралашып яшәдек. Аңа да авыр булды... Яңа гына фатир алганнар, күчәргә тиешләр иде. Беренче мәлләрдә кызларын карашырга туганнары бик булышты. Аннары ул кабат өйләнде. Уртак балалары булмады. Хатыны кызларны үзенеке кебек итеп яратты: алар да «әни» дип өзелеп торды. Кызганыч, иртәрәк китте...

...21 июнь – Рәис белән минем өчен елның иң хәсрәтле көне булып калды. 8 ноябрь – Гөлназның туган көне җитсә дә, иртүк икебезнең дә күзләр яшьләнә иде. Иң авыры баштагы ун ел булды. Хәзер яралар җөйләнә төште инде. Әмма сагындыра! Өзелеп-өзелеп сагындыра...



КЫТАЙ. ХАЙНАНЬ



Раушания ПОЛОСИНА-СӨЛӘЙМАНОВА

Хайнаньга килергә путевка сатып алу өчен, кытай кешесе ким дигәндә өч ел акча җыя, диләр. Озаграк, билгеле. Әмма бу көтү үзен аклый. Мондагы рәхәтлек! Май кебек җылы диңгез, пальмалар, җиләк-җимеш… Ә бит кайчандыр Хайнань – утрау-төрмә булган. Анда ябылган тоткыннарның шактый озак яшәвенә хөкүмәт җитәкчеләре соң гына игътибар итә. Баксаң, утрауның һавасы үзе үк кешегә дәва икән! Ел әйләнәсе ял итәрлек җәннәт почмагы! Хайнаньда салкыннар бөтенләй булмый. Яңгырлар сезонына гына туры килүең бар.
Бүгенге Хайнань отель һәм госпитальләрдән генә тора. Һавасы чыннан да бик чиста, Таиландтагы кебек дымлы да түгел. Ул һаваны тагын да чистарак итү өчен Кытай хөкүмәте утрауда бензин ягучы скутерларда йөрүне бөтенләй тыйган, бензин һәм дизель мае ягучы автомобильләрне дә тыярга җыена.

Алар хәтта автобус көтеп торган вакытны да бушка уздырмый: тукталышта аякларына «растяжка» ясап торган кытай әбиләрен еш күрәсең.

Тел

Хайнаньда ял итеп кайтучылар барысы да диярлек социаль челтәрләрдә: «Кытайлар русча сөйләшми», – дип аптырап, шаккатып, хәтта ризасызлык белдереп тә яза. Алар әле инглизчә дә сөйләшми! Отель исемнәренең яңгырашы да кытай һәм инглиз телләрендә берберсеннән бик нык аерыла. Шуңа күрә шәһәрне үзегез генә карап йөрергә телисез икән, барасы урынның исемен кәгазьгә кытай телендә язып алыгыз. Шактый авыр, катлаулы тел бу. Әмма ике генә сүз кытайча өйрәнсәгез дә, аларның күңелләре бик булыр. Истә калдырыгыз: исәнмесез – нихао, рәхмәт – сесе.

Отель

Кайсы отельдә туктарга икәнен хәл иткәнче, башта пляж сайлагыз.

Санья Бэй – өч пляж арасында иң озыны. Әмма транспорт, ашауэчү ягыннан безгә ул бик әйбәт вариант булып тоелмады. Калган пляжларга караганда, монда су да болганчыграк. Тик безне пляждагы черки турындагы сүзләр күбрәк куркытты бугай. Судан чыгуга отельгә кайтып китсәң һәм шунда кызынсаң, алар куркыныч түгел ди. Ә менә пляжда кызынырга калсаң, тешләп бетерә, диләр. Шуңадыр, яр буенда бер шезлонг та күрмәдек.

Без Дадунхайны сайладык. Россиядән килгән туристларның иң яраткан пляжы бу. Гомумән, утрауда, кытайлар һәм руслардан кала, башка халык бик сирәк очрый. Пляждагы кафе, массаж салоннары – һәммәсе дә руслар өчен эшли. Кесәңнең калынлыгына, мөмкинлегенә карап сайларлык кибетләр дә байтак.

Ялонг Бей пляжы ерактарак урнашкан. Аңа автобус белән 45 минут чамасы барырга кирәк. Иң чиста пляж – шушысы. Әмма анда отельләр кыйммәтрәк. Кафе һәм кибетләр дә азрак. Кая карасаң да – кытайлар. Тик алар су да коенмый, кызынмый да – бирегә фотосессия ясарга гына киләләр. Янындагы хатын-кызларның кулыннан җитәкләп, судан чыккан кыяфәт ясап фотога төшәләр – имеш, серферлар.

Күп катлы биналардан торган отельләрне мин дә, ирем дә яратмый, безгә бунгаллар булсын, террасалар... Яшеллеккә күмелгән территория... Диңгез якын икән, бассейны да кирәкми. Guest House дигән отельгә тукталдык. Диңгезгә кадәр 10–15 минут җәяү атлыйсы (отель машинасы 5 минутта да илтеп куя), аның каравы, отель яшеллек эчендә утыра. Матур! Иртәнге ашлары да бик тәмле булды. Итсез, ашсыз тора алмаучыларга пилмәнгә кадәр бирделәр.

Бер нәрсә бар: Кытайда отельләр сезне чисталыгы белән шаккаттыра алмас. Киресенчә, шәһәрдә дә бөтен җирдә тәртип булырга мөмкин, хәтта отель территориясендә дә, ә менә номерда... Пыяладагы бармак эзләре, тузанлы кровать аслары, сезгә кадәр яшәгән туристлардан калган чүп-чар – монда гадәти күренеш. Чисталык сезнең өчен бик мөһим икән – отельне җентекләбрәк эзләгез. Яки боларның барысы белән дә килешеп, аларга күз йомып, күңелегезне ялга гына көйләгез. Юк, алай булмый, дип әйтәсез икән, ялга Кытайга бармыйсыз гына инде.

Ашау-эчү

Бездәге кафеларны кытайлар ресторан дип йөртә. Безнең ашханәләр – анда кафе. Тагын әле «чифаньки» бар – болары безнең ТатМакка охшаган бугай. Соңгылары бик еш очрый.

Тамак ялгыйм дип кая гына керсәң дә, ризыкны рәсем буенча сайларга туры килә. Русчага тәрҗемә ителгән менюларга артык ышанмаска киңәш итәм. Бер менюда, мәсәлән, помидорны хөрмә дип язганнар иде.


Саньяда кытай ризыкларының тәме әчкелтем-төчкелтем, ачыдыр дип уйлаган идек. Киресенчә булып чыкты, дөресрәге, аның бернинди тәме юк. Әллә рус туристларына яраклашканнар, әллә җирле үзенчәлек булды – аңламадык. Без күбрәк сәүдә үзегенә йөрдек, суши ашадык. Рус ризыклары гына әзерли торган кафелар да бар, аларга кермәдек.

«Макдоналдс»ка гына кереп ашыйм – анда бар да мин белгән ризыклар», – дияргә ашыкмагыз. Меню бездәгедән шактый аерыла. Икенче яктан караганда – бу кызыграк та.

Хайнаньда ашау-эчү Таиландтагыга караганда ике тапкыргa кыйммәтрәк, диделәр.

Транспорт

Иң беренче эш итеп телефоныгызга maps.me приложениесен һәм Санья картасын йөкләгез. Ул интернетсыз да эшләячәк. Хайнань утравында хәрби базалар байтак, шуңа күрәдер, мөгаен, картада барлык бианалар да күрсәтелмәгән. Әмма картадагы бу «кимчелекне» Россиядән сезгә кадәр килгән туристлар



Санья Бэй пляжын кытайлар үзләре ятарак төшә. Беренчедән, аның урыны уңайлы – ул шәһәр үзәгенә якын. Кичке шәһәрне карап йөрергә теләүчеләргә бик җайлы. Күңел ачу чаралары да күбрәк, ашсының да кайсын телисең – шунысын сайлау мөмкинлеге дә бар. Иң матур шәфәкъләр дә – шушында...

Автор фотолары

Хайнань утравына кабат барып чыксак, сәламәтлекне чынлап торып ныгыгып кайтырга исәп бар.



■ Агач рәвешендәге йортлардан гыйбарәт «Beauty Crown Hotel» – дөньядагы иң зур отельләрнең берсе. Кичке утлар кабынгач, аның «ябалдашларында» төрле иероглифлар һәм сурәтләр пәйда була.



күптән «төзәткән»: йөзләгән урынны үзләре билгеләп куйган. Бу сезгә бик булышачак.

Автобуста барган өчен һәрвакыт акчалата түләргә кирәк. Акчаны ишектән керүгә махсус тартмага саласың. Вак акчаларыгызны алдан ук әзерләп куегыз – тартмадан сдача бирмичек тә алып булмый. 6 юань урынына 10 юань саласыз икән – үзегез гаепле.

Таксига утырсагыз, счетчик буенча түлисез. Әмма игътибарлы булырга кирәк: такси кайда да бер ул – «бакча артлары аша» алып бармасын. Икеләнәсез икән – таксины отельдәге гид аша чакыртырга мөмкин.

Урамдагы хәрәкәт Кытайда бездәгедән шактый аерыла. Әйтик, җәяүлеләр өчен чыгу юллары нәрсәгә ясалгандыр – аңламадык. Сез зебрага аяк басты дип кенә машиналар барыбер туктамый. Шуңа күрә юлны кытайларга ияреп чыгуың хәерлерәк. Һәм никадәр тизрәк атласаң, шулкадәр яхшырак. Хәтта тротуардан барганда да муеның бертуктамый борылып торырга тиеш. 360 градуска! Кай яктан скутер килеп чыгасын берничек белмисең. Ә алар бөтен җирдә! Өстәвенә, электрга көйләнгән: сезгә кычкыртмаса, якынайганын барыбер ишетмисез. Ә алар бертуктамый кычкырта! Миңа аларның ул сигналлары бөтен юл йөрү кагыйдәләрен алыштыра кебек тоелды. Кем беренче кычкыртса – шул хаклы, һәм шул кеше ни тели – шуны эшли.

Прокатка байк алырга да була, әмма мин киңәш итмәс идем. Моңарчы Азия илләренә инде баргагыз, йөреп караганыгыз булса гына... Ә машиналарны чит ил кешеләренә прокатка, гомумән, бирмиләр.

Акча

Кытайның үз валютасы – юань икәнен, бер юаньның якынча 10 сум торганын әйттем инде. Монда башка бертөрле валюта белән дә түләп булмый, диделәр.

Карта белән түләргә киңәш итмиләр: түләү узмаска мөмкин. Дөресрәге, сезнең картадан акча алыначак, тик аларда «түләнде» дип күрсәтелмәячәк. Кытайлар үзләре дә моңа бернинди гарантия бирми. Без акчаның бер өлешен – юань, ә бер өлешен доллар белән алып бардык. Долларны юаньга алыштыру авыр түгел. 100–200 долларны читкәрәк җыеп куярга онытмагыз: отельдә депозит өчен сорарга мөмкиннәр. Кытайда бу – адым саен очрый торган күренеш.

Дәвалану

Язмамны шушы урыннан башласам, мөгаен, дөресрәк тә булган булыр иде – күпләр бит Кытайга нәкъ менә дәвалану өчен бара. Без моңа никтер җитди итеп карамадык: баруыбыз да бер генә атнага, сәламәтлеккә дә зарланмыйбыз. Минем үземне кытай массажы гына кызыксындырды.

Гидлар: «Диагностика 80 юань тора, аны сезнең өчен туроператор түләде», – дияргә ярата. Тик бу алай түгел – Кытайда диагностика бушлай.

Клиниканы социаль челтәрләрдәге фикерләргә карап эзләдек. Миңа калса, отельдә түгел, ә сырхауханәдә урнашкан клиниканы сайласаң, дөресрәктер. Табиб инглизчә сөйләшә, ә аның ярдәмчесе

русча да белә булып чыкты. Диагностика узарга нибары... 10 минут вакыт җитте. Доктор пульсны тыңлый, күз кабакларын төшереп карый, тирене тикшерә, буыннар ничек эшләвенә игътибар итә... Һәм шунда ук барлык чирләрең, проблемаларың язылган исемлекне кулыңа да тоттыра. Монда син белгән авыртулар да, әле белмәгәннәре, тиздән беләчәкләре дә бар... Минә шулай: остеопаттан соң гастроэнтерологка, аннан чыккач, терапевтка чират торасы юк. Барысы да тиз һәм төгәл.

Диагностика узгач, дәвалау билгелиләр: гадәттә, йә инә кадыйлар, йә массаж ясыйлар яки банка салалар.

Тулы бер курс – ун процедура алу әйбәт дип санала. Әмма беренче процедурадан соң ук инде җиңеллек тоясың. Шулай дип әйтүчеләргә үзебез дә башта ышанмаган идек... Икебезгә дә инә кадарга кирәк, диделәр. Массаж дип сүз кузгатып карасам да, профессорның ярдәмчесе шунда ук кырт кисте: «Табиб инә кадарга, диде. Димәк, шул җитә». Башка җирдә булса, акча эшләп калырга тырышырлар иде... Шунда ук аларга карата ышаныч уянды.

Нәрсәләр карарга?

Күршедәге пляж һәм бухталарны карап кайтырга була. Экскурсияләргә дә кушыла аласыз, юлга үзегез генә дә чыгып китәргә мөмкин. Дадунхайда торсагыз, Болан Башын Борды паркын карарга бара аласыз – 10-12 юаньга такси сезне бик тиз илтеп җиткерәчәк. Кичкә таба барсагыз әйбәтрәк: автобусларына эләгү ихтималы бар. Тик җәяү дә шактый атларга туры киләчәк.

Йорт-агачларны карарга бару өчен дә кемгәдер иярергә кирәкми. Санья җир асты сәүдә үзәге – карап йөрер өчен шулай ук шактый кызык урын.

Дадунхайның үзәк мәйданында да булырга тырышыгыз: кичләрен анда җырлый торган фонтаннар кабына. Өлкән яшьтәге кытайлар бу мәйданга шушы музыкага биергә дип җыела.

Пенсия яшендәге кытайлар терекөмештән бер дә ким түгел: урамда кайда нинди урын бар, кичләрен алар бөтенесен фитнес мәйданчыгына әйләндерә. Берәүләр ушу белән шөгыльләнә, икенчеләре бии, җырлый яки өстәл уеннары уйный...

Отельнең үзеннән чыкмыйча да берәр кызык шөгыль табарга мөмкин. Бездә, мәсәлән, чын каллиграфия остасыннан мастер-класс алырга була иде. Бушлай! Ул – русча һәм инглизчә, ә мин кытайча берни белмәсәк тә, елмаю һәм ишарәләр ярдәмендә барыбер аңлаштык. Үз кулым белән язган кытай иероглифлары истәлеккә калды.

Тагын... Диңгез яры буйлап сузылган юллары шундый әйбәт – роликта йөрергә яратасыз икән, һич икеләнмичә үзегез белән алыгыз. Тик роликларны багажга тапшырырга туры киләчәген генә онытмагыз.

Кытайлар һәм диңгез

Көндезләрен пляжда ялгышып та бер кытайны күрмисең. Әмма кояш офыкта күмелүгә урамнар кытайлар белән тула. Диңгез дә – диңгез, болар да – диңгез! Алар соң көндез кайда була, нигә су коенмый, кызынмый, дип сорыйсыгыз киләдер.

Нигә коенмыйлармы? Җавап бик гади – йөзә белмиләр. Йөзә белгән кытайны көндез шәм яндырып эзләсәң дә күрмәссең. Алар суга керергә, гомумән, бик курка. Үзләре дә йөзми, башкаларга да рәхәтләнеп йөзәргә ирек бирми.

Берәр рус туристы «шуннан ары узмаска» дип куелган буёкларга таба йөзеп китсә, шунда ук тавыш көчәйткечен күтәреп, кытай килеп җитә һәм үз телендә усал-усал итеп нидер сөйли башлый. Ә инде син билдән тирәнрәк суга керсәң, алар тәмам хафага төшә: яр читендәге кытай өчен бу инде коточкыч тирән тоела.

Ә кызынмауларының сәбәбе шулай ук бик гади: аларның барысының да офис хезмәткәрләренә охшыйсы килә. Кытайлар карашынча, кондиционердан чыккан салкын һава астында офиста эшләү – иң югары дәрәҗә. Тәнең кояшта каралган икән, син йә вак сәүдәгәр, йә җыештыручы, йә төзүче дип саныйлар. Аз хезмәт хаклы мондый эшчеләргә охшамас өчен алар үзләренең тәнен кояштан булдыра алганча саклый: әйткәнемчә, көндезләрен урамга чыкмаска тырыша, баштан алып аяккача төренә – тәннәрен кояш кына күрмәсен... Ничә көн ял итеп, бер тапкыр да коену костюмыннан пляжда кызынып ятучы кытай хатын-кызын очратмадым.

Кытай стримерлары (инстаграмда туры эфир алып баручылар) Россиядән әле килеп кенә төшкән, кызынырга, каралырга өлгермәгән кызлар белән фотосурәткә төшәргә бик ярата.

...Туристлар арасында: «Таиландка караганда, Кытайда күбрәк ошады. Йә Пхукет, йә Хайнань дисәләр, һичшиксез, икенчесен сайлыйм», – дигән сүзләрне бу көннәрдә бик еш ишеттек. Безгә дә чагыштырып карарга кирәк булыр. Димәк, чираттагы сәфәр – Таиландка!

Белмәсәң бел



Хайнаньга баргач, җиләк-җимеш ашамыйча кайтырга һич ярамый! Баллы ананас, мангоның әллә ничә төре, кокос суы – кичке ашыбыз гел шулардан гына торды. Кайбер кибетләрдә сез сайлаган җиләк-җимешне шунда ук чистартып, турап бирергә тәкъдим итәләр. Монысы бик җайлы. Тик Кытайда бөтен нәрсәне дә килограммлап түгел, 500 граммлап кына исәплиләр. Шуңа күрә, бәяне чамалау өчен, аны икегә тапкырлап карарга һәм 0 не кушарга онытмаска кирәк (1 юань – 10 сум). Әйтик, мангоның бәясен 25 юань дип язганнар икән, аның бер килограммы 500 сум тора дигән сүз.

«КӨТЕП ТОРУЧЫҢ БУЛГАНДА РӘХӘТ...»



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

Булат НИГЪМӘТУЛЛИН,
җырчы,
Татарстанның атказанган артисты;
гаилә стажы – 17 ел;
улына – 15 яшь.

1 Иң элек хатын-кызның сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Тагын тавыш турында әйтмәдегез әле. Сөйләшүенә, үзен тотышына да игътибар итәм. Пөхтәлегенә! Хатын-кыз үз-үзен карыймы-юкмы – бу минем өчен бик мөһим. Күзендә очкын бармы-юкмы? Ул дөньядагы иң чибәр хатын-кыз булмаска да мөмкин, ләкин сөйкемле сөяге үзенә җәлеп итә дә куя! Хатыным Рәзиләнең елмайганда ике бит очында мәхәббәт чокырлары пәйда була – аны беренче тапкыр күргәч, шуларга игътибар иткән идем...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Азрак көйсезләнүендер. Андый чакта тузынуын, холкын күрсәтеп алуын... Без – ир-атлар үзебез дә чыгымчыламый тормыйбыз.

3 Ә нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Ир буларак түбәнсетүен, хөрмәт итмәвен. Хәер, мондый чиккә җитсә, парлар инде таркала. Ә хыянәт... Монысын әйтү авыр. Белмим... Хатын-кыз сине яратса, әгәр аны бар да канәгатьләндерсә, ул беркайчан хыянәт итмәячәк. Әгәр андый хәл туса, башта гаепне үзеңнән эзләргә кирәктер. Кешене гаепләргә бик җиңел бит ул...

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Икесе дә якын! Һәрбер кеше тормышта шундый хатын-кыз эзли, өйдә үзен алиһә дә, хуҗабикә дә көтүен тели. Гомумән, көтеп торучың барын белгәндә шундый рәхәт бит ул... Мине өйдә гел көтәләр! Төнлә дә, көндез дә. Йокламыйча! Бик соңга калсам: «Көтмәгез, ятыгыз!» – дип үзем әйтәм. Өстәлгә ашарга гына әзерләп куй, үзем җылытып ашармын, дим. Йокыларын өзәсем килми.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әлбәттә! Дус та, сердәш тә, таяныч та... Барлык серләреңне иң беренче аңа сөйлисең бит. Моң-зарыңны да... Аңа сөйләмичә, әти-әниеңә бушанмассың?! Дусларга да. Юк, дусларга сөйләп була анысы. Тик барыбер кайчак барысын да түгелдер. Ә хатынга барысы да сыя. Сине аңласа сыя... Тик андый аңлашу булмаса, ничек икәү янәшә яшисең ди?

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Без Йошкар-Ола университетының икътисад факультетында укыганда таныштык. Мин икенчегә күчкән елны тулай торакка беренче курслар – әллә никадәр татар кызлары килеп тулды. Танышулар китте. Без аның белән бер районнан булып чыктык. Авыллар да бер-берсеннән ерак түгел. Башка милләт кызына өйләнүемне күз алдына да китерми идем. Моны әбиләр сеңдергәндер – безне алар тәрбияләде. Тик укыганда кая әле өйләнергә? Алты ел очрашып йөрдек...

1999 елда халыкара «Татар җыры» бәйгесендә катнашып, лауреат исемен алдым. Җырларга ярата идем! Деканыбыз да татар кешесе. Кави Василович бәйгеләргә берсүзсез җибәрә: «Тик миңа матур җырлар алып кайт», – ди. Аңа кассеталар төяп кайтам. Татар эстрадасының күтәрелеп килгән вакыты бу. Үземнең шул юлдан китәсемне инде чамалыйм, әмма укуны барыбер тәмамларга кирәк. Сеңлем Дилә бер ел укыды да: «Бу минеке түгел», – дип, Казанга китте дә барды әнә. Ә мин алай булдыра алмадым: ир-атның кулында һөнәр булырга тиеш дип санадым. Әмма лауреат булу мине канатландырды: Казанга юл эзли башладым. Күңел шунда тарта! Дилә инде анда укый, Альбина Апанаева белән икәү торалар. Мин дә алар янына киләм – бергә җырлар сайлыйбыз. Ике җырым бар иде ул чакта: «Торналар» һәм «Якын дустың барын онытма». «Ядкарь» студиясе беренче альбомымны чыгаргач, бөтен җирдә шушы җырлар яңгырый башлады. Казанда минем тормыш кайный – инде гастрольләр планлаштырабыз... Рәзилә бу вакытта укуны тәмамлап, районда эшли генә башлаган иде. Бер-береңә янәшә булганда хисләр бертөрле ул, ә аерым торгач... Бәлки, ир кеше ерагая да башлыйдыр. Мин бит кеше күз алдына чыктым – үземә игътибарның

көннән-көн үскәнен тоям. Башны җуярга да озак түгел... Ул, билгеле, борчыла: «Син китәрсең дә онытырсың», – ди. Аны да аңлыйм... Минем алда ике юл бар иде. Әмма бергә булган алты елга, ул чорда бергә кичергән шатлык-сөенечләргә, авырлыкларга ничек хыянәт итәсең?! Бәлки, хәзер югалтканны аннары гомердә дә кире кайтарып ала алмам дип уйладым... «Бераз сабыр итик инде, акча җыйыйк», – дидем Рәзиләгә. Беренче гастрольләр башланды. Популярлык, әйткәнемчә, зур – үтүкне тыксаң да «Торналар» җыры яңгырый. Беренче гонорарлар кулга керде... Кыз сорарга да бардык, кыз туе булды. Әти-әниләре каршы килмәде: Рәзиләнең үзенең теләге зур икәнен беләләр иде. Яратмаса чыкмас иде... Җырчы кеше белән яшәү хатын-кызга җиңел түгел. Мин аларга һәйкәл куяр идем... Без бит гел кеше күзендә. Көнләшү дә бар: хатын-кыз да таш йөрәкле түгел. Телефонга «смс»лар килеп төшкән чаклар да булды: әдәпне онытып җибәрүче хатын-кызлар да бар... Боларның барысын да уздык. Хәзер инде көлеп кенә искә алабыз. Шуларны кичкәнгә бер-береңне күбрәк хөрмәт итә башлыйсың да.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Бар андый нәрсә. Моны әтинең дә әйткәне булды. «Рәзилә әниеңә охшаган ул», – дип.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Кыю тотарга! Күбрәк мал тапкан хатын-кызлар, гадәттә, ирләрнең юашрагын сайлый. Күп сүз әйтмәсен, артыгын көрәшмәсен, вак-төяк белән башымны катыра торган булмасын... Ике якны да бу канәгатьләндерә икән, тик яшәсеннәр.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Әгәр хатын-кыз шулай хәл иткән икән, ул аны инде барыбер белдерәчәк. Калганы исә ир кешедән тора. Йә кабул итә, йә юк... «Юк» дип, сүзен өздереп, аңлаешлы итеп әйтә икән, башка сорау калмый.

10 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Хатын-кызга өйдә бөтен нәрсә гел үз урынында булырга тиеш инде аңа. Ә без таратырга яратабыз. Дөрес, носкилар фатир буйлап таралмаган – анысына өйрәндек. Улым да, үзем дә. Бер нәрсә кирәк булып, эзли башласаң: «Юк, ул анда ятмый бит, аның урыны монда», – ди ул. Әйбер бер урында гына ятса, үзебезгә дә җиңел анысы. Тик мин ул урынның кайда икәнен гел онытам. Ә хатын-кыз онытмый, бөтен нәрсәне хәтерли! Кайчак берәр кая җыенып чыгып китәргә кирәк, нәрсәнедер эзли башлыйсың, тапмыйсың. Аптырагач, тагын аңа шалтыратасың. «Шушы шкафның шушы киштәсендә, шушы кырыендa», – дип җавап бирә ул. Без әйбер эзли белмибез шул. Кайчак шунда булырга тиешлеген дә беләсең, шкафны инде тәмам бушатып бетерәсең – юк кына! Тагын хатынның номерын җыймый чараң юк. «Ә ул юылган, әле бауда эленеп тора», – ди ул. Мондый нечкәлекләрне без гомердә белеп бетерә алмыйбыз.

11 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез?

– Хаклы булуымны исбатларга тырышам: мәсьәләне логик яктан аңлатып карыйм. Әмма ничек кенә булса да, бөтен нәрсәне аның белән сөйләшеп эшләргә кирәгенә күптән инандым. Хатын-кыз авызыннан син уйламаган фикерләр чыга кайчак. Дөресрәге, син уйлап бетерә алмаган. Ишеткәч, карале, чыннан да шулай бит, дип аптырап китәсең һәм бөтенләй бүтәнчә чишелеш табасың.

Уртак фикергә килмәсәң, бу сөйләшүне калдырып торырга кирәк. Чишелми икән, азрак көтсен. Мәсьәләгә кире борылып кайтканда, беребезнең фикере үзгәргән булуы да бар. Аннан һәрнәрсәнең үз чишелеше табылмый калмый, син вакытны ашыктырганнан исә берни үзгәрми. Димәк, иртәрәк – әле сәгате сукмаган.

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым дип, диванда кырын ятып тора.

– Сез бераз арттырасыз, хатын-кыз, арыдым дип, ашарга пешермичә, диванда ятып тормый инде ул... Ниндидер сәбәп белән әзерләргә җае булмаса, ул миңа алдан шалтырата: «Бүген ашарга пешерә алмадым, әйдә, берәр кая барып кайтабыз», – ди. Андый чакта өйгә дә кереп тормыйм, «чык», дип кенә чакырам.

Буш вакытым бар икән, хатын эштә чакта үзем дә нидер әзерли алам. Суыткычта шулпа бар икән – ә ул гел бар – аш пешерәм. Итле ризык та әзерләргә булдырам. Мин бит студент булган кеше. 8 литрлы кәстрүлдә аш пешереп яки зур табада ит белән бәрәңге кыздырып, кызларны чакырганым булды. Бездә шулай иде: бүген – беребездә, иртәгә – икенчебездә.

13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.

– Кайвакыт, киресенчә, аңа мине көтәргә туры килә. Миңа бит барысын да әзерләргә, бернәрсәне дә онытмаска кирәк: кунакка дип чакырсалар да, күп вакыт җырларга да туры килә. Шуңа күрә сәхнә костюмын алмыйча булмый.

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Ничек ошамасын, мин бит аны алдан әйтеп куям! Читләтеп булса да. Ярты ел алдан шул хакта сүз чыгарасың: менә бу әйберем булса, ничек шәп булыр иде дип... Без моңа ияләштек инде. Үзем дә бүләк бирергә яратам. Чәчәкләр! Бер сәбәпсез! Тамашачы биргән чәчкә бәйләмнәрен мин аңа сирәк алып кайтам. Барысын да өләшәм: төркемдәге артистларга, концерт карарга килгән туганнарга... Кешегә бүләк бирү – аның сөенечен күрү бүләк алганга караганда рәхәтрәк икәнен торган саен ныграк аңлыйсың... Студент чакта, авылларда концертлар куеп кайткач, Рәзиләгә алтын муенса алган идем. Тар гына, кыска гына. Ә ул шул вакыттагы шатлыгын әле дә искә ала!



Төнлә «балык каптыру»

Һәркайсыбыз балаларыбызның тизрәк тәпи китүен, чүлмәккә дә үзе белеп утыруын тели. Ләкин кайбер балалар шактыйга кадәр төнлә астын юешли торган була. Халык телендә, шаяртып, «балык каптыру» дип йөртелгән бу проблеманың нилектән килеп чыгуын һәм аннан котылу юлларын безгә югары категорияле табиб-уролог, Казан дәүләт медицина университетының балалар хирургиясе кафедрасы профессоры, медицина фәннәре докторы, Татарстанның атказанган табибы, республикабызның дәүләт премиясе лауреаты Валерий МОРОЗОВ сөйләр.

Төнге яки көндезге йокы вакытында баланың бәвелен тота алмавын энурез дип әйтәләр. Әлеге патология 5 яшьтән узган балаларның 15 процентында күзәтелә. «Пес» итәсе килгәнне контрольдә тоту балаларда 3 яшьтән 5 яшькәчә формалаша. 5 яше тулганчы баланың йоклаган чакта астын юешләве – гадәти хәл. Бу вакытта әле аның баш һәм арка миендәге бәвел чыгаруны контрольдә тота торган үзәкләре тиешенчә өлгереп җитмәгән була.

Балаларда энурез башлануга этәргеч бирүче сәбәпләр күптөрле. Аның берсе – аденоидлар аркасында борын белән сулыш алуы кыенлашу, бала организмының даими гипоксия (кислородка кытлык) кичерүе. Нәселдәнлек тә роль уйный – баш миенең гипофизында төнлә бәвел бүленеп чыгуны тоткарлаучы антидиуретик гормон җитәрлек күләмдә ясалмый. Арка миенең терминаль бүлекләре (әвернә сөяге өлеше) өлгереп җитмәү, бала карында чакта яки туган вакытта баш яки арка миенә зыян килү – шулай ук бәвел тотмауга китерүче сәбәпләрнең берсе булырга мөмкин. Бу вакытта сидек куыгының нейроген дисфункциясе күзәтелә, ягъни бәвелне туплый һәм бүлеп чыгару функциясе бозыла, бәвел куыгын ябык килеш тота торган аппарат тиешенчә эшләми.

Баланың бик еш (һәр сәгать саен) яки, киресенчә, бик сирәк йомышлавы әлеге дисфункциянең булуын күрсәтә.

Кайчак баланың йоклаганда астын юешләвенең сәбәбе стресс кичерү дә булырга мөмкин. Әйтик, балалар бакчасына бирү, энесе яки сеңлесе туу, гаиләдәге низаглар, баланың куркуы яки борчылуы... Әгәр дә тормышындагы шундый җитди үзгәрешләрдән соң балагызның астын юешли торган гадәте барлыкка килүен сизсәгез, бу очракта психологка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Әти-әниләргә кайчан, нинди очракларда борчылырлык сәбәп бар соң? 5 яшен тутырган бала төнлә яки көндез йоклаган вакытта атнага бер тапкырдан ешрак астын юешләсә, бу инде балалар урологына яки невропатологка күренү өчен җитди сәбәп. Табиб уронефрологик һәм, кирәк дип тапса, неврологик тикшеренүләр уздырачак, энурезның сәбәпләрен ачыклап, тиешле дәва билгеләячәк.

Әлеге проблеманы хәл итүдә медикаментоз чаралар да, физиодәва да кулланыла. Диагноз дөрес куелса, амбулатор шартларда яки көндезге стационарда ике-өч дәвалау курсы узып, энурездан тулысынча арынырга мөмкин. Курс аралары – өч ай тирәсе.

Халыкта бу чирне дәвалауның төрле ысуллары бар: баланы мунчада чабындыру, төнлә уятып, ешрак чүлмәккә утырту, тозлы балык ашату, кичкә таба су эчүне чикләү – алар күптөрле, ләкин нәтиҗәсе аз. Шуңа да традицион медицина ысулларына өстенлек бирелә.

Казан дәүләт медицина университетының балалар хирургиясе кафедрасында медицинаның әлеге өлкәсе буенча үзебез уздырган фәнни тикшеренүләр оптималь диагностика протоколы булдыру һәм 95–100 процент очракта савыгуга ирешү мөмкинлеге бирде.

Балалардагы энурез проблемасы буенча белгечләр Казандагы медицина үзәкләрендә кабул итә.

Табиб киңәше

Бала тыныч йокласын дисәгез:
- көндәлек режимны төгәл үтәргә;
- баланы зур тетрәнүләрдән сакларга;
- туңуны булдырмаска;
- борын һәм авыз куышлыгындагы чирләрне вакытында дәваларга;
- туганда төрле травма алган һәм сәламәтлегендә неврологик тайпылышлар булган балаларны мөмкин кадәр иртәрәк дәвалый башларга кирәк.



Аякта сөяк чыкса...

Аяктагы баш бармак бер якка янтаеп, кырыйдан сөяге чыгу – күпләребезгә таныш нәрсә. Аякны ямьсезләп, матур туфлиләр кияргә комачаулавы бер хәл, ул әле бик авырта да. Бу сөяктән ничек котылырга соң? Ә иң яхшысы – аны ничек итеп булдырмый калырга? Медицина фәннәре кандидаты, Республика клиник хастаханәсенең 1 нче ортопедия бүлеге мөдире Рамил САЛИХОВ шушы сорауларга җавап бирер.

Әлеге проблеманың медицина телендәге атамасы – Халюс Вальгус. Бу, мөгаен, табан сөяге белән бәйле чирләрнең иң күп таралганыдыр. Җир йөзендәге 18 яшьтән алып 65 яшькә кадәр булган халыкның 25 процентында шушы проблема күзәтелә. Ир-егетләргә караганда, хатын-кызларда өч-дүрт тапкыр ешрак очрый.

Халюс Вальгус аякның баш бармагы эчкә таба кәкрәюдән башлана. Ул аяк киеме сайлаганда комачаулый, авырта. Тора-бара бармак тагын да ныграк кәкрәя, авырту да көчәя, яннан бармак сөяге бултаеп чыга. Ул бер яктан – табан сөягенең башы, икенче яктан бурсадан гыйбарәт. Бурса ялкынсынганлыктан, көчле авырту тоела. Чарасын күрмәсәң, бармакның кәкрәюе тагын да дәвам итеп, калган бармакларның да зарарлануына китерә.

Сөяк табан мускулларының балансы дөрес булмау аркасында чыга. Бармак кәкрәюе ул икенчел генә билге. Бармакның торышы үзеннән-үзе бозылмый, аның төп сәбәпчесе – аркылы яссытабанлылык. Иң элек табан сөякләре җәелә. Сеңерләр бармакны читкә тарта башлый. Кайчак бармак кәкрәеп кенә калмый, борыла да.

Биек үкчәле тар аяк киемнәре, көнозын аяк өсте торып эшләү, авыр күтәрү, гәүдәнең артык авырлыгы, күпләр уйлаганча, сөяк чыгуның төп сәбәпчеләре түгел. Әмма аркылы яссытабанлылык күзәтелгәндә алар сөяк чыгуны тизләтә.

Халюс Вальгус берничә стадия белән билгеләнә. Төгәл диагнозны рентген ярдәмендә травматолог-ортопед яки хирург куя. Нинди стадиядә булуына һәм пациентның яшенә карап, дәвасы да төрлечә.

Яшүсмерләр өчен күп очракта консерватив дәва чарасы билгеләнә. Үсүче яшь организмга аяк бармагын дөрес халәттә тотып тору өчен махсус ортопедик җайланмаларның файдасы зур. Шулар ярдәмендә сөякләр дөрес урнашып, проблемадан котылып калырга мөмкин әле.

Әлеге җайланмалар өлкәнрәк пациентларга да билгеләнә. Ләкин бу очракта алар дәва чарасы буларак түгел, ә хәлне сизелерлек җиңеләйтү һәм сөякнең алга таба кәкрәюен булдырмау өчен кулланыла.

Бу чир бер көндә генә барлыкка килми. Ул аяк табанын еллар буена акрынлап кына зарарлый. Безгә килгәндә кешенең табан сөякләре җәелгән, сеңерләре тартылган, мускуллары үзгәргән була. Аларны инде кире үз халәтенә кайтару мөмкин түгел.

Бик авыр очракларда операция билгеләнә. Ләкин ул да тулысынча булышмаска мөмкин.

Минем киңәшем: әгәр дә кешедә тумыштан ук аркылы яссытабанлылык бар икән, табан сөягенең җәелүен, баш бармакның кәкрәюен булдырмас өчен, аяк киеме эченә ортопедик олтан салырга, бармакларга бандаж кулланырга, аяк бармаклары арасына махсус кыстыргычлар куярга кирәк. Әйткәнемчә, болар – ярдәмче чаралар. Ләкин алар чирне йөгәнләргә булыша.

Табиб киңәше

Аяк бармагының сөяге чыгып интектерсә:
- табан мускуллары өчен махсус гимнастика ясарга, табан асты белән теннис шары тәгәрәтергә, алмаш-тилмәш аяк очларына һәм үкчәләргә басып йөрергә;
- сызлавы көчле булса, ялкынсынуны баса торган махсус кремнар, майлар сөртергә;
- табанга җиңелчә массаж ясарга;
- аякларны диңгез тозы салынган җылы ваннага тыгып утырырга;
- ятар алдыннан аяклар өчен контраст душ кулланырга;
- тар һәм биек үкчәле туфлиләр кимәскә.









Ефәктән дә нәфисрәк...

Иран келәме! Күзләрегезне йомыгыз да әчтән генә шул сүзләрне кабатлагыз әле. Бу матурлыкны гомердә күргәнегез булмаса да, күңел халәтегез белән сез аны күз алдына китерә алырсыз. Чем-кара күзле гүзәл хатын-кыз сурәте, аның кыйммәтле ташларының ялтырап китүе, тыенкы көлү, фонтаннарда су челтерәгән тавышлар – Шәрыкның хуш ис сирпеп торган томанлы образы әнә шулай гәүдәләнә. Әйтеп бетергесез рәхәтлек, хозурлык, байлык халәте. Америка рәссамы Сингер Сарджент берчак: «Италия Ренессансының бар сынлы сәнгате иран келәменең бер кисәгенә дә тормый!» – дип әйткәндә, нәкъ менә шуны күз уңында тоткандыр, мөгаен. Ул келәмнәр турында поэмалар язылган, аларны хуш исле гөл-чәчәкләргә күмелеп утырган, сайрар кошлары, киек җәнлекләре белән таң калдырган әкияти бакчага тиңләгәннәр. Келәмчеләрнең әйбәт энергиясе башкаларга да күчеп, күзләрне иркәләгән. Кулдан келәмнәр туку, кабатланмас гамәли һөнәр буларак, ЮНЕСКОның нәфис гамәли сәнгать мирасы исемлегенә кертелгән.

Урта Азиядә келәмнәр гомер-гомергә дәрәҗәле санала. Алар кыйммәт бәядә йөри, нәселдән-нәселгә тапшырыла. Һәм бүгенге көндә дә кыйммәтен югалтмый, киресенчә, хакы арта гына. Чын сәнгать әсәренә тиңлиләр аны. Урта гасырларда ук келәмнәрне идәннәргә җәйгәннәр, диварларга элгәннәр, намазлыклар итеп файдаланганнар.

Сәмәрканд келәм фабрикасында соклануымны һәм шатлыгымны тыя алмадым. Кристаллдай чиста биләмәсе, биек тут агачлары, чәчәкле бакчасы белән каршы алды ул мине. Кошлар сайрый, арыктан челтерәп сулар ага. Әйтерсең, вакыт машинасында йөз елларга артка күчтем. Остаханәдә кызлар берничә йөз еллар элек кебек үк келәмнәр тукып утыра, бүлмәләре генә иркенрәк. Һәр кызның үз кулы, шуңа күрә бер оста башлаган эшне икенчесе төгәлли алмый. Искиткеч бизәкләрнең бергә үрелүен, буяулар һәм экстерьерны элеккеге СССРның башка республика осталарыныкы белән бутау мөмкин түгел. Сүз дә юк, төрекмән келәмнәре аерым урын алып тора. Ләкин Сәмәркандның ефәк келәмнәрен иран келәмнәре белән янәшә куярлык. Иран һәм Сәмәрканд келәм туку мәктәпләре бертөрле. Сәмәрканд осталары иң матур келәм дизайнын булдыруга ирешкән. Яраткан мотивлары: «буте» – «кыяр». Кош сурәтләре, чәчәкләр дә киң таралган.

Келәмнең тыгызлыгы квадрат сантиметрдагы төеннәр саныннан чыгып исәпләнә – затлы келәм критерие бу. Иран шаһларының сарай осталары, шәрык манараларын хәтерләткән катлаулы һәм үтә нәфис рәсемнәр төшереп, бик зур келәмнәр тукыганнар.

Киңәш итәбез

- Келәмне тузан суырткыч белән даими чистартып торыгыз. Этикеткага күз салырга онытмагыз – келәмне ничек чистартырга икәне язылган анда.
- Ефәк, йон һәм мамык катнашкан келәмнәр дә була. Аларны да бик сак чистартырга кирәк. Үз белдегегез белән тотынмагыз.
- Келәмне сак кына кагып, тискәре ягыннан чистарталар. Аның өчен келәмне коймага түгел, бауга эләргә кирәк. Бөтен тузаны чыгып беткәнче кагып торыгыз.
- Уксуста чылатылган (1 литр суга 1 аш кашыгы) тукыма аша бәргәләсәң, келәмнең бизәкләре ачыграк күренә.
- Вакытлар узу белән каралса, келәмне кайнар бодай көрпәсе төнәтмәсе белән юыгыз.
- Май тапларын нашатырьлы кайнар су ярдәмендә бетереп була.
- Даими рәвештә ныклап чистарту уздырырга кирәк. Келәмне химчисткага илтегез.
- Биш елга бер чистартсаң була дип ялгыша күрмәгез. Идәнгә җәелгән андый келәмнәр сулып калгандай булалар. Шуңа күрә аларны ел саен юып торырга кирәк.

Кул белән тукылган келәмнәрдә табигый буяулар гына кулланыла. Ефәкне синтетик буяулар белән бозарга ярамый. Юкса нәфис ефәк катып китә. Индиго, куркума, марена, Әстерхан чикләвеге кабыгы, гранат кабыгы кабатланмас төсмерләр белән баеталар. Индиго иң кыйммәт буяу исәпләнә, ул сирәк зәңгәр төс бирә. Куе зәңгәр төсне орнамент өчен фон буларак кулланалар, шулай ук яшел, кызыл, күк төсендәге зәңгәр, фирүзә, нәфис алсу, алтынсу, кура җиләге төсләрен кулланалар. Төрле буяуларны катнаштырып, ачык яшелдән сизелерсизелмәс сары төсләрне китереп чыгаралар, хәзер нәфис пастель тоннары да киң таралган. Йон келәмнәр аллергеннар дип язсалар да, табигый буяулар кулланып эшләнгән келәмнәр аллергия китереп чыгармый.

Соңгы егерме ел эчендә Россия базарын арзанлы синтетик паласлар һәм келәмнәр тутырды. Бу исә төрле авыруларга китерде. «Кибет паласы» начар дип әйтмим, бик яхшы да булырга мөмкин ул. Безнең техноген тормышта кулдан эшләнгән әйберләр, югары сыйфатлы булып, сезнең зәвыгыгызны да күрсәтер, әлбәттә. Ә табигый келәм тарафдарлары турында нәрсә әйтеп була? Алар иң яхшысын ала беләләр. Кыйммәтле һәм дәрәҗәлеләрне дип әйтмим. Күңел биреп эшләнгән «чын келәмнәр»не һәм... әбиләр суккан паласларны. Ничек кенә яхшы һәм сыйфатлы булмасын, алар инде беркайчан да «кибет паласлары»н сатып алмас.

Келәмнәрне юу һәм чистарту буенча хезмәт күрсәтү киң таралган хәзер. Кайчак аларны сыйфатсыз итеп башкаралар. Мондый хезмәтне тәкъдим итүче фирмалар бәяне төшерергә тырышып, келәмнәрне түбән сыйфатлы порошоклар белән юа.

Келәм никадәр борынгырак булса, шулкадәр кыйммәтрәк. Шуңа күрә әбиегезнең иске келәмен чыгарып ташларга ашыкмагыз. Профессионаллардан чистарттырып алыгыз. Натураль келәмнәр искиткеч кыйммәт тора.

Рәмзия КАШАПОВА

Служба чистоты «ПИОНЕР»
Ответственная чистка ковров без аллергенов
ВЫВЕДЕМ ЛЮБЫЕ ЗАПАХИ И ПЯТНА, ВЫЧЕШЕМ ШЕРСТЬ
ЦЕНА ДЛЯ ЧИТАТЕЛЕЙ ЖУРНАЛА – ОТ 130 РУБЛЕЙ ЗА 1 КВ. МЕТР
*Промокод: Сююмбикэ
Звоните: 8 (843) 214-16-16 www.чисткаковров.рф
РЕКЛАМА

PRESSA

Дограма



Төрекмәннәр – тугандаш төрки күршеләребез. Уртаклыгыбыз күп алар белән: динебез бер, бәйрәмнәребез, телләребез охшаш... VIII гасырга караган ядкарьләр төрекмәннәрнең бик борынгы халык булуын раслый. Күпчелек төркиләргә хас булганча, аларда әле узган гасыр башына кадәр кабиләләргә һәм ыругларга бүленеш сакланган. Борынгы тамырлары Огуз ханга барып тоташа.

Иң олы бәйрәмнәре – Корбан һәм Ураза гаете. Корбан гаете тәгәл өч көн дәвам итә. Бу көннәрдә табыннар мул, ишекләр ачык булырга тиеш. Хәтта хуҗалар үзләре өйдә булмаса да, ишек ачык кала, юлы төшкән теләсә кем кереп сыйланып чыгарга мөмкин. Корбан гаетендә таганда атыну гадәте дә бар төрекмәннәрдә. Шул рәвешле, ел буена җыйган гөнаһлар коелып төшеп кала, имеш. Туган җанлылык һәм кунакчыллык төрекмәннәрнең төп сыйфатларыдыр, мөгаен. Барлык төрки халыкларга хас булганча, төрекмән өенә аяк баскан кунак – Аллаһ бүләге. Кунак табынына сый-нигъмәтнең иң яхшысы, иң тәмлесе куела. Төрекмән милли аш-суының күп өлеше итле һәм сөтле ризыклардан гыйбарәт. Башка төрки кухнялардан аермалы буларак, балык иң затлы сыйларның берсе санала. Балыктан әзерләнгән пылау туй табыннарына куела.

«Хуҗабикә галәме»нең бүгенге кунагы Гунча НАРБАЕВА әзерләп күрсәткән дограма исә төрекмән халкының көндәлек ризыкларыннан. Дограманы авыз итеп караган кеше аннан беркайчан да баш тартмас. Тәмле, туклыклы, үзе гади, үзе кызыклы... Бергәләп әзерлибезме?!



Кирәк

- 1-1,5 кг сөякле ит;
- 2-3 баш суган;
- 1-2 кашык томат пастасы яки 1-2 помидор;
- он;
- кайнаган су;
- тәменчә тоз, борыч;
- аш тәмләткеч үләннәр.



Фото: Анна Арахамия

Эш барышы

■ Бу ашны әзерләү өчен иң элек петир – кетердәп торган юка икмәк пешерергә кирәк.

■ Петирның рецепты бик гади: суга бер чеметем тоз һәм кулга ябышмаслык күләмдә он гына кирәк. Камырны баскач, юка итеп җәябез. Өстенә сыек май сибеп, җәемне тәгәрәтеп төрәбез. Төргәкнең ике башын эчкә таба бөгәрләп китерәбез дә берсе өстенә икенчесен куеп, кул белән басабыз. Ул бераз «ял итәргә» – май камырга сеңәргә тиеш.

■ Камырны берничә кисәккә бүлеп, таба зурлыгында гына юка итеп җәябез. Калынлыгы – 0,5 см тирәсе. Өстен чәнечке очы белән тишкәлибез. Аны салганчы, таба төбенә он сибәбез, табаны майларга кирәкми. Петир кызу мичтә алланганчы пешә.

■ Дограма өчен төрекмәннәр куй ите куллана. Сыер итеннән дә пешерергә мөмкин. Шулпага тәме чыксын өчен, сөякле ит яхшырак. Ләкин аның турарлык ите дә җитәрлек булсын.

■ Итне салкын суга салып, кайнатып чыгарабыз. Күбеген җыеп алгач, талгын утта пешерәбез. Берәр сәгатьтән тоз, суган, 1-2 кашык (шулпаның күләменә карыйбыз) томат пастасы өстибез. Паста урынына помидор турап салсаң да ярый. Ит пешкәч, шулпадан алып суытабыз.

■ Суынган ит белән петирны кул белән генә ваклыйбыз. Төрекмәннәр аны зур гаилә белән, барысы бергә түгәрәкләнеп утырып башкара. Итне пычак белән турасаң да була.

■ Бер-ике баш суганны бик вак итеп турыйбыз. Шулпа суынып китсә, аны кайнарлатып алабыз.

■ Зур касәгә вакланган итне, петирны, туралган суганны салып, бергә катнаштырабыз. Бер-ике аш чүмече кайнар шулпа өстибез. Кабат яхшылап болгатабыз.

■ Дограманы кеше саен касәләргә яки тирән тәлинкәләргә бүлеп, шулпа салып чыгабыз. Куерак яраткан кешегә – шулпасын азрак, сыеграк яратканга шулпасын күбрәк салабыз. Иң ахырдан аш тәмләткеч үләннәр сибәбез.

Белмәсәң бел



Төрекмәннәрдә икмәкне кадерсезләү бик зур гөнаһ санала. Һәр кызның бирнә сандыгында сачак – икмәкне төреп саклау өчен махсус ашъяулык була. Аны берничә катлы тукымадан яки дөя йонынннан басылган киездән ясыйлар. Сачак өстенә фәкать ризык кына куярга ярый һәм ул башка керләрдән аерым юыларга тиеш.

Мастер-классны оештыруда ярдәм иткәннәргә өчен
Татарстан халыкларының Дуслык йортына рәхмәт белдерәбез.

Аны кем генә яратмый икән, дисезме? Килешәм, андый кеше юктыр ул. Әмма кибетләрдә сатыла торганы артык баллы, аңа ясалма буягычлар кушылган була. Классик лимонад исә лимон, су һәм шикәр комы гына кушып ясала. Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА исә лимонадны бөтенләй дә шикәр кушмый гына ясарга тәкъдим итә. Андый эчемлекләр тәмле дә, организм өчен файдалы да.



Лимонад яратасызмы?





Фото: www.pixabay.com

«Цитруслы иртә»

Кувшинга бер тармак розмарин салып, кашык белән изәбез. Шуңа 1 литр су өстәп (газлы яки газсыз минераль су), 3-4 аш кашыгы бал кушабыз (күбрәк тә, азрак та кушарга була, кем ничек ярата бит), яхшылап болгатабыз. Лимонадка ярты лимон, бер әфлисун һәм бер кыярны телемләп турап салабыз, теләгән кеше боз шакмаклары өсти ала.

«Чәй яратучыларга»

Бик тәмле лимонадны чәйдән дә ясарга була. Моның өчен бөтнек кушып пешерелгән 500 мл яшел чәйне суытып, 1 чәй кашыгы вак угычтан уылган имбир, телемләп туралган ярты лимон, 3-4 аш кашыгы бал өстибез һәм бөтнек яфраклары салабыз.

«Шифа касәсе»

Кувшинга бер тармак шалфей үләнен салып бераз изгәлибез, 1 литр газлы яки газсыз минераль су, 3-4 аш кашыгы бал кушып, яхшылап болгатабыз.

Тәгәрмәчләп туралган 2 груша, 2 телем лимон салып, 1 әфлисуннан сыгылган сок өстибез.

«Зифалык»

Бу лимонад матдәләр алмашын яхшырта.

Берәр тармак бөтнекне изгәләп, ярты литр су, 3 чәй кашыгы вак угычтан уылган имбир, 2 телем лимон салабыз һәм яхшылап болгатабыз.

Лимонадны шунда ук эчәргә ашыкмагыз. Ярты сәгатьтән ул тагын да тәмлерәк булачак.

Кучкар. Эш-мәшәкатькә бай катлаулы ай. Корган планнар шома гына бармас, үзгәрешләр кертергә туры килер. Яңалыклар һәр өлкәдә булачак, хәтта шәхси тормышта да, әзер торыгыз.

Үгезбозау. Ай ыгы-зыгылар белән башланып китәр. Күңелегез нииндидер авантюрага тарта, шуның аркасында коллегалар белән аңлашылмаучанлык та килеп чыгуы бар. Киеренке булса да, бу ай иҗади эш өчен кулай чор.

Игезәкләр. Сынау чоры. Эшегез, идеяләрегез, тәкъдимнәрегез сынала. Эшегез барып чыкмаса, күңелегезне төшермәгез. Аз гына сабырлык күрсәтегез, алга таба бар да җайланачак, айның ахыргы ун көне бик уңышлы булыр.

Кысла. Гади ай түгел. Вакыйгалар бер-бер артлы үзгәреп кенә торыр. Ай башында энергия агымы уңайрак, мөһим эшләрне шул чорга ниятләгез. Игътибар таркалган вакыт, сак булыгыз.

Арыслан. Тормышыгызның катлаулырак чоры. Алдыгызда зур мөмкинлекләр ачылырга тора, сайлау кыен булмагае. Тышкы каршылык кына түгел, эчке каршылык та көчле. Якыннарыгызның киңәшен тотыгыз.

Сөмбелә. Айның энергиясе уңай гына булмас. Ул – вәсвәсәгә һәм низагларга этәрә торган. Үз-үзегезгә булган ышанычыгыз какшап китәр. Дөньяның матурлыгы, якыннарыгыз турында күбрәк уйланыгыз.

Бизмән. Сәламәтлекне ныгытуны иң беренче планга куегыз. Бу айда бар эчке энергиягезне сарыф итәргә туры килер, алда зур эшләр көтә. Аралашуларны чикләргә тырышыгыз, ул да көчне күп ала.

Чаян. Тормыш потенциалыгыз бик югары чор. Әмма аны дөрес итеп файдалана белергә кирәк. Алдыгызда яңа мөмкинлекләр ачылырга тора, авыз ачып калмаска тырышыгыз. Булмас дигән идеяләр дә уңыш китерергә мөмкин.

Укчы. Энергия тотрыклы түгел: ул әле ялкаулыкка этәрә, әле җандагы гаярьлекне уята. Сәләтегезне күрсәтү өчен шәп кенә форсат килеп чыгар. Алай да амбицияләрегезне бераз йөгәнләгез.

Кәҗәмөгез. Сөбханалла, сездәге көч, активлык! Нинди эшкә керешсәгез дә, уңышлы булыр. Әмма ашыкмагыз, бу айда ялгышу ихтималы зур, гәрчә эчке сиземләвегез искиткеч көчле булса да.

Сукояр. Катлаулы чорларның берсе. Организмның көчләре бетеп киткән вакыт, күп нәрсәгә игътибарыгыз да җитеп бетмәс. Шуңа бәйле зур булмаган проблемалар килеп чыгарга мөмкин, сак булыгыз.

Балык. Мөнәсәбәтләрнең ныклыгын сынарга туры килмәгәе. Хәер, барысы да үз кулыгызда, үзегезгә партнерыгыз күзлегеннән чыгып карый белсәгез, бар да җайланыр. Айның энергиясе тискәре, низагларга кермәскә тырышыгыз.

зирәк кешедән зирәк сүз

ИҢ ТӘМЛЕ ИПИ

Бер шәһәрдә бик бай кеше яшәгән. Ни теләсә, шуны ашый алырлык байлыгы булган аның, ләкин авызының тәме генә юк икән. Иң тәмле ризыклар да аңа төче тоелган. «Миңа ошарлык тәгам әзерләүчегә йөз мең алтын түлим», – дигән ул. Кемнәр генә килеп, ниләр генә пешереп карамаганнар, байга аларның берсе дә ошамаган. Иң ахырдан бер ярлы кеше килгән. Аның байга тәкъдим итәрлек бер ризыгы да булмаган. «Мин сиңа киңәш алып килдем. Иң беренче капкан кисәк – иң тәмлесе була», – дигән ул. «Акылсыз, – дип ачуланган аны бай. – Иң беренче кисәге дә, иң ахыргысы да бер тәмдә иде мин ашаган ризыкларның». Бу мескенне кызганып, байның хезмәтчесе аңа бер кыерчык ипи биреп җибәргән.

Икенче көнне тылсымчы киемнәренә киенеп, теге кеше тагын бай янына килгән. «Мин сиңа ничек ярдәм итәсен беләм. Урмандагы бер нарат төбендә тылсымлы ипи кыерчыгы ята. Аны ашасаң, ризыкның тәмен кабаттан тоя башларсың, – дигән ул. – Тик бер генә шарты бар, син аны үзең эзләп табарга тиеш, югыйсә тылсымның көче бетә».

Бай бик шатланып, «тылсымчы» карт артыннан урманга киткән. Көне буе йөргәннәр, тик теге кыерчык кына табылмаган. Бай инде тәмам йончыган, ачыккан. «Менә шушы агач төбен генә карыйбыз да...» – дип, биек нарат төбенә килгәннәр. Бай ни күрсен, агач төбендә кечкенә генә бер кыерчык ипи ята икән. Комсызланып, капкан да йоткан ул ипине. «Йә, ничек соң, беренче капкан кисәк иң тәмлесеме?» – дип сораган аннан «тылсымчы». «Гомеремдә дә шуннан да тәмлерәк ризык капканым булмады», – дигән бай. «Ә бит бу ипи синең үз йортыңда пешкән икмәк иде. Димәк, кичә мин әйткән сүз дөрес булып чыга инде?» – дип, аңа дөресен сөйләп биргән карт. Байга килешергә генә калган.

***

Ипиең булып та, тешең булмаса, монысы хәсрәт түгел, тешең булып та ашарга икмәгең булмаса – менә монысы хәсрәт.

Сәгъди (фарсы шагыйре).

Икмәксез һәм Алласыз бусагага кадәр дә җитә алмассың.

Александр Суворов (рус полководецы).

Икмәк белән туендырасы урынга сүз белән туендырма.

Аристофан (борынгы грек комедиографы).

Икмәк булса, җыр да була.

Леонид Брежнев (1966–1982 елларда КПСС Үзәк комитетының Генераль секретаре).

Үзең эшләп тапкан икмәгең булса, Аллаһы Тәгаләдән аңа сыларга май сорый аласың.

Бауржан Тойшибек (казакъ язучысы, тарихчы).

Кайгы-хәсрәтсез тормышта ипи һәм тоз ашап яшәвең, кайгылы тормышта тәм-том ашап яшәүгә караганда күпкә яхшырак.

Иоһанн Златоуст (христиан дине рухание).

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен әзерләүче – Лилия ГӘРӘЕВА







ЗӘРКӘНЧЕ КЫЗЛАР

Алтын-көмешнең, гомумән, зәркән бизәнү әйберләренең бәясе гомер буе бик югары йөргән. Аларга ия булу хуҗасының статусын, ни дәрәҗәдә бай булуын күрсәткән. Ялтыраган алтын-көмеш байлык билгесе генә булып калмыйча, бу металлар материаль культура компоненты да саналган әле. Аларга ихтыяҗ бүген дә зур. Менә ни өчен зәркән сәнгатен үстерүгә аерым игътибар бирәләр.

...Зәркәнчеләр Гөлназ Хафизова һәм Ольга Петрованың иҗади дуэты моннан ун ел элек башлана. Халык сәнгате һөнәрләре көллиятенә укырга кереп, кызлар шушы һөнәрне үзләштерә. Бергә уку иҗади хезмәттәшлеккә дә юл ача. Алар, чынлап та, бер дулкында. Бизәнү әйберләрен дә, бер-берсен тулыландыра-тулыландыра, бергәләп ясыйлар. Тарих, әдәбият, суфичылык, көнчыгыш философиясе белән дә кызыксыналар. Зәркәнчелектә инде онытылып бара торган ысулларны кабаттан торгызып, татар традицион бизәнү әйберләре иҗат итәләр. Зәркән җитештерүдә эмаль дигән катлаулы юнәлешне дә бергәләп сайлаганнар. Ниндиләре генә юк: коеп ясалганнары, бизәкләп эшләнгәннәре... Аларны җитештерү зур хезмәт сорый торган катлаулы процесс. Композиция законнарын белүдән тыш, һөнәри өлкәдә дә осталык сорала монда. Эмальнең үз хикмәтләре бар. Аз гына дөрес эшләмәсәң дә, бөтен хезмәтең харап булырга мөмкин. Уйланылган рәсем йә сюжет шундук юкка чыгачак. Тырышлык куеп эшләнгән вак эш ихтыяр көче, түземлек, тырышлык таләп итеп кенә калмый, талант та сорый. Гөлназ белән Ольганың эшләрен күреп таң каласың. Колористика, сызыкларның җай гына күчеше күзләрне иркәли.

Бүген борынгы бизәнү әйберләре, музей предметы сыйфатына ия булып, күз карасыдай саклана. Сәнгати өстенлекләренә, ясалу вакытына, иҗат итүчеләренә, музейга килеп эләгү тарихына игътибар итеп, тикшеренүчеләр җитди өйрәнә аларны. Кыйммәтле металл һәм ташлар мәңгелек дип исәпләнсә дә, борынгы эшләнмәләрне реставрацияләргә, өслекләрен чистартырга, югалган ташларны өстәргә туры килә.

Зәркәнче-реставраторлар катламы – аерым катлам. Бу очракта инде син югары квалификацияле оста гына түгел, тарихны, металлар үзлеген яхшы белергә, геммолог булырга тиешсең. Кызлар әнә шул сыйфатларга да ия. Борынгы зәркән эшләнмәләрне реставрацияләү өлкәсендә алыштыргысыз белгечләр алар хәзер. Исемнәре XX–XXI гасыр Россия зәркәнчеләренең библиографик белешмәсенә теркәлгән. Күптән түгел шедеврга тиң эшләре белән шаккаттырдылар. Зәркән шәмаил – агачтагы панного сокланмаган кеше калмады. Гаҗәп нечкә эш: көмеш, бакыр, асылташлар һәм кайнар эмальне файдаланып, чын сәнгать әсәре иҗат иткәннәр. Татар стилендә, авангард яки шәрык стилендә эшләнгән бизәнү әйберләренең кабатланмас үз матурлыгы бар, алар Гөлназ белән Ольганың авторлык табышы буларак аерылып тора. Кызлар менә шундый нәфис-нәзберек юнәлештә үзләрен күрсәтә алган. Ә бит югары дәрәҗәләргә ирешкән зәркәнчеләр, гадәттә, ирләр була иде.

Иҗат иткән бизәнү әйберләренә кызларның күңел җылысы, югары зәвыгы да күчкән. Аларның эшләрен сәнгать кешеләре, артистлар, галимнәр һәм хәтта князьләр дә бик ошата...

Рәмзия КАШАПОВА








ГӨЛНАЗ ХАФИЗОВА
ОЛЬГА ПЕТРОВА





«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ИНДЕКСЫ **П2204**

Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар **73002**

Яртыеллыкка язылырга өлгерми калучылар һәр айның 15 нә кадәр язылып, журналны киләсе айдан алдыра ала



Сайтта: www.syuyumbike.ru
ВКонтактеда: vk.com/suumbike
Фейсбукта: www.facebook.com/syuyumbike
Инстаграмда: www.instagram.com/suyumbike_journal

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (теркәлеп) язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. **iPad** һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълуматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була.

16+

РЕКЛАМА